“ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ” МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
“ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ “ЯМАШИРМӘ “ЙОЛДЫЗ”БАЛАЛАР БАКЧАСЫ” МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

# “ИҢ МИЛЛИ ТӘРБИЯЧЕ – 2024”

***( ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАШУ)***

Биектау, 2024

Төзүче авторлар:

Яруллина М.Р. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе ярдәмчесе;

Габдрахманова Р.Г. - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе мәктәпкәчә белем бирү методисты;

Фәтхриева Э.А. - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе педагогларның һөнәри үсеше буенча методисты;

Гыймадиева Л.М. - “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә “Йолдыз” мәктәпкәчә бюджет белем бирү учреждениесе мөдире;

Яруллина А.Р. - “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә “Йолдыз” мәктәпкәчә бюджет белем бирү учреждениесе тәрбиячесе

“Иң милли тәрбияче – 2024”: республикакүләм бәйгедә уңышлы дип табылган эшләр җыентыгы./төз.авт:Яруллина М.Р., Габдрахманова Р.Г., Гыймадиева Л.М., Фәтхриева Э.Ә., Яруллина А.Р.- Биектау, 2024.- 173 б.

Рецензент : Төхфәтуллина Ә.Г. – филология фәннәре кандидаты, ДАҺБУ “Г. Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте” нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Җыентыкка “Иң милли тәрбияче” Республикакүләм бәйгесенә килгән иң яхшы эшләр урын алды. Җыентык милли белем һәм тәрбия бирүче балалар бакчалары педагоглары, татар теле укытучылары, эти – әниләр өчен ярдәмлек булып тора.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә
"Йолдыз" балалар бакчасы коллективы оештырган
*"Иң милли тәрбияче – 2024"* бәйгесендә җиңү яулаган эшләрдән тупланган
методик материаллар җыентыгына

**БӘЯЛӘМӘ**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә "Йолдыз" балалар бакчасы коллективы оештырган "Иң милли тәрбияче – 2024" бәйгесе Рәсәй күләмендә игълан ителгән "Гаилә елы" на багышлануы белән актуль. Чөнки тәрбия – ата-аналарның, тәрбиячеләрнең зур осталыгын, тырышлыгын һәм түземлеген таләп итә торган дәвамлы эш. Гаиләдә нигез итеп салынган, балалар бакчасында тагын да үстерелә, камилләштерелә.

Милли белем һәм тәрбия бирүче балалар бакчалары педагоглары, татар теле укытучылары һәм әти-әниләргә адресланган әлеге җыентыкта "Иң милли. тәрбияче" республикакүләм бәйгегә килгән иң яхшы эшләр урын алган. Хезмәтнең максаты – халкыбызның әдәби байлыгына, фольклор мирасына, аның гореф-гадәтләренә таянып балаларга ана телен өйрәтү.

Җыентыкның "Бәйрәмнәр, кичәләр" дип аталган беренче бүлегендә "Аулак өй". "Кичке уен", "Кич утыру", "Исем кушу йоласы" кебек таныш чаралар белән беррәттән, "Кабык салып, мунчала алу күренеше", "Туган нигезгә җыелу" , "Бусага ялы", "Он тарту" кебек сирәк очрый торган йолалар да бар. Аларның һәрберсе методик һәм тәрбияви максатларга ярашлы итеп язылган. Ә "Шөгыльләр, мастер – класслар" бүлегендә исә туган телдә сөйләм үстерү өлкәсенә караган белем бирү эшчәнлеге эшкәртмәләре һәм осталык шөгыльләре урын алаган. Алар да мәктәпкәчә яшьтәге балаларның яшь үзенчәлекләренә һәм кызыксынуларына ярашлы итеп төзелгән.

Гомумән, җыентык мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә милли тәрбия бирү юнәлешендә эшләү өчен файдалы чыганак. Аның аша балаларга халкыбызның гореф-гадәтләре, әдәби һәм мәдәни байлыгыбыз турында мәгълүмат бирү белән беррәттән, туган телдә сөйләшергә теләк уяту, аны хөрмәт итү; милли бәйрәмнәрнең тарихы белән таныштыру, аларда катнашу; халыклар, милләтләр арасындагы дуслык төшенчәсе кебек мәсьәләләр дә хәл ителер дип уйлыйбыз.

Төхфәтуллина Ә.Г. – Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, филология фәннәре кандидаты.

# КЕРЕШ

Халкыбызның алдагы көне, язмышы бүгенге балаларны, яшьләрне тәрбияләү белән бәйләнгән. Тәрбия эшендә катлаулы, әлегә хәл ителмәгән мәсьәләләр шактый күп. Бүген без укучыларны туган телдә укырга һәм язарга өйрәтү белән генә чикләнмичә, һәр яклап камил шәхес тәрбияләүнең бер юнәлеше булган милли культура формалаштыру, халкыбызның милли-мәдәни рухын сеңдерү юнәлешендә эшлибез.

Әдәплелек, тыйнаклык, намуслылык, башкаларга хөрмәт белән карау кебек әхлакый сыйфатлар һәт милләт кешесенә дә хас. Милли мәдәният формалаштыруда иң мөһиме – халык традицияләренә, гореф-гадәтләренә нигезләнеп, әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү.

Балаларда милли мәдәният турында Бербөтен күзаллау булдыру – туган телеңне белү һәм шул телдә аралашу; халык авыз иҗатын – әкиятләр, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, бишек җырларын белү; шигырьләр, җырлар өйрәнү; халыкка хас әдәп кагыйдәләрен, туган як табигатен, милли халык уеннарын белү дигән сүз.

Педагог-галим В.Казыйхановның сүзләрен искә төшерик: “Әгәр укытучы-тәрбияче белән бала өчпочмакның ике ягын тәшкил итсә, өченче – таянып торган ягы  - ата-ана”. Кеше гамәлләренең әхлакый сыйфатларына бик яшьли нигез салына. Гаделлек, хезмәт сөючәнлек, кыюлык кебек уңай сыйфатлар яшьтән үк әхлакый гадәтләр буларак тәрбияләнгәндә генә, кешенең гомерлек ышанычлы юлдашына әйләнәчәк. Бала кечкенәдән үк үз-үзенә хезмәт күрсәтү һәм билгеле бер режимны үтәү бурычларын, нәрсәне эшләргә ярый, нәрсәне ярамый икәнлеген белергә тиеш. “Кем дә булса, башкаларның гаепләрен тикшергәнче, беренче чиратта үзендә булган кимчелекләрне бетерергә, үзен яхшы итеп тәрбияләргә тырышсын”, - ди галим.

Балаларга дөрес тәрбия бирүдә ата-ананың абруе көчле. Аларның шәхси үрнәге генә балаларның мәхәббәтен яулый ала. Шуңа күрә ата-аналар дөрес тәрбияне иң беренче чиратта үзләреннән башларга тиеш. “  Гыйлем вә тәрбия орлыкларын хәзер ихлас вә мәхәббәт илә чәчсәгез, киләчәктә файдалы җимешләрне дә үзегез җыярсыз”, - ди Р.Фәхреддин.

Яшь буынга дөрес тәрбия бирү вазыйфасына һәр ата-ана җитди һәм җаваплы карарга тиеш. Ә моңа тиешле педагогик белем алу, тәрбия бирү чараларын белү, үтәү нәтиҗәсендә генә ирешергә мөмкин. Ә балалар бакчасы менә шул зур вазифаны башкара ала.

2024 нче ел Рәсәй күләмендә игълан ителгән “Гаилә елы”  кысаларында без, Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы” коллективы гаиләдәге милли гореф-гадәтләрне яңарту, милли бәйрәмнәрне искә төшерү, милли үзаңны үстерү, милли рухлы тәрбиячеләрне барлау максатыннан ДАҺБУ Г. Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте”, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе белән берлектә, Татарстан Республикасының мәктәпкәчә

белем бирү учреждениеләренең татар телендә белем бирүче тәрбиячеләре арасында **“Иң милли тәрбияче”** Республикакүләм бәйгесен оештырдык.

Бәйгегә килгән, яхшы дип табылган эшләрне җыентыкка туплап, сезгә дә тәкъдим итәбез!

**Габрахманова Рамилә Гомәр кызы,**
Мәктәпкәчә белем бирү методисты.
**Гыймадиева Ләйлә Мансур кызы**,
Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы мөдире

# БӘЙРӘМНӘР,
# КИЧӘЛӘР



**“БУСАГА ЯЛЫ” ЙОЛАСЫ**

***Гыйлметдинова Гөлназ Равил кызы***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*

*“Катнаш төрдәге Балтач1нче балалар бакчасы”*

*муниципаль бюджет мәктәпкәчә*

*белем бирү учреждениесе*

**Максат:** балаларны татар халкының гореф – гадәтләре, “Бусага ялы” йоласы белән таныштыру.

**Үстерү бурычы:** балаларның халык авыз иҗатын өйрәнүгә кызыксынуын үстерү.

**Тәрбияви бурыч:** татар теленә карата хөрмәт һәм ихтирам тәрбияләү, халыкның рухи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту.

**Белем бирү бурычы:** милли ризыклар ,милли киемнәр турындагы белемнәрен тирәнәйтү. Татар халкының гореф – гадәтләрен хөрмәтләргә өйрәтү.

**Төп белем бирү өлкәсе:** “Сөйләм үсеше”.

**Интегральләшкән белем бирү өлкәләре:** “Танып-белү үсеше”, “Социаль-коммуникатив үсеш”.

**Методик алымнар һәм чаралар:** әңгәмә, сораулар, биремнәр, күзәтү, сәхнәләштерү, картиналар карау, үзбәя бирү.

**Җиһазлау:** залның түрендә матур итеп бизәлгән авыл йортының эчке күренеше: матур итеп чигелгән мендәрләр, чигелгән җәймәләр белән ябылган кровать, чиккән ашъяулык ябылган өстәл, сөлгеләр, чыта паласлар, скамейкалар, залның алгы өлешендә авыл йортының тышкы күренеше: бусага белән эшләнгән йорт ишеге, кечкенә коймалар,койма башына куярга балчыктан эшләнгән чүлмәк, ноутбук, тавыш көчәйткеч колонкалар.

**Сүзлек өстендә эш:** бусага, бусага ялы.

**Алдан үткәрелгән эш:** әңгәмәләр, слайдлар карау, шигырьләр, җырлар өйрәнү.

**“ Галиябану” татар милли көе уйнала.**

**1 нче кыз бала:** Әбием,әбием, кара әле,син өйрәткәнчә чәк-чәк пешердек, авыз итеп кара әле,тәмле булганмы?

**Әби:** Бик тәмле булган бу балалар, булдыргансыз!

**2 нче кыз бала:** Әбием чәк-чәк пешерү кайдан барлыкка килгән ул?

**Әби:** Балакайларым минем, борынгы риваятьләрдә сөйләнгәнчә, Болгар ханы узенең бердәнбер малаеның туй өстәлендә яңа сый торуын тели: ул әзерләүнең гадилеге белән барысын да гаҗәпләндерсен, озак бозылмасын һәм шул ук вакытта үзенең тәм сыйфатларын

югалтмасын, ди. Пешекчеләр бик озак эзләнәләр. Күп кенә тәмле ризыкларны хан татып караган, тик ул аларның берсен дә ошатмаган. Ул бары тик бер көтүче хатының оннан, йомыркадан һәм балдан әзерләнгән  чәк-чәген сайлаган. Һәм бердәнбер улының туенда хан яшь парларга искиткеч чәк-чәк бүләк иткән. Шушы чәк-чәк кебек бер- берегезгә татлы телле булып гомер итегез дип теләк теләгән.

Шул вакыттан бирле балалар,татар туйларында, иң кыйммәтле сый һәм өстәл бизәге буларак, яшьләргә чәк-чәк тәкъдим итәләр.

Чәк-чәк  ул кызларым– татар халкының кунакчыллыгын күрсәтә торган сый.

**Балалар (бергә):** Иииии әбием,  рәхмәт синҗа!

**3 нче кыз бала:** Әбием,кара әле,син өйрәткәнчә оекбаш бәйләдем? Матур булганмы әбием?

**Әби:** Ай ай, бик матур булган, кулларың алтын икән, кызым! Хәзер бит заманалар башка кызым, кибетләрдән җаның ни тели шуны алырга була. Алар йонны кайдан алуларын да, ничек эшкәртүләрен дә белмиләр шул. Аларны гаепләп булмый. Заманасы шул.

**4 нче кыз бала, 5нче кыз бала**: Әбием,ә без син өйрәнкәнчә алъяпкыч чиктек. Я ,ничегрәк, әбием?

**Әби**:Иии балалар, бик матур килеп чыккан бит. Алъяпкыч ул балалар – уңган хуҗабикәнең генә түгел, булдыклы йорт хуҗасының да, хезмәт сөюче яшь буынның да киемендә аерылгысыз билге булып тора.Алъяпкыч, балалар бер ничә төрле булган. Әби-апаларыбыз ашарга пешергәндә бер алъяпкыч кигәннәр, эшләгәндә икенчесен, шулай ук кунакка бара торган алъяпкычлар да булган.

Аллага шөкер,чигәргә дә  ,бәйләргә дә,ашарга пешерергә дә өйрәттем үзегезне. Кызларым,ә бүген мин сезне, кич утырырга  чакырам.

**Кызлар бергә:** Кич утырыргааааа!

**Әби:** Әйе, әйе балалар, кич утырырга!

**1 нче кыз бала**:Сезнең замандагы кебекме  ул, әбием?

**Әби:** Әйе, кызым, нәкъ безнең замандагы кебек кич утырырга  чакырам сезне.

**Кызлар (барысы бергә):**Ә егетләр ?

**Әби:** Килерләр,егетләрне дә дәштем.

(Кызлар шатланышып өй җыештыра башлый. Музыка уйный. Әби сөйли.)

**Әби:** Эх, бар иде бит безнең яшь чаклар. Егетләр гармун уйнап, җырлап урам әйләнерләр иде, кызлар янына кич утырырга аулак өйләргә килерләр иде. Эх, хәзер яшьләр элекке, без уйнаган уеннарны оныттылар шул. Заманаларны шушы телевизор, телефон, компьютер дигән зәхмәт басты бит.

**2 нче кыз бала:** Әбием, нигәдерегетләр дә килми, килгәннәре дә күренми .

**Әби:** Килерләр, килерләр,килмичә кая китәрләр икән!

**3нче кыз бала:** Килсәләр нишлибез соң, әбием?

**Әби:** Килсәләр, бусага ялы түләтмичә кертмәгез! Егетләрне матур итеп каршы алыгыз.

**Әби:** Ә сез балалар, бусага ялы ни икәнең беләсезме соң?

**Кызлар:(**бергә) Юкккккк.

**Әби:**Бусага – нәрсә соң ул балалар?

**Кызлар(бергә):** Ишек төбе.

**Әби:** Ә бусага ялы, ул балалар, бусагадан үтү өчен нинди дә булса күчтәнәч алып килү. Иииии балакайларым минем, без яшь чакта, егетләр кич утырырга килгәндә , матур итеп тегелгән җыйнак кына янчыкка билле прәннек, шикәр, җимеш, конфетлар салып алып килә торган иделәр. Элек заманнарда ук ,кыз бала кияүгә чыкканда, ризалык билгесе итеп, егеткә сөлге бүләк иткән. Килен кеше- кияү өенең бусагасын атлап кергәч тә, бусага бирнәсе итеп , чөйгә сөлге элгән. Өйне үзе алып килгән сөлге-тастымаллар белән бизәгән. Бу инде килен булып төшкән кызның уңган- булганлыгын күрсәткән.

Гармун тавышы.(Малайлар “Гармун алыйк, әле дускай” җырын җырлап киләләр) Малайлар тавышы ишетелә. Ишек шакыйлар.

**Кызлар**:Чү, киләләр, киләләр!Бусагага басыгыз.

Ыгы-зыгы башлана.

**Малайлар:(**шау-шаулап ишеккә ябырылып) Кызлар, кызлар кая сез, нигә кертмисез инде? Ачыгыз инде.

**Кызлар:**Ач булсагыз, ашап килегез.(көлешәләр).

**Малайлар:** Ачыгыз тизрәк.

**1 нче кыз бала:** Ә, бусага ялың кайда соң?

**1 нче малай:** Әссәламәгаләйкүм чибәркәй, ала алсаң, мә ал! (Малай матур итеп чигеп эшләнгән янчыкны югары күтәрә, кыз үрелеп карый, ала алмый. Малай тагы да өстәрәк күтәрә, кыз сикереп кучтәнәчне ала)

**1 нче кыз бала**: Рәхмәт! Әйдә рәхим ит, түргә уз. (Барып утыралар).

**2 нчемалайлар**: Кызлар дим, кызлар! Безне дә кертегез инде.

**2 нче кыз бала:** Ашыкма, авызын ашка пешәр. Сиңа, егет ни кирәк?

**2 нче малай:** Кара кашлы кыз кирәк.

**3 нче кыз бала:** Ни эшкә соң ул кирәк?

**2 нче малай:** Әнигә килен кирәк.

Кызлар көлешәләр. Малай кермәкче була.

**3 нче кыз бала:** Чү, чү, бусага ялың кая? Кара аны, ял түләмичә кермәкче була.

**3 нче малай:** (малай янчыгын югары күтәреп) Ала алсагыз, алыгыз!

(малай тагында янчыкны югары күтәрә, кыз бала сикереп диярлек үрелеп янчыкны ала.)

**Кызлар**: Бик зур рәхмәт! Әйдә, рәхим итегез, түргә үтегез. (Барып утыралар).

**4 нче малай**: Мине дә кертегез инде, кызлар-йолдызлар.

**4 нче кыз бала:** Ә синең бусага ялың кая соң?

**4 нче малай:(шаяртып)** Ииииии күктәге йолдызым, салам түшәгем, судагы кондызым, сазда.....

**4 нче кыз бала**:Алаймы? ( егетне уйнап чәбәкли башлый)

**4 нче малай**: Бетте, бетте мә ал.(янчыгын югары күтәрә) Ала алсан, ал!

(Янчыкны югары күтәрә, кыз үрелеп ала.)

**4 нче кыз бала**: Әйдә, рәхим ит, түргә уз. (Барып утыралар).

Әби өй эченә үтә. Малайлар әбине күреп, утырган урынныркннан торып, әби белән кул биреп күрешәләр.

**Малайлар(бергә):** Исәнме, Мәдинә әби! Рәхмәт, безне чакырганга.

**Әби:** Әйдүк, әйдүк, балакайларым. Түрдән узыгыз!

**3 нче малай:** Бәйрәм булгач, бәйрәм булсын әйдә, күңелле үтсен кичебез. Уен, җыр-биюләр белән бергә үрелеп, безне кичебезне бизәсен.

**1 нче малай:** Кызлар, әйдә, бергәләп “Пешмәгән” уенын уйнап алабыз.

**Кызлар(бергә):** Әйдәгез, уйныйбыз.

Кагыйдә. Парлашып уенга басалар, бер парсызы уртага чыга. Бию көе башлана. Уртадагы уенчы эчтәге кешеләрне ияртеп китә, бию көенә баралар. Көй туктагач, һәркем парлашырга тиеш. Пары җитмәгән – пешмәгән була.

**5 нче кыз бала:** Егетләр, әйдәгез бергәләшеп җырлап- уйнап алабыз.

Кара-каршы күмәк җырлы уен **“Челтәр элдем читәнгә”** уйнала.

Малайлар бер рәткә, кызлар аларга каршы басалар. Кара-каршы җырлыйлар.

**Ялгыз калган кыз бала:**

Ал алъяпкыч челтәрле, илдә матур бетәрме?

Илдә матурлар бетәрме, җан сөйгәнгә җитәрме?

**Кызлар:**

Челтәр элдем читәнгә, җилфер –җилфер итәргә.

**Малайлар:**

Без килмәдек буш китәргә, килдек алып китәргә.

**Кызлар:**

Алын алырсыз микән, гөлен алырсыз микән?

Урталарга чыгып сайлап кемне алырсыз микән?

**Малайлар:**

Алларын да алырбыз, гөлләрен дә алырбыз,

Күңелебезгә кем ошаса, шуны сайлап алырбыз.

**Ялгыз калган кыз бала:**

Әй дусларым, дусларым, дусларым , бәгырьләрем,

Яшь гомерләр ике килми, белегез кадерләрен.

**Кызлар:**

Челтәр элдем читәнгә,җилфер –җилфер итәргә.

**Малайлар:**

Без килмәдек буш китәргә, килдек алып китәргә.

**Кызлар:**

Алай да бергә – бергә, болай да бергә – бергә,

**Малайлар:**

Дуслар белән бергә булсаң, күгәрчен кебек гөрлә.

**Бар да:**

Алларын да алырбыз, гөлләрен дә алырбыз,

Күңелебезгә кем ошаса, шуны сайлап алырбыз.

**Әби:** Иииии балакайларым минем, җырладык та, уйнадык та. Ә хәзер, бер рәхәтләнеп чабата биеп алыйк әле.

Чабата бию.

**Малайлар:** Мәдинә әби, кызлар, бик күңелле үтте кичебез, хәттә сизелмәде дә. Безгә китәргә вакыт. Рәхмәт сезгә. Сау булыгыз.

**Кызлар**: Сау булыгыз егетләр, киләсе очрашуга кадәр.

**Әби:** Сау булыгыз,балалар.

# КИЧ УТЫРУ

***Әхмәтшина Флера Солтан кызы***
*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*
*“Рябинушка” Красносельский балалар бакчасы”*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениясе*

Яшь төркеме: зурлар

**Үткәрү формасы:** тематик, гомумиләштерүче.

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар халык мәдәнияте, аның гореф-гадәтләре белән таныштыру. Гаилә белән мәктәпкәчә белем бирү учреждениясы арасында үзара аңлашучанлык,уртак кызыксынучанлык,эмоциональ үзара ярдәмләшү атмосферасы булдыру.

**Бурычлар:**

**Тәрбия бирүче:**

- халык мәдәниятенә уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- балаларда бер-береңә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;

**Укыту:**

- көнкүреш әйберләренең исемнәре белән таныштыру, сүзлекне баету;

**Үстерү:**

- сөйләмнең эстетик һәм эмоциональ ягын үстерү;
- музыка эшчәнлегенең төрле төрләрендә ритм хисен, үз хәрәкәтләрен сөйләм белән килештерә белүне дәвам итү;
- уеннар, хәрәкәтләр аша координацияне, реакция тизлеген үстерү;
- уенда иҗади күренешләр һәм яшьтәшләре белән аралашу белән кызыксынуны үстеру;

Музыкаль залны бизәү: зал бәйрәмчә бизәлгән, стеналарга туган тел турында әйтемнәр , шигырьләрдән өзекләр язылган плакатлар,төсле рәсемнәр эленгән, өстәлләрдә («киштәләрдә») - самавыр,татар халык ашлары , музыкаль уенчыклар;

**Кулланыла торган технологияләр:**

-мәгълүмати-коммуникатив;

- иҗади сәләтләрне формалаштыру технологиясе;

-сәламәтлек саклау;

-эзләү-танып-белү;

- музыкаль йогынты технологиясе;

**Мәгариф өлкәләре (интеграция):** «Танып-белү үсеше», «Сөйләм үсеше», «Социаль – коммуникатив үсеш», «Социаль – шәхси усеш»;

**Методлар һәм алымнар:** уен күнегүләре, күрсәтмә, ишетү, кызыксындыру алымнары, контроль методы, үз-үзеңне тикшерү, сүзләр.

**Сүзлек эше:** сүзләрнең мәгънәсен аңлату, фольклор, киштәлек.

(Тәрбиячеләр һәм балалар татар киемнәрендә)

*Бүлмә бәйрәмчә бизәлгән,балалар салмак кына музыкага керәләр.*

**А.Б.:**Балалар безнең татар халкы элек электән кунакчан булган,әби-бабайларыбызның гореф гадәтләрен,милли традицияләрен саклаганнар һәм бик күңелле итеп ял иткәннәр:бәйрәмнәр,кичәләр,фольклор чыгышлар үткәргәннәр,халык җырларын,халык уеннарын яратып башкарганнар.Менә бездә бүген әби бабайлардан килган “Кич утыру” бәйрәм тамашасын үткәреп алабыз.

( ишек шакыйлар)

**1 бала:** Безнең олы капкага кем анда кат-кат кага?

Тормагыз инде басып, кечкенә капка ачык.

**А.Б:** Әйдә, безгә килегез, капкалардан керегез,

Капкалардан керегез, бакчабызга үтегез.

Бакчабызга үтегез, кунак булып китегез.

*Музыкага кунаклар керәләр.*

**А.б:** Капкалардан әз кергән, безнең бакчага кем килгән?

**Җыр “Әссәләмәгаләйкем”**

**Кунаклар:** Кәм килгән дип, сорамагыз, кадерле дуслар килгән!

Кунаклар,балалар исәнләшәләр.

**Кунаклар:**Исәнмесез, диеп башлыйк әле, танышу бит шулай башлана.

Сезнен белән очрашканга, дуслар, күңелебез шундый шатлана.

**2 бала:** Хуш киләсез, үтегез, түрдән рәхим итегез!

Хуш киләсез, үтегез, узыгыз, утырыгыз!

**(**Балаларкунакларны эстәл артына чакыралар,чәй эчәләр.)

**А.Б:** Самовар куйдым кайнарга, өргәнче кайнап чыкты.

Тәмле итеп чәйләр әчик, барыбыз бергә чакта.

Сез, балакайларым, өстәл әзерләгез.

Ә сез, кунаклар, оялмыйча өегездәкебек булыгыз!

**ЖЫР “Без әзәрлибез табын”**

*(н.т. с.40)*

*(балалар утыралар һәм чәй эчүне дәвам итәләр).*

**Кунаклар:** 1. Бер утыру үзе бер гөмер дип, бабайлар бит юкка әйтмәгән.

Бер очрашып серләр бүлешу, бу гадәтләр әлә бетмәгән.

Шул унай бәлән бүген җырның иң матурын гына.

Җырламый мөмкин түгел.

2. Яхши дуслар җыелганнар, шул унай белән бүген.

   Җырыбызнын иң матурын гына, Җырламый момкин түгел.

3. Җыр күңелне күтәрә җырдан йорәк басыла.

   Дуслар җыелган табынга, җырлап күңел ачыла.

**“Такмаклар” (кунаклар башкаралар).**

Килгән кунакларын күңеллен күрик,

Оркестр белән күңел ачыйк!

(Балалар инструментлар алалар, кунаклар чигү чигергә утыралар)

**ОРКЕСТР**

А.Б: Кунаклар сезгә безнең музыкабыз охшадымы?Ә һәзер без сезне уйнарга чакырабыз,рәхим итегез.

**Уен “Парыңны тап”**

А.Б:Балалар матур чәчәкләр арасында, карагыз әле, зәңгәр чәчәктә бар,әйдәгез аның белән уен уйныйбыз.

**Уен «ЗӘҢГӘР ЧӘЧӘК»**

**3 Бала:** Тәрәзәдә гөлләр үскән гөл яфрагын кем кискән?

Уйнамый да, келми генә бу дөньяда кем үскән?

**УЕН «ТҮБӘТӘЙ»**

**4 Бала:** Сез дә килгәнсез икән, без дә килгәнбез икән.

Яхшы, дуслар, җыелганнар, парлашып биик икән!

**Яз турында шигырлар**

(Балалар,кунаклар тагын чәй эчәләр)

**“Күмәк бию”**

**Кунаклар:** 1. Нинди олы бәхет-җыелышып, уйнап келү гел бергә,

Насыйп булсын идесөенешеп шатланып яшәү гел бергә.

2. Алай итәргә кирәк, болай итәргә кирәк,

   Хуҗаларга рәхмәт әйтәп, кайтып китергә кирәк.

3. Кем кунаклар яратмый, алар шатлык таратмый,

Җырларыбыз юлдаш булсын сезгә.

**А.б:** Рәхмәт сезнең, барыгызга килгәнсәз,

әби, бабай,гадәтләрән шулай дәвам итәрбез:

**5 бала:** Гел бергә-бергә бөтен гомергә,

Җырлап яшәргә, гөрләп яшәргә,язсын дөньяда!

*Кунаклар китәләр.*

Балалар кул селкеп саубуллашалар .

## “КАБЫК САЛЫП, МУНЧАЛА АЛУ КҮРЕНЕШЕ”

***Гилемханова Рәфисә Нурулла кызы***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының*

*Югары Шытсу “Ак каен” балалар бакчасы*

*муниципаль мәктәпкәчә белем бирү бюджет учреждениесе*

“Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәнеңне онытма син!
Бел син ерак бабаларның,
ничек итеп көн иткәнен...
Ни иккәнен, ни чиккәнен,
Нинди җырлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.
Р.Фәйзуллин.

Максат:халкыбызның борынгы гореф- гадәтләрен өйрәнүне дәвам иттерү.

Үстерү бурычлары:балаларның игътибарын,сөйләм телен үстерү.

Тәрбия бурычлары:милли йолаларга,гореф- гадәтләргә карата кызыксыну,олылар хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.

Белем бирү бурычлары:балаларны борынгы йолаларның берсе булган кабык салып мунчала алу серләренә төшендерү.

Җиһазлау.Күл күренеше,зәңгәр күл җыры, юкә кабыклары,казыклар,кармак,мунчалалар,бүләкләр, магнитафон.

Барышы.

Камышлы күл куренеше. Зәңгәр күл җыры яңгырый.Күл кырыенда балыкчы малай утыра.

Бабай килә,исән-сау гынамы олан.Балык чиртәме?Бездә яшь чакларда балыктан кайтып керми идек.Ул чагында мондый матур кармаклар да юк иде.Шулай да аптырап тормадык.Бер тал чыбыгы алып аның бер башына тимер чыбыкны бөгеп ыргак ясап, беркетеп шуңа чели

киертеп балык тоттык.Заманалар үзгәрде, кармакларның да ниндиләре генә юк хәзер, аллага шөкер генә инде балалар.

-Менә улым,мин бу күлгә кабыклар салган идем бит әле.Кабыкның нәрсә икәнен беләсеңме соң син?

-Юк бабай белмим,нәрсә соң ул?

-Ул улым агач кайрысы була.

-Әнә теге казыкларны күрәсеңме?

Менә шуларга кабыклар бәйләнгән,мин менә мунчаласы өлгердеме икән дип карарга килгән идем.Әгәр өлгергән булса өмә ясап кабыклардан мунчала кубарасы була.Ул вакытта синең балыкларың качып бетәр инде.

-Син ,әнә теге беренче рәшәткәгә барып кара, анда да балык бик шәп чиертә ул.

-Бабай, мин анда син тал чыбыгыннан үреп биргән сөкәне салган идем бит.Минем дә ничек итеп мунчала алып булганны күрәсе килә бит бабай.

Бабай җырлый:

Инеш сулары бик сай

Буа буамый булмас.

Кабык салып мунчала алып,

Файдаланмыйча булмас.

Ай хилләү,хилләү,хилләү

Файдаланасыбыз бар(2 тапкыр)

Селте суы һәм мунчала

Бергәләп идән югач.

Гәрәбәдәй чиста була

Мунчала белән югач.

Ай хилләү,хилләү,хилләү

Мунчала белән югач(2тапкыр).

Бабай.Бик әйбәт булыр улым.Борынгыдан килгән бу гадәтне күреп, белеп өйрәнүең бик яхшы.

Көндә эшләнә торган эш түгел бу, балыкны көндә тотарга була.

Мунчала бик кирәкле әйбер.Экологик яктан бик чиста,тәнне юганда массаж да ясый әле ул.Аның белән идән юсаң идән ялтырап тора. Элек-электән юкә кабыкларын суга салып куеп тотып торганнар.Моның өчен суның тирән булуы да кирәк.Чөнки кабыклар суга күмелеп торырга тиеш.Әгәр мондый күлләр булмаса инешләрне буап куеп та салырга була.

Кабыклар суга салгач агып китмәсен өчен дүрт башына дүрт казык кагып куела.Кабыкларны шуңа бәйләп өстенә таш бастырып куярга кирәк.Шуннан сон мунчала өлгергәнче суда тотыла.

Бүген көн дә бик матур, мунчаласы купкан булса өмә ясап алырбыз аллаһ -боерса.

(Бабай суга кереп бер кабыкны алып мунчаласын куптарып карый.)

-Булган бу улым.Син хәзер авылга кайтып,өмәгә кешеләрне чакырып килерсең.Хәдичә әбиең дә кабык салсаң мунчала бирерсең әле дигән иде.Аңа да хәбәр бирерсең.Кыскасы бар балакаем ашык,барсын өмәгә чакыр.(малай авылга чаба)

Җыр.Өмәгә килүче яшьләр катнашында.(авыл көе)

Бабай. Җәмагать аллаһның рәхмәте белән кабык салган идем, мунчала чыгарырга дип. Менә Югары оч Дәүлиләр чыгарган,аларныкы өлгергән,без дә алар белән бергә салган идек, шуңа күрә мин дә килеп караган идем, безнеке дә өлгергән мунчала.

Әби: И картым карале, мин өмәдә катнашучыларга дип бүләкләр дә алып килдем бит әле.

Бабай:Булган әбисе булган,ә хәзер матур теләкләр теләп эшне башлыйк.

Бабай: .Әйдә Мөнип улым син яшь кеше суга керерсең,башта бисмилләһны әйтеп казыкларын чишәрсең.Шамил улым син дә кабыкларны алып чыгышырга булышырсың.Ә сез кызлар кабыктан менә шулай итеп мунчаланы кубарып элеп куярсыз.(курсәтә)Элеп куйсаң суы саркып кибәргә әйбәт була.Син әбисе яшьләргә ничек эшләргә кирәк икәнен өйрәтеп торырсын.

(Өмә җыр- уен белән дәвам итә.)

Кыз бала.Бәйрәмнәр бик күп болай да,
Ә шулай да,ә шулай да
Иң шәп бәйрәм-кабык салу йоласы бәйрәме булачак!

Икенче кыз.Җырлар тыңлыйк,җырлыйк,отыйк,
Җыр куңелне җылыта.
Әйдә җырлап яшик, дуслар,
Җыр дуслыкны ныгыта.

(Егетләр һәм кызлар капма -каршы басалар да такмаклар җырлыйлар.)

Егетләр.Без җырлыйбыз шаян җырлар,
Ә сез тыңлап торыгыз.
“Әнә килә автомобиль”
Булыр безнең җырыбыз.

Кызлар.Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр мунчала.
Безнең авыл малайлары-
Юктан югалып кала.

Егетләр. Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр кабыклар

Безнең авыл кызлары-

Сиксән яшьлек карчыклар.

Егетләр.Әнә килә автомобиль,

Сез нигә утырмыйсыз?

Башка кызлар тиз онтыла,

Сез нигә онтылмыйсыз?

Кызлар. Әнә килә автомобиль,

Агып бара майлары.

Шәп җырлый безнең малайлар,

Җырлый торган чаклары.

Егет.Мин сезгә бер кызык сөйлим әле.(барсы да түгәрәкләнеп утыралар.)

Җиктем үрдәк,

Киттем үрләп,

Җиктем күркә,

Баганадан өркә,

Арбам кабык,

Төядем мунчала,

Барам чабып,

Киттем авып,

Тәртәсе салам.

Төшәм дә калам,

Төшәм дә калам.

Ничек кайтып җитәргә?

Аптырадым бит тәмам.

Кызлар.Әйдәгез , “Мунчала” уенын уйнап алабыз.( музыка куела, мунчала кулдан –кулга тапшырыла, көй туктагач кемдә кала, шуңа җәза бирелә.Уен тәмамланганнан соң барсы бергә)

Кул буена мунчалага ,

Дип кенә килгән идек.

Тиз генә әйләнеп өйгә

Кайтырбыз дигән идек.

Әби. И оланнар бик матур итеп җырладыгыз, уйнадыгыз яшь чакларыбызны искә төшердегез, бик зур рәхмәт сезгә.Мунчалаларда бик куп булды.Өмәдә бик тырышып эшләдегез, менә сезгә үзебезнең бүләкләребезне тапшырабыз ,бүгенге өмә истәлеге итеп сакларсыз.

# **“ОН ТАРТУ”**

(татар халык йоласы)

***Әхмәтшина Нурфия Роберт кызы***

*Арча районы МБМБУ*

*“Арча 9нчы номерлы балалар бакчасы”*

Максат: балаларны татар халкының милли гореф-гадәтләре белән таныштыруны дәвам итү; балаларда бу гореф гадәтләргә, йолаларга хөрмәт, ихтирам тәрбияләү, милли җырлы- биюле уеннар аша балаларда туган телгә карата хөрмәт тәрбияләү, балаларның сүз байлыкларын арттыру.

***Бәйрәм барышы.***

Бабай: Табигатьне генә күр әле карчык, ул болыннары..Ялтырап бормалы Агыйдел ята.Ул , баллы куәт исе дисенме, балык исе.. Өлгергән, ашлыктан тарткан он исе, бәгырләрне кисеп керә карчык.

Әби: Сөбханалла, сөбханалла диген Гарифҗан бар нәрсә дә Аллаһның рәхмәтеннән тора. Бик шөкер килде бит елы да.. Икмәкләр дә бик уңышлы булды.

Бабай: Шулай карчык, шулай ..Җиле дә вакытында исеп, яңгыры да вакытында яуды. Шөкер хезмәтебез бушка китмәде, барыбыз да шул бер пот икмәккә карап торган көнебез.

Әби: Илдә тынычлык урнашкач, заманаларыбыз да үзгәреп, тормышларыбыз да әкренләп җайлана тошә бит картым.

Бабай: Әлһамдеүлләх таякка эшләп, ачлыктан үлмәскә бер кесә ашлык белән тотылып , зинданнарда күпме халык әрәм булды.

Әби: Сөйләмә генә инде картым...үзәкләрне өзәрлек ??

Әйдәле Гарифҗан тегермән ташларыңны караштыра тор. Хәзер килеп җитәрләр. Кичә байтак кеше белешкән иде түгелме соң?

Бабай:Ташын карадым ла карчык, суы шактый кимегән әле.. Бераз буаны ныгытмыйча тегермәнне җибәреп булмас..Ярты йорты эшнең рәте башы да булмас..Кешенең карап торган икмәгеннән мәхрүм итсәң Аллам сакласын.

Әби: Шулай, шулай картым. Гозер –амәнәт итеп сиңа тапшырганнар икән, мамык кебек булсын картым. Тегермәне легер-легер әйләнеп, яхшы чыгарса гына, икмәкнең исе дөняларга тарала аның ..

(ашлык күтәреп берәм-берәм керә башлыйлар)

1.Егет: Әссәламәгаләйкүм, исән саулар гына торасызмы?

Бабай Вәгаләйкүмәссаләм!Шөкер үзегез исән саулар килеп җиттегезме? Әй улым да килгән икәәән.

Теге юлысы килгәндә шигырь өйрәнеп кил дигән идем улым, кая өйрәнденме икән?(бала сойли)

Бабай: Әй, маладис улым, булдырдың. Урнашыгыз әйдә оланнар.

2. Егет:И,Гарифҗан абзый без бу көнне саный-саный көтәбез. Ай-яй шактый булды быелгы икмәк. Урнашабыз, урнашабыз...

1 Егет: Икмәктә генә микән хикмәт? Гарифҗан бабай белән Майҗамал түтидәдер хикмәт.(шаярып) Алар булмаса нишләр идек җәмәгать?

Әби: И, рәхмәт төшкереләре, безне шулай олылаган өчен ходай зурласын сезне.

Әй улым, кая, син дә берәр шигырь өйрәндеңме сон?

2 Егет: Бар энем теге , өйрәнгән матур шигыреңне сөйләп күрсәт әле. (бала сөйли)

Бабай: И, рәхмәт улым, менә ичмасам булдыралар....

Әби: Гарифҗан! Буаның суы кимегән дигән, идең түгелме соң...Эш башланганчы бергә-бергә ныгытып аласызмы әллә?

1 Егет: Хәзер, Майҗамал түти, тегермәнгә җан кертәбез аны.

1 Кыз: Әйдәгез җәмәгать, эшкә тотыныйк. Кем эшләми, шул ашамый, Майҗамал түтинең икмәгеннән авыз итәсегез килсә, тизрәк эшлик...

2 Кыз: Әйдәгез, җырлый, җырлый эшлик.Тизрәк тә эшләнер, күңелләр дә күтәрелеп китәр.

Бергә

Әби: Булдырдыгыз, оланнар. Мондый ил токкасыдай, егетләр-кызлар булганда була . Кара, мөшкәдән ничек итеп ага... Күрегез әле бу нигъмәтне (учына он ала , онны уып карый) (бергә әйе,әйе ,ай-яй бигрәк хуш исле) Бер уч он алып кереп китә.

Балалар, мин кереп ипиемне өлгертим әле.

1 Кыз:(уртага чыгып)

Әйдәгез әле җәмагать чират җиткәнче, берәр уен уйнап алыйк.

Әйдәгез,әйдәгез.(бергә)

4 төркем балалары "Башмакчы" уенын уйный.

12 төркем балалары "Төймә" уенын уйный.

Әби:Икмәк пешеп чыкты оланнар, әйдәгез авыз итегез.

Адел белән Раяз шигырь сөйли.

1 Егет: Ай-яй ничек күпереп пешкән,исләре дә исләре...

2 Егет : Мондый ,күпереп пешкән икмәкне бары,Майҗамал әби генә пешерә ала.

Әби:И,оланнар икмәкне пешереп була аны, оны яхшы булса...Онда бөтен хикмәт, онда...Гарифҗаным гына исән булып тора күрсен..

1 Егет: Әйе шул,мондый яхшы онны ,бары Гарифҗан бабай гына тарта белә.

2 Егет:Якын тирәдә андый тегермәнне, көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Тегермәнчесе турында әйтәсе дә юк.

Бабай: Әәәәй оланнар. -Илләребез тыныч булып, икмәкләребезне исән-сау ашарга насыйп булсын ...

1 Егет: Шулай булсын, амин сез дә исән-сау гына булып, тегермәндә теркелдәп торсын..

Әби: Шулай ,шулай булсын оланнар. (җырлый)

Әйдә әле, Гарифҗан, булмаса гармуныңны тартып җибәр әле...

Дөбер,дөбер әйләндерә

Тегермәннең ташлары,

Ниләр генә күрми икән

Бу адәмнең башлары.

Уйныйбыз да,жырлыйбыз да

Дуслар гаеп итмәсләр,

Халкыбызга бәхет теләп ,

Җырлап яшик иптәшләр.(чыгып китәләр)

Жырлыйк әле, җырлап эшлик,

Жырлап эшләр чагыбыз

Нинди матур, нинди гүзәл

Безне туган ягыбыз.

Кушымта: Безнең эшкә сездә шулай

Җиң сызганып кушылыгыз.

Йөрәкләрне жилкендереп

Жырлап эшләр чагыбыз

Әби: Булдырдыгыз, оланнар. Мондый ил тоткасыдай, егетләр-кызлар булганда була . Кара, мөшкәдән ничек итеп ага... Күрегез әле бу нигъмәтне (учына он ала , онны уып карый) (бергә әйе,әйе ,ай-яй бигрәк хуш исле) Бер уч он алып кереп китә.

Балалар, мин кереп ипиемне өлгертим әле.

1 Кыз:(уртага чыгып)

Әйдәгез әле җәмагать чират җиткәнче, берәр уен уйнап алыйк.

Әйдәгез,әйдәгез.(бергә)

4 төркем балалары “Башмакчы” уенын уйный.

12 төркем балалары “Төймә” уенын уйный.

Әби:Икмәк пешеп чыкты оланнар, әйдәгез авыз итегез.

Адел белән Раяз шигырь сөйли.

1 Егет: Ай-яй ничек күпереп пешкән,исләре дә исләре...

2 Егет : Мондый ,күпереп пешкән икмәкне бары,Майҗамал әби генә пешерә ала.

Әби:И,оланнар икмәкне пешереп була аны, оны яхшы булса...Онда бөтен хикмәт, онда...Гарифҗаным гына исән булып тора күрсен..

1 Егет: Әйе шул,мондый яхшы онны ,бары Гарифҗан бабай гына тарта белә.

2 Егет:Якын тирәдә андый тегермәнне, көндез чыра яндырып эзләсәң дэ таба алмассың. Тегермәнчесе турында әйтәсе дә юк.

Бабай: Әәәәй оланнар. -Илләребез тыныч булып, икмәкләребезне исән-сау ашарга насыйп булсын ...

1 Егет: Шулай булсын, амин сез дә исән-сау гына булып, тегермәндә теркелдәп торсын..

Әби: Шулай ,шулай булсын оланнар. (җырлый)

Әйдә әле, Гарифҗан, булмаса гармуныңны тартып җибәр әле...

Дөбер,дөбер әйләндерә
Тегермәннең ташлары,
Ниләр генә күрми икән
Бу адәмнең башлары.
Уйныйбыз да,җырлыйбыз да
Дуслар гаеп итмәсләр,
Халкыбызга бәхет теләп ,
Җырлап яшик иптәшләр.(чыгып китәләр)

## “АВЫЛЫМ ЧИШМӘЛӘРЕ-ӘБИЕМ ЙОЛАЛАРЫ”

**(«Су буенда, кичке уен» күренеше)**

***Гарипова Айгол Нургаян кызы***
*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*«Катнаш төрдәге “Тургай” Норма балалар бакчасы”*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:**

1)Балаларның күңелләрендә татар халкының җырлы-моңлы биюле уеннары аша гасырлар буенча үткәрелгән татар халык йола бәйрәмнәрен саклап калу;

2) Киләчәк буынны милли традицияләр нигезендә тәрбияләү;

3) Уен барышында җанлы диалог, һәртөрле сөйләшүләр, көлке, җор сүз, импровизация аша балаларның сөйләм телен үстерү, фикерләү сәләтләрен арттыру;

**Бурычлар:**

1) Балаларны уен аша татар халык йолалары белән таныштыру;

2) Киләчәк буыннарны милли традицияләрдә тәрбияләү нигезендә халкыбыз рухының аерылгысыз бер өлешен тәшкил иткән уеннарыбызның югалуына юл куймау;

3) Халкыбызның милли җыйнау, матбугатта бастыру, аларга кабаттан "җан өрү" хәстәрен күрү;

**Җиһазлау:** чишмә, эскәмия, бәби арбасы, курчак, 5 көянтә, чиләкләр, кырлы бәләк, кул эшләре (орчыклар, кашыклар, чиккән кул эшләре, тукмаклар), музыка үзәге.

Кошлар, челтерәп аккан чишмә тавышы.

Салмак кына "Тәфтиләү" татар халык көе яңгырый.

(татар халык уен коралы курай)

Әби чыга:

- Әй,бәрәкалла,чишмә тавышы..... Исәнме, чишмә! Суларың шифалы шул синең! Э-х, бар иде яшь чаклар, чишмә суы аккан кебек, челтерәп агып, үтте дә китте. Сукмагың да тапталган, йөриләр, чишмәгә йөриләр димәк. Каяле, кошлар тавышларын тыңлап ял итеп утырыйм әле. (скәмиягә утыра)

"Каз канаты"(татар халык көе) көенә көянтә-чиләк күтәргән кызлар чыгалар, аяк очларында биеп әйләнәләр дә, чишмә тирәсендә туктап калалар.

Кызлар: Әссаләмәгәләйкем, дәү әби!

Әби: Вәгаләйкем-әссәлам, кызлар!

Әминә әби: И-и, кура җиләге күк авылыбызның чибәр кызлары килгән бит!

Камилә: Нигә үзегез генә моңланып утырасыз, әбикәй?

Әминә әби: Юк балакайларым, моңланып утырмыйм, сокланып утырам, яшь чакларымны искә төшереп...

Ерактан баянда уйнаган"Авыл көе" ишетелә (татар халык көе).

Камилә: Кызлар, егетләр килә...

Гармунда "Авыл көе" (татар халык көе) уйнатып, бабай белән егетләр керәләр.

Егетләр: Сәлам бирдек чибәр кызларга!

Кызлар: Сәламегезне алдык,

Әби: кесәбезгә салдык! (көләләр)

(Егетләр үзара, әбиләр дә бар икән, дип сөйләшәләр.Раил егет килеп Әби белән кул биреп исәнләшә)

Егетләр: Шуннан?

Мәрьям: Тугыз ким уннан.

Егетләр: Шуннан?

Камилә: Утырган да шуган.

Егетләр: Шуннан?

Инзилә: Кишер белән суган.

Егетләр: Шуннан?

Дилия: Койрыгы тунган. (көләләр)

Егетләр: Әй, кызлар су алырга төшкән булып,
Нигә эшсез йөрисез?

Кызлар: Ә сез, гармун тартып, моң таратып,
Без – кызларны күзлисез! (көлешәләр)

Раил: Ю-ю- к кызлар күзләргә түгел, Ак бабай белән чишмәгә сөлге эләргә төштек.

Бабай: Әйе, яле улларым, сөлгебезне чишмәгә элеп куйыйк. (сөлгене элеп куялар)

Әминә әби: Чишмә янына төшүегез бик әйбәт булган, рәхмәт балакайлар! Суга сусаган юлчылар туктап, кулларын юып, сөлгеләргә кулларын сөртеп,сихәтле чишмә суларын эчеп,тәннәренә шифа алып, юлларын дәвам итсеннәр.

И-и-и, балакайларым, яшь чакларны искә алып, киленнәрне чакырып, кул эшләре эшләп кич утырыйкмы әллә? Мин хәзер килен – апаларыгызны чакырып алып төшәм. Балалар, без килгәнче сез китмәгез, без бик тиз килербез.(китә)

Бабай: Мин дә тик утырмыйм әле, сез килгәнче гармунымның каешын төзәтә торыйм булмаса (чишмә янынарак барып утыра да гармун каешын төзәтә башлый)

Раил: Дуслар, тик утырмыйк, әйдәгез үзебез генә калганда уйнап алабыз (кара-каршы басалар)

Раил: Камиләү!

Камилә: Әү?

Раил: Авызын дәү!

Мәрьям: Көлмә кешедән, авызың өшегән!

Инзилә: Нияз! Кабартма -дип әйт.

Нияз: Кабартма.

Инзилә: Битләреңне кабартма!

Дилия:Кәрим!

Кәрим: Әү!

Инзилә: Сөт – дип әйт.

Кәрим: Сөт.

Дилия: Авызыңны сөрт!

Алсу: Әдел!

Әдел: Әү!

Алсу: Түбә – дип әйт.

Әдел: Түбә.

Кызлар бергә: Иртәгә сине кызлар үбә! (көлешәләр)

Кызлар алгарак чыгып бергә: Эх,сез малайлар,

Түбәдәге калайлар!

Егетләр дә алгарак чыгып : Эх, сез кызлар,

Һавадагы йолдызлар!

Раил: Ярый, дуслар,үпкәләшмик, әкият сөйлим,утырыгыз.

Борын-борын заманда,

Яшәгән ди, әби белән бабай.

Аларның өйләре булган ди,таштан.

Кәҗәләре йөргән ди,баштан.

Этләре булган ди Каштан.

Сөйлимме яңабаштан?

Балалар: Ю-ю-ю-ю-юк!

Камилә: Чү, Чү, тавышланмагыз! Әнә килен-апалар төшә.

(сәхнә артында “ Әйдәгез, киленнәнр, әйдәгез”, -дигән тавыш килә) Рашидә килен бәби арбасы тартып керә.

Әминә әби: Әйдәгез, киленнәр, керегез! Авылыбызның алтын куллы киленнәренең кул эшләрен карагыз әле кызлар, сезнең дә киленнәр буласыгыз бар бит, өйрәнә торыгыз. (Кызлар кул эшләрен карыйлар) Авылыбыз тирә - юньдә оста куллы егетләре белән дан тота. Әле егетләргә дә эш алып төштек. Менә шушы орчыкларны шомартып бирерсез яме.

(Егетләргә орчыклар өләшә)

Кәрим: Бар иде яшь чаклар

Кесә тулы борчаклар.

Саламнан тәртә каерып

Чикерткә җиккән чаклар! (халык такмагы)

Була ул егетләр, шулай бит! Әйдәгез эшкә тотыныйк.

Әби: Карагыз әле, балакайларым, сез эш эшләгәндә, эш коралларыннан мин нindидер көй ишеткән кебек булдым, әллә мин әйтәм, гармунга кушылып, без дә эш коралларыннан көй чыгарып карыйкмы? (балалар һәм киленнәр үзләренә билгеләнгән эш кораллары алалар да, гармунга кушылып “Уен коралларында “ : кырлы бәләк, орчыклар, агачтан ясалган бәйләү энәләре (крючок), кашыклар белән көйгә кушылып ритм бирәләр).

Баянда “Әпипә” татар халык көе.

Көй туктагач, әби малайларның орчыкларын тотып-тотып карый, мактый. Кызларга бүләк итәләр.

Нияз торып баса да: Иң шома орчык миндә, әйдәгез “Орчык әйләндереш” уйныйбыз! Орчыкның башы кемдә кала, шул Күке булып кычкыра.

Бергә: Әйдәгез, әйдәгез...

Орчык Камиләгә туктый....

Камилә: Орчык кемдә туктый, “Чабата” биетәбез.

Татар халык көе “Чабата”

Орчык Кәримгә туктый, “Чабата” биюен бии.

Раил: Әйдәгез,парлашып җырлап-биеп алабыз.

Җырлы-биюле уен:” Куш кулым” (татар халык көе һәм сүзе)

1.Урман буйларына менәм, урман буе ямьлегә.
Бир кулыңны, мин дә бирәм, дус булырга мәңгегә.

Кушымта: Менә сиңа уң кулым (уң кулларын алга сузалар)
Менә сиңа сул кулым (сул кулын алга сузалар)
Уң кулым да, сул кулым да –
Менә сиңа куш кулым

(кара-каршы чәбәклиләр, көйгә култыклашып әйләнәләр).

2. Алма бакчасына кереп, алма ашыйсым килә,
Син алмасы – мин чәчәге булып яшисем килә.

Кушымта: Менә сиңа уң кулым (уң кулларын алга сузалар)
Менә сиңа сул кулым (сул кулын алга сузалар)
Уң кулым да, сул кулым да –
Менә сиңа куш кулым

(кара-каршы чәбәклиләр, көйгә култыклашып әйләнәләр).

Чишмә буенда бәби бишеге тирәсендә кайнашкан әби: Ай, рәхмәт яугырлары! Бигрәкләрдә булдырып җырлап уйныйсыз инде...Киленнәр әллә сез дә берәр уен уйнап курсәтәсезме, әле онытырга өлгермәгәнсездер?

Киленнәр: Сез рөхсәт итсәгез, бик тә рәхәтләнеп уйныйбыз.

“Яулык салыш” уены. (татар халык бию көе)

Уен тәртибе: Түгәрәктә биеп йөриләр, бер килендә кульяулык була, көй беткәндә яулыкны бер кешегә сала, яулыклы кеше җәза үти.

(Уен барышында , бәби елаган тавыш ишетелә. Рашидә килен йөгереп барып бәбиен ала “Үчтеки” уенын уйнатып ала. Бәби тагын елап җибәрә.

(Баланы уянгач багу такмагы “Үчти-үчти сикерткәндә” Нәкый Исәнбәт “Балалар дөньясы”(“Балалар фольклоры” җыентык,1нче бүлек,10бит.)

Рашидә килен: Әле йокысы туймаган, “Бишек җыры”на йокларга ярата ул әйдәгез, бергәләп җырлыйбыз.

“Бишек җыры” татар халык көе һәм җыры.

1. Әлли – бәлли итәр бу,
   Мәдрәсәгә китәр бу.
   Тырышып сабак укыгач,
   Галим булып җитәр бу.

(Рашидә килен бәбиен бәби арбасына сала)

Әминә әби: Балалар, киленнәр, дөньябызны онытып уйнап та ятабыз бит, кояш баеп килә түгелме?

Барысы: Әйе, әйе...

Әби: Балакайларым, исегездә тотыгыз, кояш баегач беркайчан да чишмәдән су алмагыз, ярамый! Чишмә янын һәрвакыт чиста тотыгыз, чишмәләрне саклагыз, бүген уйнаган уеннарны онытмагыз, ишек алларында дусларыгыз белән, өйдә әти-әниләрегез белән уйнагыз яме.

Бергә: Рәхмәт сиңа, чишмә!

Егетләр чиләк-көянтәләрне кызларга кияргә булышалар.

“Су юлы” (татар халык көе) көенә чыгып китәләр.

**АУЛАК ӨЙ**

***Гобәйдуллина Фәридә Илдус кызы***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*Килдебәк авылының “Кояшкай” балалар бакчасы”*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесы*

**Максат:**балаларны халкыбызның милли гореф – гадәтләре белән таныштыру, үз халкы белән горурлану хисе тәрбияләү.

**Бурычлар:**милли җырлы-биюле уеннар аша балаларда туган телгә карата ярату хисен тәрбияләү; өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәтү; йола һәм гореф – гадәтләрнең алыштыргысыз тәрбияви чара булуын балаларга җиткерү.

**Зал бизәлеше:** зал түрендә өйнең эчке күренеше, анда борынгы сандык, чиккән мендәрләр, сөлгеләр, идәндә тукыган паласлар җәелгән.

**Бәйрәмнең барышы:**

Залда өй күренеше, залның икенче башында чишмә, агачлар....

Әби белән бабай сөйләшеп керәләр.

**Әти:** Әй, әнисе сиңа әйтәм, эш бетте, әллә мин әйтәм, Сабага җизниләргә кунакка барып кайтыйк микән?

**Әни:** Бик яхшы булыр әтисе.

**Әти:** әйдә аласа тизрәк әзерлән!

**Әни:** Тукта инде, тукта, өйне кемгә калдырыйк икән әтисе? Күрше Бибинур әби чирләп тора бит!

**Әти:** Нигә юкка кайгырасың, Гүзәлиябез олы кыз бит, аны өй сакларга калдырып була инде. Карт кыз янына яшьләр килми инде, әнисе.

**Әни:** Ярар, алайса, шулай итәрбез. Кызыбызны кисәтеп калдырыйк!

**Әти:** (Гүзәлияне чакыра) Кызым, әй, кызым, кер әле.

**Әни:**Гүзәлия кызым, без Сабага җизниләргә кунакка барабыз. Берүк өйне сакла, сеңелең Зөһрәгә дә күз-колак булырсың. Егетләр, кызлар җыеп аулак өйләр ясап ята күрмәгез!

**Гүзәлия:**Юк, юк әни тыныч кына йөреп кайтыгыз!

(Әти белән әни саубуллашып чыгып китәләр)

**Зөһрә керә:** Гүзәлия апа, мин барысында ишетеп тордым. Әйдә апа аулак өй ясыйбыз.

**Гүзәлия:**Абау! Әти белән әни мине олы кыз диеп, күз-колак булырга кушып калдырдылар бит. Ачуланмаслармы икән? (Зөһрә үпкәләгән кебек басып тора)

**Гүзәлия:** Я ярый, чакырсаң чакырырсың  инде иптәш кызларыңны!

**Зөһрә:** (апасын кочаклап ала) Рәхмәт сиңа апа, хәзер тиз генә суга тошеп менәм чишмәгә шунда кызларныда чакырам.

**Гүзәлия:** Ә мин тиз генә өйне тәртипкә китереп куя торам. Кунаклар килгәндә өй чиста, күркәм булырга тиеш.

(Зөһрә чиләк- көянтәсен алып әкрен генә әйләнә, залның икенче башына чишмәгә бара.Су ала, икенче кызда суга килә, тагын икенче кыз килә, шулай берничә кыз килә. Ул арада агачлар артыннан посып кына бер малай аларны күзәтә һәм сызгырып иптәшләрен чакыра ).

**1 кыз:** Ай кызлар егетләр килә, нишлибез.

**1 егет:** Хәерле көн кызлар! Көн шундый эссе, сусадык су эчермәссез микән чиләгегездән.(1 кыз янына килә)

**2 кыз:** Рәхим ит күпме кирәк шуның кадәр эч (чишмәгә күрсәтә)

**1 егет:** Ә минем сезнең чиләктән эчәсем килә иде.

**3 кыз:** Ә бәлки минем учымнан эчәрсең?

**1 егет**: (Сөенеп) бик рәхәтләнеп. (1 кыз учы белән су алада егет су эчәргә дип кызның кулына иелә шул вакыт кыз учы белән суны егеткә сибә. Барысыда көләләр.) Ә-ә-ә әле сез шулаймы? (Бармак яный). Кызлар, егетләр әйдәгез бер җырлап алыйк әле. (Кара-каршы басалар)

**Кызлар:** Ак алъяпкыч билләрдә,

Җилфердәми җилләрдә.

Сандугачларда сайрамый

Сез булмаган җирләрдә

**Малайлар:** Үзләренең коесы бар

Безгә килеп су ала.

Чиләген тутырып алада

Көлә-көлә югала.

**Бергә:** Ямьле Мишә буйлары

Дулкынлана сулары.

Агачларда кошлар сайрый

Сагындыра шулары.

**4 кыз:** Әйдәгез назалы уйнап алабыз.

***Наза уены***

1. Синмени, килдеңмени?

Зәйтүн гөле өч тармаклы,

Аның берсе синмени?

*Кушымта.* Алсуланып кояш чыга , кояш чыга таң аткач,

Ник сызгырып уятмадың, уятмадың ошаткач?

2. Исемнәре Нургата,

Синең кебек ялкау бака

Күпер астында ята.

3. Кара каеш ник будың?

Эш эшләргә ярамагач,

Җан көйдереп ник тудың?

4. Исемнәре Алтынбай.

Бер битендә балкый кояш,

Бер битендә балкый ай.

**Зөһрә:** Кызлар, онытып торам әйдәгез тизрәк кайтыйк, бездә бүген аулак өй, әниләр кунакка киттеләр.

**5 кыз:** Шулаймыни (сөенеп), кызлар кул эшләрегезне алыгызда әйдәгез Зөһрәләргә.

**2 егет:** Безнедә кертәсезме соң?

**6 кыз:** Тәртибезгә карарбыз инде.

(Кызлар чиләкләрен алмакчы булалар егетләр тиз генә чәчәкләр алып кызларга биреп чиләкләрне үзләре алалар.  Өйгә кадәр бергә кайталар Зөһрә чиләкләрен алып өйгә керә, ә башкалар чыгып китәләр ).

**Гүзәлия:** Кайтып җиттеңме? Я ничек иптәшләрең киләбез диделәрме? (Ул арада кызлар киләләр). Бәрәч, кызлар килеп тә җитте. Каршы ал сеңлем  кунакларны

**Зөһрә:** Бәйрәмсез бик күңелсез бит,

Күңелсездер сезгә дә.

Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә

Кирәк һәммәбезгә дә.

Бәйрәмнәр бик күп болай да.

Ә шулай да, ә шулай да.

Халкыбызның йолаларын

Искә төшерик әле,

Күңелле итеп бүген

“Аулак өй “үткәрик әле.

( Җиңелчә көй астында кызлар утырып чигү чигә башлыйлар)

**Гүзәлия:** Кызлар эшләгәндә берәр җыр җырласак эшләребеәдә тизрәк эшләнер , күңелле дә булыр иде. Әйдәгез әле “Сөлге чигәм”җырын җырлыйк.(җыр башкарыла)

***Сөлге чигәм***

Сөлге чигәм асыл җепләр белән.

Йөрәк хисен салып бу җырга.

Насыйп булса иде бу бүләгем

Мәйданнарда җиңгән батырга.

Ефәк җепләр белән сөлге чиктем,

Уртасында чәчәк-гөл генә.

Җиңеп алсаң, егет, бу бүләкне,

Вәгъдә бирәм сиңа мәңгегә.

(Егетләр җырлаган тавыш ишетелә)

**7 кыз:-**Кызлар! кызлар! Егетләр килә түгелме? Кертәбезме?

**8 кыз:-**Кертик,кызлар! Әзрәк утырырлар да кайтып китәрләр.

**Егетләр**: исәнмесез,кызлар-йолдызлар!

**Кызлар**: исәнмесез! Егет сезгә кем кирәк?

**Егетләр**: Кара кашлы кыз кирәк! Кызлар ачыгыз инде ишегезне!

**Кызлар**: Ач булсагыз, ашап килегез,бер кочак акча алып килегез!

**Егетләр:** Акча бездә бер букча.

**Кызлар:** Ишек бавы бер алтын

Безнең кызлар мең алтын!

**Егетләр:** Кызлар кертегез инде. безнең дә уйныйсыбыз килә.

**Кызлар:** Бусага ялын түләмичә кертмибез!

**Егетләр:** Түлибез, түлибез, кертегез инде!

**Кызлар:** Ялыгыз нинди?

**Егетләр** (берәм-берәм): Мин биим, мин җырлыйм, мин такмак әйтәм!

**Гүзәлия**: Ярый инде керсеннәр! (Егетләр кереп исәнләшәләр)

**1 егет:** Исәнмесез саумысез?

Нигә кәҗә саумыйсыз?

Әтәчегез күкәй салган

Нигә чыгып алмыйсыз?

Аның каршысына бер кыз йөгереп чыга:

**1 кыз:** Әй, Әпсәләм, Әпсәләм!

Сәлам бирдем Әпсәләм.

Синнән безгә тиештер бит

Вәгаләйкемәссәләм!

Кара-каршы күмәк җырлы уен***” Челтәр элдем читәнгә” уйнала.***

Егетләр бер рәткә, кызлар аларга каршы басалар. Кара-каршы җырлыйлар.

***Кызлар.***

Челтәр элдем читәнгә, җилфер-җилфер итәргә.

***Егетләр.***

Без килмәдек буш китәргә, килдек алып китәргә.

***Кызлар.***

Алын алырсыз микән, гөлен алырсыз микән?

Урталарга чыгып сайлап, кемне алырсыз микән?

***Егетләр.***

Алларын да алырбыз, гөлләрен дә алырбыз,

Күңелебезгә кем ошаса, шуны сайлап алырбыз.

**Гүзәлия:** И,безнең яшьләр дә бик булдыра икән! Аулак өйгә килгәч төрле уеннар уйныйк идек. Мәсәлән: “Капкалы” , “Такмак әйтү”, “Түбәтәй” һәм башка төрле уеннар.

**2 кыз:** Әйдәгез “Түбәтәй” уенын уйныйбыз.

**<u>“Түбәтәй уены”.</u>**

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Түбәндәге җырны җырлый-җырлый, түбәтәйне бар-берсенә бирәләр:

Түбәтәеңне кигәнсең, бик ераклардан килгәнсең,

Төскә матурлыгың белән шаккатырыйм, дигәнсең.

Түп – түп-түбәтәй, түбәтәең укалы.

Чиккән матур түбәтәең менә кемдә тукталды.

Җыр ахырында түбәтәй кемдә калса, шуңа җәза бирелә (бии, җырлый, әтәч булып кычкыра һ. б.). Уен шулай дәвам итә.

**2 кыз:“Йөзек салыш”** уенын бергәләп уйнап алыйк!

“Йөзек салыш” уены уйнала.

**3 кыз:** Үзем саныйм.

Зәй. Зәй, Зәйнәбем.

Атны кайда бәйләдең?

Алмагачка бәйләдем.

Алма төште шап итеп,

Зәйнәп чыкты ялт итеп! (Санап чыккан бала йөзек сала)

(Кемдә йөзек , шул сикереп чыга)

**4 кыз:** Нинди җәза бирәбез?

**2 егет:** Әтәч булып кычкырсын (уен ике мәртәбә уйнала)

***2 нче отылган бала шигырь сөйли:***
Әбием аулак өйләрдә
Халык җыры җырлаган
Халык җыры - бай мирас, дип
Бу көнгәчә саклаган!

***3 нче отылган бала*** иптәшләренә үзе шигъри юллар белән җәза бирә:
Игътибар белән тыңлагыз
Җәзаны үзем бирәм
Матур – матур сүзләрне
Кайсыгыз күбрәк белә.

Түгәрәккә утырган балалар чиратлашып матур – матур сүзләр әйтәләр: алмам, күгәрченем, былбылым, йолдызым, матурым, алтыным, чибәрем, йомшагым һ.б.

***4 нче отылган бала:*** Кунак килсә сый – хөрмәтсез
Камыр – ашсыз булмый бит.
Кем нинди ашамлык белә?
Я, дуслар, әйтеп карыйк
Татар халык ашларын
Без тукталмыйча саныйк.
Балалар халык ашларын әйтешәләр: чәк – чәк. өчпочмак, коймак, тәбикмәк, бәлеш, кыстыбый, кош теле һ.б.
***(Әти белән әни кайталар, кунаклар белән исәнләшәләр)***
**Әни:** Әллә аулак өй оештырганнар инде (ачуланып)
**Әти:** Ярар инде, әнисе, ачуланма, яшь вакытта үзебездә аулак өй оештырырга бик ярата идек. Әйдәле кунак кызларын, кунак малайларын күчтәнәчләр белән сыйлыйк. (Кулы белән балаларга “во!” дип күрсәтә) Үзебезнең матур йолаларыбызны, гореф-гадәтләребезне онытмагыз!
**Әни:** Җәй көннәрендә эштән соң- болынлыкларда үткәрелгән “Кичке уен”ны, кышкы озын кичләрдәге ”Аулак өй” кебек матур бәйрәмнәрне сез, балалар, киләчәк буыннарга да җиткерергә тиешсез!

Иии, онытып та торам бит. Кунактан күп итеп күчтәнәчләр алып кайткан идем. Әйдәгез, ак өйгә чыгып, күчтәнәчләр белән чәй эчеп алыйк.

***Алга бер бала чыга:***

Дуслык җебе өзелмәс ул

Халык моңы бар җирдә

Безнең мондый очрашулар

Истә калсын гомергә.

(Балалар залдан татар көенә биеп чыгып китәләр.)

## Әбиемнең серле сандыгы!

**Рәхимова Гөлинә Рәис кызы**

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*
*Хәй Вахит исемендәге "Мәмдәл гомуми урта белем бирү*
*мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе"*

**Бәйрәмнең максаты:** Күңел ачу чараларында актив катнашырга омтылыш формалаштыру. Халкыбызның гореф-гадәтләрен, буыннан-буынга истәлек булып калган әйберләрнең исемнәрен хәтерләрендә калдыру. Шигырь һәм уеннар аша балаларны татар халкының үткәне белән таныштыру. Нәфасәти зәвыкларын үстерү, әйләнә – тирәдәге предметларны бәяли белергә өйрәтү. Татар халкына мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү.

Сәхнә өй кебек итеп бизәлгән, тәрәзәләрдә борынгы челтәрләр, тәрәзә араларында кызыл башлы сөлгеләр,чиккән кашагалар, криватка челтәрле япма ябылган, чигүле мендәрләр куелган. Түрдә сандык, самовыр, чынаяклар,татар халык ашлары куелган. Балалар, тәрбияче милли киемнәр кия.

**Тәрбияче**: Исәнмесез балалар (балалар исәнләшә). Без бүген сезнең белән сөйгән халкыбызның күңел бизәкләре, йолалары, уеннары, гореф-гадәтләре белән танышырбыз.

Хәтердән курыкма син!

Үткәнеңне онытма син!

Бел син ерак бабайларның,

Ничек итеп көн иткәнен.

Нинди уйлар,нинди моңнар,

Безгә калдырып киткәнен.

Балалар, без бүген сезнең белән кунакка барабыз. Кемгә дисезме? Бибинур әбиегезгә! Ул әнә теге бизәкле капкалы йортта яши. Әйдәгез, минем арттан барыгыз да. (Тәрбияче балалар белән бер түгәрәк урап  чыга һәм капка янына килеп басалар)

Әйдәгез, балалар, капкага серле сүзләребезне әйтеп карыйк

(Барысы бергә): Әй капка,капка, Сәлам бирдек әссәләм. Синнән безгә тиештер бит, вәгаләйкем-әссәлам. (Капка ачыла, балалар өй эченә узалар. Бибинур әби өйдә булмый, оныгы Айгөл сандык өстенә утырып җырлый-җырлый сөлге чигеп утырган чак була)

**Бала башкаруында җыр “Сөлге чигәм”**

**Тәрбияче**: Исәнме, Айгөл. Күрәм, Бибинур әби өйдә юк.

**Айгөл**: Әбием ахирәтләренә утырмага китте. Ул озак тормас кайтып җитәр.

**Тәрбияче**: Без Айгөл балалар белән әбиеңнең серле сандыгы белән танышырга дип килгән идек.

**Айгөл**: Ул әбиемнең серле сандыгы мине дә күптәннән кызыксындыра. Әйдәгез, ачып карыйк әле сандыкны. (Сандык янына килаләр)

**Айгөл**: Әбиемнең матур сандыгы!

Нинди серләр саклый икән ул?

Гөмер буе җыйган хәзинәме,

Әллә инде күңел бизәгеме,

Нинди серләр саклый икән ул?

**1 бала**: Әбиенең серле сандыгын

Бер ачасы иде, ачасы

Әби-баба белгән йолаларны,

Халкыбызның күңел җәүһәрләрен

Бер ачасы иде, ачасы.

**2 бала**: Әбиемнең матур сандыгы

Кызыктыра мине күптәннән.

Ачыйк, әйдә әбекәйнең сандыгын

Яшь буынга мирас булып,

Бер хәзинә калсын үткәннән.

(Айгөл белән бер бала сандыкны ачалар)

**Тәрбияче**: Ай-һайниләр генә юк бу серле сандыкта! Чынлап та сандык тулы хәзинә икән. Балалар, карагыз әле, бу әби-бабаларыбыздан калган иң изге китап – Коръән. Әби-бабаларыбыз Коръән укып, тәзбих тартып, балаларына, оныкларына якын туганнарына изге теләкләрен, догаларын юллаганнар.

**“Тамчы” дигән  җырлы-биюле уен башкарыла.**

(Балалар түгәрәккә басып җырлап йөриләр)

Тамчы там, тамчы там,

Тамуыңны яратам.

Тамган тамчыларга карап,

Мин җырларга яратам.

(җыр куплетыннан соң кара-каршы бииләр)

Тама тамчы, тама тамчы,

Тама тамчы түгелме?

Тамчы тамса, матур язлар

Килеп җитә түгелме?

(Парлашып әйләнәләр, бию беткәч, балалар утыралар)

**Бибинур әби: (**кайтып керә) Нинди моңлы көй ишетелә дисәм, үзебезнең балалар җырлый икән.

**Тәрбияче**: Исәнмесез, Бибинур әби. Балаларны сезнең серле сандык белән таныштырырга дип килгән идек.

**Бибинур әби**: Мин бик шатмын балалар, сезнең татарларның милли киемнәренә һәм халкыбызның күңел бизәкләре белән кызыксынуыгызга. Әйдәгез бергәләшеп карыйк, күптәннән ачканым юк иде инде сандыгымны?

(Бибинур әби сандыктан китап ала,барысы бергә өстәл артына утыралар)

**Айгөл**: Ай, нинди зур китап!

**Бибинур әби:** Әйдәгез карыйк әле, бу серле китапны? Татар милли киемнәре кигән балалар рәсем бу биттә. Нинди матур киемнәр! Балалар минем сандыгымда да шундый милли киемнәр бар. Карап китик әле үзләрен. (Сандыктан калфак ала, Айгөлгә кидерә) Кызым бу калфак сиңа бигерәк килешә.

**3 бала.** Серле сандыкның эчендә

Саклана чиккән калфак.

Ул калфакны әбекәем

Кадерләп кигән һәрчак.

Милләтемнең нуры анда:

Ука, чугы, чәчәге.

Кадерләп саклагыз бер үк

Әбиемнең калфагын!

**(музыка уйный. Татар милли киемнәре кигән балалар “Шома бас” дигән җырлы-биюле уен уйныйлар)**

**Бибинур әби**: Ә болары Казан сөлгеләре. Әбиләребез үзләре тукып эшләгән. Кайсы гына егетнең иңенә ятмаган да нинди генә батырларга бүләк булмаган бу сөлгеләр.

**4 бала**. Сөлге чиктем асыл җепләр белән
Уртасында чәчәк-гөл генә.
Насыйп булса иде бу бүләгем
Авылыбызның батыр егетенә.

**(бер бала сандыктан түбәтәй ала, шигырь сөйли)**

**5 бала**.Балкып тора түбәтәйләр,
Энҗе бөртекләр белән.
Алар монда килгән ия
Чын әкият иленнән.

**Тэрбияче:** Түбәтәй-төрки халыкларда ирләрнең төп баш киеме. Түбәтәй бары тик гади тукымадан гына тегелә. Түбәтәй чигә,тегә белгән кеше алтын куллы оста саналган. Балалар әйдәгез җырлы-биюле “Түбәтәй” уенын уйнап алыйк.

**(балалар түгәрәкләнеп басалар. “Түбәтәй”җырын җырлый-җырлый түбәтәйне бер-берсенә бирәләр)**

**Бибинур әби:** Менә монысы алъяпкыч. Татар кызларының алъяпкычлары канатлы булырга тиеш. Чиккән алъяпкычлар зифа буйлы кызларга бигрәк тә килешеп тора. Киләчәктә сез дә шулай милли алъяпкычлар ябып йөрерсез әле.

**(алъяпкыч кигән кыз шигырь сөйли)**

**6 бала**. Әй алъяпкычым, алъяпкычым,
Бигрәк матур ла бизәкләре.
Сырлап куйган гөлле чәчәкләре,
Әй, өзәдер лә үзәкләрне,
Күр, нурландыра йөзләремне.

(Бибинур әби сандык тартмасыннан чиккән кулъяулыкка төрелгән йөзек ала)

**Бибинур әби**: Бу йөзек - әбиемнән калган истәлек. Мин аны бик кадерләп саклыйм. Аулак өйгә җыелгач “йөзек салыш” уенын уйный торган идек.

**Айгөл**: Әбекәй, безгә дә өйрәт әле ул уенны?!

**Бибинур әби**: Әйдәгез, барыгыз да тезелешеп утырыгыз. Учларыгызны тотыгыз. Мин сезгә йөзек салам. Йөзек кемдә икәнен сизсәгез, аңа берәр “җәза” бирәбез (йөзек сала). Йөзек кемдә сикереп чык.

**Балалар**: Йөзек – Искәндәрдә.

**Тәрбияче**: Нишләтәбез Искәндәрне?

**Балалар**: Җырлатабыз.

**(бала бии-бии җырлый, уен бер ничә тапкыр уйнала)**

**Айгөл**: Әбиемнең сандыгында тагын ниләр калды икән? (Айгөл ниндидер төргәк чыгара). Нәрсә икән бу? (төргәкне сүтә)

**Бибинур әби:** Монысы бабагызның истәлеге. Сугышка киткәндә: "Мин кайтканчы берәүгә дә бирмә, саклап тот", - дигән иде. Үзе генә әйләнеп кайта алмады шул!

**Тәрбияче**: Татар халкы элек-электән җырга – моңга бай булган. Ул үзенең кайгысын да, шатлыгын да җыр белән уртаклашкан.

**7 бала**:Өстәлемдә гармун тора,
Бабаемның гармуны.
Кулларыма алып тартсам,
Агыладыр моңнары.

**8 бала**.Уйнап җибәр гармуныңны
Дуслар бергә җыелсын.
Белик яшәүнең кадерен
Тойыйк тормыш җылысын.

**Тәрбияче:** Әйдәгез әле, гармун тавышын тыңлап үтик.

**(Гармунда милли көйләр башкарыла)**

**Тәрбияче**: Күпме мирас! Һәркайсы затлы хәзинә. Бу хәзинәләр сандыкларда гына сакланырлык кадерле байлык. Безнең әби-бабаларыбыздан калган милли хәзинә. Ә хәзер тылсымлы сандыкны ябыйк, аның әле серләре күп. Сезнең белән кабат Бибинур әбигә кунакка килергә язсын.

Адаштырмас маягыбыз-мирас,
Юлда юлдаш-туган телебез!
Туган телне,җирне сөйсәк кенә
Матур булыр алгы көнебез!

**(кичә "Туган телем" җыры белән тәмамлана)**

# “ИСЕМ КҮҢЕЛ КӨЗГЕСЕ”

(исем кушу йоласы)

**Гәлләмова Рүзилә Рәүф кызы**
**Шәвәлиева Нәкыя Мөхәмәтвакыйф кызы**

*Яшел Үзән районы Осиново авылы бюджет*

*учреждениясы 53 номерлы катнаш төрдәге*

*"Шатлык" балалар бакчасы*

*Кыз бала исеме йолдыз балкышына охшасын,*

*Назлы гөлчәчәктәй нәфис булсын.*

*Ир-ат исеме кылычлар чыңлавын хәтерләтсен,*

*Аның мәгънәсендә гакыл гәүдәләнсен.*

*Рәсүл Гамзатов.*

**Максат:**

1.гореф-гадәтләребезгә, гаилә традицияләренә кызыксыну уяту;

2.буыннар бәйләнеше,исемнәр, аларның килеп чыгышы, әһәмияте турында күзаллауларын тирәнәйтү;

3.гаиләң белән горурлану хисләре, өлкәннәргә ихтирам, хөрмәт тәрбияләү;

**Бурычлар:**

Белем бирү: Татар халкының борынгыдан килгән йоласы – “Исем кушу” турында сөйләшү. Исемнәрнең мәгънәләре турында аңлату.

Үстерү: Милли йолалар турында белемнәрен киңәйтү.

Тәрбияви: Балаларда татар милләтенең йолалары, традицияләренә карата кызыксыну уяту. Бер-берсенең исеменә хөрмәт тәрбияләү.

**Алып баручы:** Халкыбызның рухи мәдәниятенә алып керүче бер чыганак- ул татар халкының милли, күркәм йолалары. Аларның берсе – исем кушу йоласы. Ул йола әле дә үткәрелә. Хәзерге буын балалары милли хәзинәбезне, ана телен саклап калсыннар өчен.

Исәнмесез!- диеп башлыйм әле,
Танышу бит шулай башлана.
Сезнең белән очрашканга, дуслар,
Күңелкәем шундый шатлана!

Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар! Бүген без сезгә татар гаиләсендә уза торган йолаларның берсе - Исем кушу йоласын күрсәтербез.

Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре була. Татар халкының Сөмбелә, Сабантуй, Нәүрүз, Нардуган, Корбан гаете, Ураза бәйрәме, каз өмәсе, исем кушу бәйрәмнәре елдан – ел камилләшә, кызыклы итеп оештырыла.

Исем кушу йоласы гаиләдә зур вакыйга. Бала тугач та, бер атна - ун көн эчендә башкарыла.

Талгын көй яңгырый. (тал бишек)

Әби белән Әмир (утыралар)

**Әмир:** Әби бездә бүген нинди зур бәйрәм?

**Әби:** Улым, бездә зур шатлык. Гаиләгә шатлык булып, өмет һәм куанычлар өстәп дөньяга олы зат туды.Без бүген аңа исем кушабыз. Кунаклар килгәнче улым сөйләшеп алыйк әле.

**Әмир:** Әби, ә миңа исемне кем кушты?

**Әби:** Мулла абзый кушты. Аны кетеп утырыш улым.

Балам, сабыйга нинди исем бирәбез соң? Бик матур бер исем кирәк булыр инде безнең энекәшкә.

**Әмир:** Мин таптым, мин таптым Рамазан булсын

**Бергә:** Булсын, булсын бик күркәм исем.

**Әнисе:** Бүген бездә бәйрәм булыр

Исем кушарбыз уйлап.

Яхшы исем, матур исем

Мәгънәсе булыр чынлап.

(ишек шакыган тавыш) Мулла килә.

**Әби:** Әйдәгез кадерле кунаклар, рәхим итегез, түрдән узыгыз.

**Мулла:** Әссәләмәгәләйкүм!

Әби белән Муса: Әссәләмәгәләйкүм!

**Мулла:** Хәерле көн сезләргә.

Исем кушу йоласын

Башлап җибәрик, әйдә.

**Әнисе:** әйдәгез, рәхим итегез.

**Мулла:** Азан әйтә. Әти - әни, туганнар сез ризамы Рамазан диеп исем бирергә.

**Барысы бергә:** Риза, риза

**Әнисе:** Саклыйк буыннарга рухи хәзинәне,

Бишек җыры – күңел көзгесе.

Киләчәктә шәхес булыр өчен

Тәүге адым, яшәү өлгесе.

**Әнисе:** ә хәзер барыгызны да бәби ашына чакырам.

**<u>Алып баручы:</u>** бишек җырлары - безнең киләчәгебезгә нигез сала. Балаларны шул могҗизалы җырлардан мәхрүм итмәсәк иде!

Исем кушу йоласы ахырына да якынлаша. Килгән кунаклар өчен бүләгебез дә бар. Сезгә кадерле кунаклар бездән музыкаль сәлам.

Рәхим-шәфкатьле булсын өлкәннәр,

Җанны җылытсын иман нурлары.

Әй, нәни кешем,өмет йолдызы,

Имин, уң булсын барыр юлларың.

Кул сузам сиңа, елмаеп дәшәм:

Якты дөньяга ямь биреп яшә,

Җиргә син кирәк, илгә син кирәк,

Көнгә син – терәк, исәнме, Кеше!

Бала туды. Дөньяга яңа кеше килде.Аңа кушу өчен исем кирәк. Матур исем, мәгънәлеисем, зәвыклыисем – кыскасы әйбәт исем.

Татар халкы элек-электән яңа туган сабыйга исем кушуга зур җаваплылык белән караган. Исеме җисеменә туры килә торган матур эчтәлекле, аһәңле, җиңел һәм анык әйтелешле исемнәр бирергә тырышкан. Яңа туган сабыйга кушу өчен исем эзләгәндә, ул исемнең җыйнак, җиңел әйтелешле, яхшы мәгънәле һәм аһәңле булырга тиешлеген истә тоту зарур булган. Күркәм исемнәребез күп булганга, һәрбер ата-ана шулар арасыннан үзенә ошаганын, зәвыгына туры, күңеленә хуш килгәнен, әлбәттә, заман таләпләренә җавап бирә торганын сайлый алган.

**Уен “Исеменә карап җисеме”**

Исемнәр үзе бер тарих.Аларны ачыклауга галимнәр зур әһәмият бирә. Әйдәгез, гыйбрәт алыр өчен генә кайбер исемнәрнең мәгънәләренә игътибар итик әле.

Балалар сезнең алдыгызда сүрәтләр(ай, көзге, тимер,акча, хан, китап, ике дус). Мин сезгә исемнәр укыйм, ә сез аларның мәгънәсен рәсемгә туры китереп җавап бирегез.

Айсылу – ай;

Әмирхан – хан;

Галим – китап;

Илдус – дуслар;

Гүзәл – көзге;

Байбулат – акча;

Тимерхан – тимер.

Алып баручы: Балага исем кушу- җиңел эш түгел. Бала тугач, өйгә, гаиләгә яңа ямь, юаныч, куаныч, бәхет өстәлә. Шуның белән бергә яңа туган сабый ата-анасына өстәмә мәшәкатьләр дә

китерә. Аларның иң беренчесе— исем кушу. Балага нинди исем бирергә? Бу сорау һәрбер ата-ананы, баланың өлкән туганнарын, кардәш-тумачаларын уйландыра, борчый. Чөнки исем кешегә бер генә мәртәбә бирелә һәм ул аның гомерлек юлдашына әверелә. Һәр кеше үз исеменә шулкадәр күнегә ки, ул аның туган теленең иң якын, иң газиз, иң кадерле сүзе булып тоела. Татар халкының йолаларын, гореф гадәтләрен онытмасак иде.

## “ТУГАН НИГЕЗГӘ ҖЫЕЛУ” ЙОЛАСЫ

***Зәйнакова Гөлфинур Исрафил кызы***
*Татарстан РеспубликасыАрча муниципаль районы*
*“Арча 10нчы балалар бакчасы”*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесы*

Бәйрәмчә табын әзерләнгән. Әби бәлеш тотып өстәл янына килә. Бабай баянда татар халык көен уйнап керә.

Бабай:Буген минем туган көн
Бәйрәм була торган көн,
Үткән әз-мәз тормышымны
Бәйрәм итә торган көн.

Әби: И бабасы, шушы яшькә җитәргә дә насыйп булды бит.

Бабай: Гомер үтсә дә күңел унсигездә бит әле, әбисе.

Бергәләп “Картаямени соң йөрәк” татар халык җырын башкаралар.

Картаямыни соң йөрәк,
Маңгайлар сырланса да,
”Үтте яшьлек-җүләрлек” дип
Җырларда җырланса да.

МУЗЫКА

Әби: Балаларда кайтып җитә торгандыр, юлда дигәннәр иде.

Бабай тәрәзәгә карап: Әнә кайтып җиттеләр, ахрысы.

*Раиль, Вика, Руслан бүләкләр, шар тотып керәләр.*

Бергәләп исәнләшәләр.

Әби: Исән сау гына кайтып җиттегезме, балакайлар?

Руслан: Бабаем, әбием мин сезне шундый сагындым!

Туган көнең белән сине, бабай,

Чын күңелдән котлыйбыз.

Бәхет, шатлык, сөенеч,

Озын гомер телибез.

*( Бабайсына шар тоттыра)*

Раиль: Әти, сиңа бүләккә матур итеп чигелгән түбәтәй алып кайттык. Кабул итеп ал әле. Кая киеп тә кара әле. Бик килешеп тора икән үзеңә.

Бабай: Рәхмәт , балаларым!

Вика: Әнкәй, сиңа да бүләгебез бар бит. Шушы бизәкле яулыкны җилкәләреңә салып чын татар әбие булып йөр әле.

Әби: Рәхмәт яусын, Виктория, кызым. Әйдәгез, мул табыннарыбыз әзер. Тургә узыгыз!

Раиль: Әйе, озакламый абыйларда, сеңлебез дә кайтып җитәрләр.

Вика: 4 оныгың, 3 балаң белән табыннарыбыз тагын да түгәрәкләнер.

Руслан: Бабай, мин сиңа бүләккә бер матур җыр әзерләдем.

Бабай: Әйдә әле улым, җырлап җибәр, мин көен тартырмын.

*Бабай баянда уйный, Руслан җырлый.*

*ҖЫР “Иң шәп бабай”*

1.Сөенеп туймас балачак,

Иң бәхетле балачак.

Бабай белән үткән кичләр

Мәңге истә калачак.

Яратабыз сине бабай,

Син бит безнен бер генә.

Нурлы йөзле, шат күңелле

Иң шәп бабай син генә!

Бабай:Рәхмәт, балакаем! Улым, син – безнең нәсел дәвамчыбыз. Безнең нәсел – гармунчылар нәселе. Бездән бүләк – беренче гармуныңны кабул итеп ал әле.

Руслан шатланып: Нинди яхшы бүләк бу, бабай. Рәхмәт! Зур үскәч миндә гармунчы булырмын. ( уйнап карый)

МУЗЫКА

Раиль:Бар гаилә бергә җыелдык

Барыбыз бергә буген.

Бергә шундый күңелле.

Әллә шулай түгелме?

Вика: Беркем читтә калмасын

Безнең белән җырласын.

Гаилә белән җыелган көннәр

Онытырлык булмасын.

ҖЫР “Әти – әни”

Әби: Сөбханалла! Балаларыбыз,оныкларыбыз да үзебез шикелле җыр – моңга гашыйк. Үзебездә гел сәхнәдә бит! Күп еллар районыбыз мәдәният йортларын җитәклибез, халкыбызның милли традицияларын түкми чәчми яшь буынга тапшыру өстендә эшлибез. Татар моңы безнең күңелләрдә!

ӘБИ-БАБАЙ ҖЫРЛЫЙ, башкалар кушылалар.

1.Әй, дусларым, сезгә әйтәм, –
Гармунчы булсын ярың;
Гармунчының буыннары
Саен мәхәббәт аның.

Кушымта:
Суда, суда,
Суда йөзәләсеңме?
Мин сине күрми түзәлмим,
Ә син түзәләсеңме?

2.Утырмагыз урындыкка
Гармунчылар утырсын.
Бөгелә-сыгыла гармун уйный, –
Ул ничек онытылсын?

Кушымта:
Суда, суда,
Суда йөзәләсеңме?
Мин сине күрми түзәлмим,
Ә син түзәләсеңме?

МУЗЫКА

Руслан:Дәү әниләр, дәү этиләр,
Әбиләр һәм бабайлар!
Сез булганда тәрбияле
Булып үсәр балалар.

Раиль: Мәңге-мәңге шулай тәрәзләрдә
Балкып торса иде утыбыз.

Һәрчак безне каршы алса иде

Әти-әни, туган йортыбыз.

Бабай: Хөрмәт итеп килгән өчен,

Якыннарым олы рәхмәт.

Бөртекләп ашсын тормышка,

Сез теләгән һәрбер теләк.

**“БЕЗ-ТУКАЙ ОНЫКЛАРЫ”**

**(күңел ачу чарасы)**

***Гыйләҗиева Энҗе Рәшид кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*

*“Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы*

*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

*Кошлар сайрый, көй үзгәрә. Урманда Шүрәле, албастылар барлыкка килә. Бииләр. Биеп алгач, агач артларына качалар. Тыныч көй ишетелә, татар халык һәм рус халык киеменнән 2 кыз чыга.*

**1 Кыз**. Хәерле көн кунаклар. Сез әкиятләр яратасыз, беләм. Без сезгә бүген Габдулла Тукайның “Шүрәле”әкиятен сөйләрбез. Тыңлагыз.

**2 кыз.**

Бик матур бер айлы кичтәбуавылныңберҖегет

Киткәнурмангаутынга, ялгызыбератҗигеп.

Тиз барып җиткәнҖегет, эшкә тотынган баргач ук,

Кисәбашлаганутынныбалтаберләнтуктатук!

Җәйгетөнненңгадәтенчәтөнберазсалкыникән;

Барчакош-кортйоклаганбулганга, урмантыникән.

Шундый тын, яхшы һавадабезнеңутынчыисә

Алны-артны, уңны-сулныбелмичә, утынкисә.

Балтасы кулда, Җегетэштэнбераztуктаптора;
Тукта, чү! Ямьсезтавышлыэлләнәрсәкычкыра.

Сискәнеп, безнеңҖегеткатыпкалааягүрә,
Аңламастан, каршысындаәлләнинди«ят»күрә.

*Кыз чыгып китә. Атка атланып Былтыр керә. Агачлар аудара. Кинәт, каршысына Шүрәле килеп чыга.*

**Шүрәле.**

— Бер дә шикләнмә, Җегет, син; мин карак-угъры түгел,
Юл да кисмимен, шулай да мин бигүк тугъры түгел.
Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм;
Мин әле, күргәч сине, шатланганымнан үкерәм.
Тик кытыкларга яралгандыр минем бармакларым;
Булгалыйдыр көлдереп адәм үтергән чакларым.
Кил әле, син дә бераз бармакларыңны селкет, и
Яшь Җегет! Килче, икәү уйныйк бераз кети-кети.

**Былтыр.** Әй, Шүрәле, Шүрәле булмый. Эшем күп бит минем.

**Шүрәле:** Ничек инде алай?Шүрәле каршы килгәнне бер дә яратмыйый.

(*Ачуланып аяк тибеп куя* )

**Былтыр:** Ярар, яхшы, уйнармын. Тик шартымны кабул итмәссең дип уйлыйм.

**Шүрәле:**

— Нәрсә шартың, сөйлә, и бичара адәмчеккенәм?
Тик тизүк уйныйкчы, зинһар, нәрсә кушсаң да күнәм.

**Былтыр:** Менә монда бер бүрәнә ята, күрәсеңме?

**Шүрәле:** Күрәм, күрәм!

**Былтыр:**

Шул агачны арбага салыйк.
Бүрәнәнең бер очында бар ачылган ярыгы.
Шул җиреннән нык кына син тот.

*Шүрәле күнә. Былтыр чөйгә суга, чөй чыгып китә. Шүрәленең бармагы кысыла.*

**Шүрәле:** Ай-яй-ай-яй, кулларым.

— Син бераз кызган мине, коткарчы, и адәм генәм;
Мондин ары үзеңә, угълыңа, нәслеңгә тимәм.

Башкалардан да тидермәм, ул  минем дустым диеп,

Аңгар урманда йөрергә мин үзем куштым, диеп.

Бик авырта кулларым, дустым, җибәр, зинһар, җибәр; —

Шүрәлене рәнҗетүдән нәрсә бар сиңа, ни бар?

*(Шүрәле кычкыра, сыкрана, гафу үтенә).*

— И Җегет, һич юк икәндер мәрхәмәт хиссең синең;

Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез! Кем син? Исмең кем синең?

**Былтыр:** Әйтсәм, әйтим. Син белеп тор. Исемем минем - Былтыр. *(атка атланып чыгып китә)*

**Шүрәле:** *(Кычкыра)*

«Кысты, харап итте явыз Былтыр мине,

Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине?»

*Тавышка Албастылар керә.*

**1 нче албасты.** Ник кычкырасын? Кем кысты.

**Шүрәле:** Былтыр кысты.

**2 нче албасты.** *(аяк тибеп, ачуланып).* Кычкырма, Шурале, тукта.

**3 нче албасты.**

— Син җүләрсең, син котырган, син тилергәнсең.

«Кычкырма син, тиз яхшылык берлән тыел!

И җүләр! Кысканга былтыр, кычкыралармы быел!?»

*Албастылар чыгып китәләр. Артларыннан, кычкыра-кычкыра, агачны күтәреп Шүрәле дә кузгала.*

**1 нче кыз:** *(моңлы көй куела, кыз чыга)*

Борчылмагыз, дусларым.

Чынлыкта Шүрәлеләр юк алар,

Тик әкияттә генә яшиләр.

Куркыталар, кычкыралар.

Бер кайчан да Шүрәлеләр булмаган. Ә Былтыр ул халык герое: акыллы, зирәк, тапкыр.

*Милли көй яңгырый,зур китап күтәреп ике бала чыгалар.”Г.Тукайның “ Китап” шигырен сөйлиләр.*

Һич тә күңлем ачылмаслык эчем пошса,

Үз-үземне күрәлмичә, рухым төшсә,

Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны

Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә;

Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш,
Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,
Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса
Хәзер генә сыгълып-сыгълып елаган яшь, —

Шул вакытта мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам;
Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,
Шуннан гына дәртләремә дәрман табам; (Булат)

Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем
Була минем юл күрсәткүче йолдызым;
Сөйми  башлыйм бу дөньяның ваклыкларын,
Ачыладыр, нурланадыр күңлем, күзем;

Җиңелләнәм, мәгъсумләнәм мин шул чакта,
Рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка;
Ышанычым арта минем үз-үземә,
Өмид берлән карый башлыйм булачакка.
*Җыр: Г.Тукай “Туган тел”*

**“ДУСЛЫК ИЛЕ”**

***Тимергалиева Әдилә Зөфәр кызы***
*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*
*“Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

Салмак кына көй уйный. Залга милли орнаментлар белән бизәлгән зонткүтәреп, татар кызычыга (тәрбияче). Татар, рус, башкорт, мари, чуваш,керәшен милли киемнәре кигән балалар керәләр.

**Татар кызы (тәрбияче):**

Без – бер илнең балалары,

Барыбыз да дуслар без.

Татарлар, чуваш, марилар,

Башкорт, керәшен, руслар без.

**Алып баручы:** - Хәерле көн, хөрмәтле кунакларыбыз!

Биибез дә, җырлыйбыз да,

Милли киемнәр киеп.

Атадык без бу бәйрәмне

“Дуслык кичәсе” диеп.

Бүген бездә бәйрәм. Бакчабызга әбиләрне кунакка чакырдык. Әйдәгезәле, аларны каршы алыйк.

Музыка уйный, татар, рус, башкорт, мари, чуваш, керәшен милли киемнәре кигән әбиләр керә.

**Әбиләр:** - Исәнмесез, кунаклар! Исәнмесез, балалар!

**Балалар:** - Исәнмесез!

**Алып баручы:** Әйдәгез әле, бергәләп бәйрәм итик!

**Бергә:** - Әйдәгез!

**Татарлар (**малай,кыз**):**

Исәнмесез!

Без - татарлар! Шушы исем белән

Җирдә яшәү үзе зур бәхет,

Яшибез без туган җиребездә,

Бар халыклар белән берләшеп.

Татар әбиен биергә чакыралар, татарча бию.

**Урыслар(**малай,кыз**):**

Здравствуйте!

Родной язык мой – русский

Ему я буду предана всегда.

Горжусь я тем, что он Великий,

Его я не забуду никогда.

Урыс әбиен биергә чакыралар, урыс биюе.

**Урыс әби:**

**-** Спасибо, ребята, что пригласили на праздник. Я вам тоже подарок принесла.

Русские народные частушки:

Как надену я рубаху

И понёву синюю,

Вы такую бабушку

Не сыщете красивую.

Сарафанов нонь не носим

Нам от них убыточек,

Нужно восемь метров ситца

Три катушки ниточек.

**Башкортлар (**малай,кыз**):**

Һаумыһыгыз, дустар!

Һаумыһыгыз! Һаумы, һаумы!

Һаулашам – сәлам бирәм.

“Һаумы” дигән әйбәт сүзне

Бар дөньяга җибәрәм.

Башкорт әбиен биергә чакыралар,

башкорт биюе.

**Керәшеннәр(**малай,кыз**):**

Арумысез, карендәшләр!

Аралар ерак димәсен,

Килсен безгә якын дус.

Зәебезнең суы татлы,

Халкыбызның йөзе якты,

Йөзе якты, күңеле хуш.

Керәшен әбиен биергә чакыралар, керәшен биюе.

Әби керәшен халык җырын бүләк итә:

Эзәй буйларына без лә төшәрбез,

Колачларны җәеп йөзәрбез.

Кычкырыр ла күке, сайрар былбыллар,

Шул чагында ничек түзәрбез?

**Марилар(**малай,кыз**):**

-Сайл де!

Одна ты, родина, такая!

Прекрасней не сыскать тебя!

Люблю душой и воспеваю

Тебя, марийская земля!

Мари әбиен биергә чакыралар, мари биюе.

**Мари әби:** - Сай улыда! (Здравствуйте!)

**Марилар: -** Сайл де! (Здравствуйте!)

**Мари әби:** - Поро кече! Пашада кузе кая? (Добрый

день! Как дела?)

**Марилар: -** Сай! (Хорошо)

**Мари әби:** - Тау! (Спасибо)

**Чуашлар(**малай,кыз**):**

Салам!

Таван черижив, таван чержив,

Асран кайми юратна чержив.

Таван чержив, таван чержив

Мухтав сана чурална чержив.

Чуаш әбиен биергә чакыралар, чуваш биюе.

Әби чуаш телендә җырлый.

**Алып баручы:**

Бүген бездә аккалфаклылар кунакта. Әйдәгез, бәйрәмебезгә

калфаклы кызларыбызны да чакырыйк. Рәхим итегез, кызлар.

Музыка уйный, татар кызлары керә.

**Татар кызлары:** Исәнмесез, аккалфаклылар!

**Татар әбие:**

Үзебезнең татар кызлары да килгән икән. Бик матур киенгәнсез,

балалар. Без яшь чакта “Башмакчы” уенын бик яратып уйный идек.

Әйдәгез әле, сезнең белән дә уйнап алыйк.

**Балалар:** Әйдәгез!

**“Башмакчы” уены.**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Әби уенны алып баручы – “башмакчы” була.

Ул кулына бер башмак тотып, уртага баса. Җырлый:

**Әби**:

Төрле һөнәр беләбез,

Матур итеп тегәбез;

Асыл төсле җепләр белән

Башмак башын чигәбез.

Балалар аңа каршы,

түгәрәк буйлап йөреп,

җыр җырлыйлар:

Әй башмакчы, башмакчы,

Үзең оста такмакчы.

Син җырлама такмагың,

Бир кияргә башмагың.

Балалар җырлап бетергәч, әби башмакны ике бала арасына куя һәм аларныңиңнәренә кагыла. Ике бала ике якка түгәрәк буйлап йөгереп китәләр. Кем беренче килеп җитә, шул башмакны кия. Ул “башмакчы” була. Башмаксыз калган бала тизәйткеч әйтә:

Бака кебек бак та бак,

Бак та бак килә үрдәк.

Менә шулай була ул

Бакадан алсаң үрнәк.

Уен тагын бер кабатлана.

**Әби:** ... кызым калды. Нинди җәза бирәбез?

**Балалар:** Җырласын, җырласын.

Җыр: “Энҗе-мәрҗән калфагым”, җыр барышында татар кызлары бииләр.

**Алып баручы:**

Аклык-сафлык белән һәрчак

Дан тота ул һәр илдә.

Безнең татар кызларына

Тиңнәр юктыр бу җирдә.

Бүгенге кичәбез ахырына якынлашты. Әйдәгез, бергәләп, Зәй турында җыр җырлыйк.

Җыр: “Дуслык иле”:

Зәем – дуслык каласында

Кояш якты, җил җылы

Шуңа күрә, һич өзелми

Туганлык, дуслык юлы.

Кушымта:

Килсеннәр, әйдә килсеннәр,

Безнең барын белсеннәр,

Зәебезнең гүзәллеген

Барысы да күрсеннәр.

Якын итеп килә безгә

Кунак булып күп дуслар.

Татарларның түр башында

Чувашлар һәм урыслар.

Кушымта:

Килсеннәр, әйдә килсеннәр,

Безнең барын белсеннәр,

Зәебезнең гүзәллеген

Барысы да күрсеннәр.

Музыка астында, балалар, кулга-кул тотынышып, чыгып китәләр.

## Милли уеннар ярминкәсе

(Күңел ачу иртәсе)

**Васильева Лилия Тәбрис кызы**

*“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Рябинушка” Красносельский балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениясе”*

**Яшь төркеме:** зурлар

**Үткәрү формасы:** тематик, гомумиләштерүче.

**Максат**: мәктәпкәчә яшьтәге балаларны рус һәм татар халык мәдәнияте, аның гореф-гадәтләре белән таныштыру. Халык бәйрәме ярминкә турында тамаша формалаштыру.Гаилә белән мәктәпкәчә белем бирү учреждениясы арасында үзара аңлашучанлык,уртак кызыксынучанлык,эмоциональ үзара ярдәмләшү атмосферасы булдыру.

**Бурычлар**:

**Тәрбия бирүче**

- халык мәдәниятенә уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- балаларда бер-береңә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;

**Укыту:**

- ярминкә бәйрәме турында белем бирү;
- көнкүреш әйберләренең исемнәре белән таныштыру, сүзлекне баету;

**Үстерү:**

- сөйләмнең эстетик һәм эмоциональ ягын үстерү;
- музыка эшчәнлегенең төрле төрләрендә ритм хисен, үз хәрәкәтләрен сөйләм белән килештерә белүне дәвам итү;

- уеннар, хәрәкәтләр аша координацияне, реакция тизлеген үстерү;

- уенда иҗади күренешләр һәм яшьтәшләре белән аралашу белән кызыксынуны үстеру;

**Җиһазлар:** Б.М. Кустодиевның «Ярминкә» картиналарын күрсәтү ИКТ - презентация; «Рус халык музыка уен кораллары» ИКТ –музыкаль-дидактик уены; музыкаль үзәк, пианино, компьютер(ноутбук);

Музыкаль залны бизәү: өстәлләрдә («киштәләрдә») - самавыр,татар халык,рус халык ашлары , матрешкалар, музыкаль уенчыклар;

**Кулланыла торган технологияләр:**

-мәгълүмати-коммуникатив,

- иҗади сәләтләрне формалаштыру технологиясе,

-сәламәтлек саклау,

-эзләү-танып-белү,

- музыкаль йогынты технологиясе;

**Мәгариф өлкәләре (интеграция):** «Танып-белү үсеше», «Сөйләм үсеше», «Социаль – коммуникатив үсеш», «Социаль – шәхси усеш»;

**Методлар һәм алымнар:** уен күнегүләре, күрсәтмә, ишетү, кызыксындыру алымнары, контроль методы, үз-үзеңне тикшерү, сүзләр.

**Сүзлек эше:** сүзләрнең мәгънәсен аңлату-ярминкә, фольклор, киштәлек.

(Тәрбиячеләр һәм балалар рус ,татар киемнәрендә)

Татар киемнәрендәтәрбияче һәм балалар татар халык көенә бүлмәгә керәләр.

**Алып баручы:** Дус яшәргә кирәк җир йөзендә,

Дуслар кирәк һәрбер кешегә

Дуслык булса янәшәдә,

Дошманлык чыгар юкка.

**Балалар:**

1. Йөри безнең бакчага бик күп төрле, балалар.

   Төрле-төрле телләрдә, сөйләшә белә алар.

2. “Дустым” сүзен дурт телдә, өйрәндем мин үзем дә.

   Әйтә беләм икә телдә “исәнмесез” сүзен дә.

3. Төрлә костюмнар киеп, йөрибез җырлап, биеп.

   Атадык без бу бәйрәмне “дуслык бәйрәме”.

4. Без татарлар! Шушы исәм белән! Җирдә яшәү үзе зур бәхәт!

   Яшибез без бу җирдә, бер халыклар белән берләшеп!

**Алып баручы:**Кунакларсыз нинди бәйрәм булсын инде?(музыка).

Ә менә кунаклар үзләре дә!

*Җырлап залга тәрбияче , рус костюмынна балалар керәләр, музыка коралларынлда уйныйлар*

**ПЕСНЯ «ВЫХОД НА ЯРМАРКУ»**

**Алып баручы.** Безгә дуслар кунакка килгәннәр.Безнең бәйрәмгә рәхим итегез!

Бер беребезне сәләмлик!

*Балалар исәнләшәләр:*

**Дети  в татарских костюмах:**Исәнмесез!

**Дети в русских костюмах:** Здравствуйте!

*Под народную плясовую музыку в зал входит* **Потешница**

**Потешница**: Вот мы и пришли к вам на ярмарку

Себя показать, ваш товар посмотреть!

Я – потешница весёлая, ваша гостья развесёлая!

Народ собирается, наша ярмарка открывается!

**Дети:**

**1.** Нынче день такой чудесный, только петь да танцевать,

Всех друзей мы приглашаем чай попить, да поиграть!

**2.** Пусть играют нам гармошки и выходят плясуны,

Хорошеют наши лица, когда радуемся мы!

***Общий хоровод «Шире круг»***

**Алып баручы:** Бүләк итәбез чәк - чәк

Тормышыгыз булсын  мул һәрчак! (*бүләк итә)*

***А.Б.***Без үзебезнең яраткан илебездә һәм нурлы республикабызда бик дус яшибез.Барлык халыкларга бәхет һәм шатлык телибез.Безнең Татарстан үзенең шатлык – куанычлары, югары үрләре белән данлыклы!

Безгә Татарстанда яшәү ошый!

**УЕН «БЕЗ БИК ДУС БУЛЫЙК»**

**Потешница:** Эй, народ честной, здравствуйте, всех на праздник Ярмарку приглашаем. Веселья и хорошего настроения желаем!

*2 сатучы һәм1 сатып  алучы прилавка артына килеп баса (руслар)*

*(1.Платочки.2. Дудочки)*

**1 продавец:** Эй, на Ярмарку спеши, купи, что хочешь, для души!

**2 продавец:** Подходите, подходите. На товары поглядите!

У Коробейников в запасе есть и бусы, и венки, разноцветные платки!

**Девочка-покупатель:**Есть у вас платочки, яркие, как щёчки?

**1 продавец:** Есть такие, забирайте, да платить не забывайте.

**Мальчик-**покупатель: А я - Дудочку куплю, очень музыку люблю!

**ИГРА «ДУДОЧКА»** с платочками

*2 сатучы һәм алучы чыга(татар)*

**1 сатучы:**Килегез! Килегез! Нәрсәләр бар, күрегез!

**Алучы:** А откуда ваш товар?

**Вместе:** Из Татарстана!

**2 сатучы:** Өстәлдә безнең чәк-чәк,

Бавырсак һәм өчпочмак!

Алсуда һәм Әскәрдә бүләк

Җитәр бар илгә!

**1 сатучы:**Бүләкләрне алыгыз

Кунакларны сыйлагыз! *(балалар кулларына ясалма күстәнәчләрне(чәк-чәк,баурсак,бәлеш,өчпочмак,кыстыбый)алып басалар.*

**Җыр «БЕЗӘЗЕРЛИБЕЗ ТАБЫН…»**

1. Без әзерлибез табын,
Китереп бөтен ягын.
Уртага куйдык чәчәк,
Чәчәк янына чәкчәк.
Бавырсак һәм кыш теле
Ризыклар төрле,төрле
Сумса,бәлеш,өчпөчмак,
Гөбәдия һәм көймак.

2. Без әзерлибез табын,
Китереп бөтен ягын.
Уртага куйдык чәчәк,
Чәчәк янына чәкчәк.
Җитешегез, кунаклар!
Кыстатмагыз, кунаклар!
Өйгә кайтып китәргә
Ашыкмагыз,кунаклар.

*2 атучы һәм алучы рус киемнәреннән чыгалар.*

**1 Продавец:** Подходи, честной народ, мы стоим у ворот!

Становитесь в ряд, выбирайте всё подряд:

Дудки, хлопушки, бубны, погремушки!

**2 Продавец:** Пришли мы с ложками,свистульками, гармошками!

Подешёвке продаём! Почти задаром отдаём!

**Покупатель:**Обошел я много мест, не видал нигде оркестр.

Заиграйте-ка сейчас, чтоб пустились ноги в пляс!

**РУС УЕННАРЫ**

***Алып баручы*:** Безнең әле оркестр бар

Шундый шәп итеп уйный

Барлык килгән кунакларны

Шаккатырырга уйлый.

***ТАТАР ХАЛЫК КОРАЛЛАРЫ ОРКЕСТРЫ***

**Сатучы** , **алучы**–татар балалары

**Сатучы:**Ярминкәгә чакырабыз

Киемнәрне сатабыз

Килегез,килегез

Алыгыз,алыгыз.

**Алучы:**Киемнәрне алырбыз,

Куңел ачыйк барыбыз.

Уеннар уйнамыйча

Куңелле булмас безгә.

Уен уйныйк бергәләп

Басыйк кумәк түгәрәк.

**Алып баручы:**Әйдәгез балалар”Түбәтәй” уенын уйнап алабыз.

***«ТҮБӘТӘЙ” УЕНЫ***

***Түбәтәеңне кигәнсең***

***Бик ераклардан килгәнсен***

***Төскә матурлыгың белән***

***Шаккатырыйм дигәнсең***

***Туп туп түбәтәй***

***Түбәтәең уккалы***

***Чиккән матур түбәтәең***

***Менә кемдә тукталды.***

**Потешница:**Солнышко, солнышко, ярче нам свети!

Будут на лужочке цветики расти.

Солнышко, солнышко, ярче нам свети!

Будут здесь, на ярмарке слаще калачи.

Солнышко, солнышко, выгляни в окошечко,

**Все дети:** Солнышко, солнышко, выгляни в окошечко!

**ИГРА «СОЛНЫШКО-ВЁДРЫШКО»**

**А.Б.**Уеннар бит,балалар, витамин кебекалар.

Куңелләрнеүстерә, йөрәкләргә көчбирә!Уйныйбызмы?

**Все дети:** Уйныйбыз! Уйныйбыз!

**УЕН «ПАРЫҢНЫ ТАП»**

**Потешница:** Как солнце щедрое в небесной сини

Из века в век не устаёт сиять,

Так согреваешь нас и ты, Россия!

Для ста народов ты – родная мать!

В соседних памятных селеньях

Татарин, русский и чуваш

Зовут друг друга с уваженьем

Иптэш, товарищ, ил, юлдаш:

Единый смысл трех разных слов

Понятен испокон веков.

**А.Б.:** Без берилнеңбалалары, барыбыз да дуслар без.

Татарлар, чуваш, марилар, башкортһәм руслар без!

**ТАТАР БИЮЕ**

**Ребёнок :**У разных народов есть прелесть традиций,

Одежда своя и родной свой язык…

Ну, как мне татарской землей не гордиться?

И тем, к чему с детства душою привык!

**Жыр“ ТУГАН ТЕЛ”**

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!

Дөньядабелдемсинтуган тел аркылы.

Иңәлекбу тел беләнәнкәмбишектәкөйләгән,

Аннарытөннәр буе әбкәмхикәятсөйләгән.

И туган тел! Һәрвакыттаярдәмеңбеләнсинең,

Кечкенәдәнаңлашылганшатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдәбулганиңәлеккыйлган догам:

Ярлыкагыл, дип, үземһәмәткәм-әнкәмне, ходам!

**Ребёнок:** Под теплым солнцем вырастая, мы дружно, весело живем!

Россия, милая, родная, цвети и крепни с каждым днем!

**Бергәҗырлыйлар**

Ярминкәгәбардык без

Күпнәрсәләралдык без,

Җырладык та, биедектә,

Күңелебезнеачтык без.

**Алыпбаручы:**

Бәйрәмиттек, эх, дусларым,

Бүгенбарыбызбергә,

Килдегездәкарадыгыз,

Рәхмәтләряусынсезгә.

## Кичке аш вакыты күренеше

**Фәйзетдинова Ләйлә Хәлим кызы**

*"Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең гомуми үсеш бирүче төрдәге 5 номерлы Саба "Бәләкәч" балалар бакчасы мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе"*

*Карт әби тәсбих тартып утыра.*

**Кайнана:** Кызым, ашны булдырып куйсак була инде.

**Килен:** Яхшы, әнкәй. Хәзер булдырам. *(чыгып китә)*

*Кайнана өстәл янында икмәк кисә.*

**Карт әби:** Кызым, берүк икмәкнең валчыкларын чәчә күрмә. Икмәк –тормыш нигезе. Икмәкнең валчыгы да изге һәм кадерле.

**Кайнана:** Бик дөрес әйтәсен әнкәй. Икмәкне кадерләп, саклап тоту – ул барыбызның да изге бурычы.

*Балалар керә.*

**1 Бала:** Дәү әни, дәү эни! Без бик ачыктык.

**2 Бала:** Ашыйсыбыз килә.

**Килен:** Әтиләрегез кайтмады бит әле. Бар, Байбулат, капка төбенә чыгып, карап кер әле. Кайтмыйлар микән?

**1 Бала:** Хәзер. *(чыгып китә)*

*Карт әби оныгын чакыра.*

**Карт әби:** Беләсеңме, балам, татар халкында, элек-электән килгән гадәт бар – гаиләдә барысы да җыелып бетмичә, өстәл янына утырмыйлар. Бу олыларга карата хөрмәт күрсәтү, ризыкны олылау булып санала.

*Бала тыңлап тора.*

*Ат тавышы ишетелә. Керәләр. Малай алдан йөгереп керә.*

**1 Бала:** Кайттылар!

**2 Бала:** Урааа! Ашыйбыз!

**Дәү әти:** Хәерле кичләр!

**Әти:** Әйбәт кенә тордыгызмы?

**Килен:** Аллага шөкер, улым. Барысы да яхшы. Әйдәгез кулларыгызны юыгыз да, табын алдына рәхим итегез.

*Карт әбине оныклары өстәл янына алып килеп утырталар.*

**Карт әби:** Әйдәгез, балалар, ашар алдыннан дога кылып куйик.

*Дога кылалар.*

**Кайнана:** Ашларыбыз тәмле булсын!

**Барысы бергә:** Рәхмәт!

*Ашап утыралар.*

*1 Бала аягын селкеп утыра башлый.*

**Дәү әти:** Улым, ашаганда аяк селкеп утырмыйлар, ашыңны шайтаннар ашый дип әйтәләр.

**2 Бала:** Шайтан чакырып утырма әле, энем.

*Ашап бетерәләр.*

**Әти:** Әйдә әле, әби, бер дога укып алыйк.

*Дога укыйлар.*

*Өстәл җыештыру мизгеле.*

# Минем нәсел-минем шәҗәрәм

**Шайхуллина Айгөл Илфат кызы**

*"Татарстан Республикасы Саба районы*
*ш.т. Байлар Сабасы 1 нче номерлы*
*"Шатлык" балалар бакчасы"*
*Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль*
*бюджет учреждениясе*

**Айгөл (сәхнә арты):**Хәерле көн сезгә якын дуслар.
Хәерле көн телим халкыма.
Чын күңелдән әйткән җылы сүздән
Барыр юллар ныграк яктыра.

*Әби белән бабай сөйләшә-сөйләшә чыгалар.Әби самавырын күтәргән, бабай аның артыннан чыга май кабартмалары тотып.*

**Әби:**Әйдә эле, картым, бер утырып әндри чәен әчик әле. Хәзер оныкның да кайтыр вакыты җитте.
**Бабай:**Оныкны көтмибезме соң?
**Әби:**Юк, әйдә икебез бергә иркенләп, яшь вакытларыбызны искә төшереп май кабартмалары белән тәмләп чәй эчик әле.
*Шул вакыт оных кайтып керә (**Айгөл**)*
**Айгөл:**Нихәл, әби! Нихәл, бабай! (кочаклашалар).
**Әби:** Иии балакаем, исән-имин кайттыңмы?
**Айгөл:**Әйе.Әби-бабай, безгә бит әле көллияттән бер эш бирделәр- үземнең ерак бабамнарны белеп килергә диеп әйттеләр. Нишләп сез миңа бер дә ерак бабамнар турында сөйләмисез?
*Әби белән бабай бер-берсенә карашалар да:*
**Әби:** Әәәәй, кызым, без аны атлаган адымыбыз саен сөйләп барабыз. Син генә тыңламыйсың.
**Айгөл:** Ничек инде тыңламыйм?! Мин сезнең һәрбер әйткән сүзегезне тыңлыйм.
**Әби:** Юк шууул.
*Сандыктан әби-бабайлардан калган истәлекләрне күрсәтә-күрсәтә барлыйлар.*
***Әби:***Менә синең бик ерак әбиең, кызым, данлыклы ипи пешерүче булган.Аның ипиләрен төрле якларда .........ипие тәмле диеп мактап ашый торган булганнар.
**Айгөл:** Әби, мин бит ипи турында шигырь беләм. Сөйлим әле үзегезгә.
*Әби пешергән икмәкнең,*
*Тәме һаман телемдә.*
*Тынын өреп пешергәнме,*
*Әллә ул һәр телемгә?*
*Яңа пешкән икмәк тотып,*
*Урамга чыга идек.*
*Күзләре кызыкканнарга,*
*Без бүлеп бирә идек.*

*Икмәгемнең үсләренә*
*Шикәр комы сибелгән.*
*Тәмле итеп шул икмәкне*
*Әнкәй мичтә пешергән.*

**Әби:** Кызым, икмәк бит инде ул тракторчы җирне яхшы сукалаганга, яхшы эшкәрткәнгә чыга. Синең ерак бабаң тракторчы булган.

*Җыр һәм күренеш "Колхоз кырлары буйлап"*

Җырлар җырлап, җиң сызганып
Эшләп йөри кырчылар.
Җыр белән хезмәтне бәйләп
Шат яши колхозчылар.

Эх, Саба уллары,
Матур су агулары.
Узебез чәчкән кырлар буйлап
Күңелле барулары.

**Әби:**Ә менә монысы инде .... әбиеңнең истәлекләре. Ул яхшы сыерсавучы булган. Элек хәзерге шикелле аппаратлар белән савылмаган сыерлар, ә кул белән дә 25шәрсыер савылган. Хәзерге хезмәт белән элеккеге хезмәтне чагыштырып булмый. Менә аның алган, ирешкән уңышлары. (сандыктан алып күрсәтә).

*Бию һәм җыр "Ай Җәмилә"*
**Айгөл:**Рәхмәт сиңа әби, рәхмәт сиңа бабай. Безнең нәселебездә данлыклы ипи пешерүчеләр, тракторчылар, сыер савучылар барлыгын белмәдем дә бит мин.
**Әби:** Әле бит, балам, ...бабаң да сугыштан катнашып Җиңү белән кайтты. Менә аның орден-медальләре, военный билеты.
*Айгөл алга алып барып күрсәтә аларны.*
Бабаемның тырыш куллары һич
Ару-талу белми эшләде.
Эш сөючән бабам гомер буе
Үз хезмәте белән яшәде.

Илләребез тыныч булсын, һәрвакыт нәселләребезне барлап торыйк. Туганнарның бергә җыелуы ул элек-электән калебеңне чистарта диеп әйтәләр. Бергә булыйк, бердәм яшик.
Хәзер үзем әни булсам да мин
Хыялымда кайтам кабаттан
Әби-бабай белән үткән еллар
Хәтеремдә бик еш яңартам.

**Җыр "Җиде ятлар туган түгел"**(барысы бергә 1 куплет)
Беребез дә мәңге түгел,
Бу дөньяда кунак кына.
Туган-туган булып кала,
Җан тартмаса да кан тарта

Җиде ятлар туган түгел
Үз туганыңның кадерен бел.
Үлгәненең каберен бел,
Исәненең кадерен бел.

# ШӨГЫЛЬЛӘР,
# МАСТЕР –
# КЛАССЛАР



# БЕЗ – ЯШЬ ЖУРНАЛИСТЛАР!

(мәктәпкә әзерлек төркемендә туган телдә сөйләм үстерү өлкәсендә
белем бирү эшчәнлегенең конспект эшкәртмәсе)

***Шәвәлиева Гөлнара Мөбәрәкҗан кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*

*«Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге*

*6 нчы номерлы «Сандугач» балалар бакчасы»*

*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

| | |
|---|---|
| Яшь үзенчәлекләре: | Мәктәпкә әзерлек төркеме |
| Тема: | «Без – яшь журналистлар» |
| Эшчәнлек төре: | Оештырылган белем бирү эшчәнлеге |
| Эшчәнлеккә кертелгән белем бирү өлкәләре: | Танып-белү, әйләнә-тирә белән танышу, туган телдә сөйләм телен үстерү, нәфис-нәфәсәти үсеш |
| Максат: | балаларның уку елында алган белемнәрен гомумиләштерү һәм системалаштыру. |
| Бурычлар: | - Туган телдә аралашуга кызыксыну, туган якка, үз милләтенә хөрмәт, дуслык хисләре тәрбияләү;<br>- Балаларның туган телдә сөйләм телен һәм сүз байлыгын үстерү;<br>- Бирелгән мәсьәләне аңлый һәм аны мөстәкыйль рәвештә башкара белү, акыл, логик фикерләү тизлеген, танып-белү активлыгын, игътибарлылыкларын, хезмәттәшлек, түземлелек. үз-үзеңә бәя бирү, максатка ирешүчәнлек сыйфатларны формалаштыру.<br>- Туган тел, туган як, аның табигате, ел фасыллары, милли уеннар темаларын системалаштыру. |
| Методик алымнар: | Әңгәмә<br>Уен (сюрприз чаралар куллану)<br>Күрсәтмәлелек (иллюстрацияләр куллану).<br>Сүзлек (сораулар, балаларның шәхси җаваплары, искәрмәләр).<br>Кызыксындыру, нәтиҗә. |
| Җиһазлау: | Ноутбук һәм проектор, презентация, редакция бүлекләре өчен өстәлләр, уеннар өчен атрибутлар |
| Алдан үткәрелгән эш: | Матур әдәбият уку, иллюстрацияләр карау, ел фасыллары турындагы мәкальләр белән танышу, Туган тел, туган җир турында әңгәмәләр үткәрү, милли уеннар өйрәнү. |

| | |
|---|---|
| Эшчәнлекнең структурасы: | I.Кереш өлеш (дәвамы 3 мин.)<br>Максат: балаларның игътибарын җәлеп итү, эшчәнлеккә кызыксыну уяту.<br>II.Төп өлеш ( дәвамы 25 мин.)<br>1. Шигырь уку. Резеда Вәлиева "Туган җир"<br>2. Дидактик уен "Арчаның истәлекле урыннарын сайлап ал һәм әйт!"<br>3. «Көлдереш» сүзле уены<br>4. Яз турында мәкальләр әйтү<br>5. Сүзле уен "Яз турында әдәби китап"<br>6. Дидактик уен" Язга кагылышлы пиктограммаларны сайлап алып журнал битенә урнаштыр!"<br>8. Җыр«Кояшлы ил»<br>9. Уен «Тылсымлы гармун»<br>III.Йомгаклау өлеше ( дәвамы 2мин. )<br>Максат: Эшчәнлекне йомгаклау. Нәтиҗә ясау. |

**Эшчәнлек барышы :**

Тәрбияче: Хәерле көн, балалар? Барыгызга да яхшы кәефләр телим! Балалар, хәтерләсәгез, уку елы ахырында бер кызыклы җиргә баруны мин сезгә вәгъдә иткән идем. Менә ул көн килеп тә җитте. Балалар өчен бастырыла торган "Сәйлән" журналы редакциясенә ярдәм кирәк икән. Май аенда бастырылырга тиешле, журналның эше тукталып калган. Чөнки бөтен журналистларны конференцияга җыйганнар. Балалар, алар бездән тиз арада, бу журналның эшләнә башлаган санын ахыргача эшләп чыгуны үтенәләр. Ярдәм итәбезме? Балалар, әйдәгез булышыйк!

-Балалар, беләсезме бу редакциядә берничә бүлек, алар төрле темаларны яктырталар. Әйдәгез якынрак танышыйк! Бу "Сәйлән" журналының редакциясе. Балалар, сәйлән нәрсә дигәнне аңлата?

Балалар: Сәйлән- мәрҗән, бисер дигәнне аңлата. Аны җыеп муенса, беләзек ясыйлар.

Тәрбияче: Әйе бик дөрес? Балалар, әйтегез әле нәрсә ул редакция?

Балалар: Редакция – китап- журналлар чыгара торган җир.

Тәрбияче: Анда кемнәр эшли?

Балалар: Редактор- ул журналның бөтен өлеше өчен җаваплы. Һәрбер бүлекне, эшне контрольдә тота.

Дизайнер- журналның макетын төзүче. Журналны кызыклы итү һәм техник бизәлеш өчен җавап бирә. Төрле идеялар, төрле формалар һәи ысуллар уйлап таба.

Корреспондент –төрле кызыклы материаллар, мәгълүматлар җыя, өйрәнә һәм шул вакыйганы мәкалә итеп яза. Шулай ук видеокорреспондетлар да була, алар видеога төшереп йөриләр.

Корректор- текстны тикшерә. Һәрвакыт орфографик сүзлекләр һәм энцеклапедияләр куллана.

Тәрбияче: Балалар,  корректорлар үз урыннарында. Алар журналның чыгышын күзәтәләр һәм тикшерәчәк. Балалар, әйдәгез эшкә керешик. Алдыбызда беренче бүлек. Бу бүлек нинди теманы ятыртуы хакында белү өчен шигырь тыңларга тәкъдим итәм.

Резеда Вәлиева “Туган җир” шигырен укыйм

Күрче, дөнья  нинди матур,

Тирә-ягың гөл генә.

Гөлбакчадай ямьле була

Бары туган җир генә.

Тәрбияче: Шигырь нәрсә турында?

Балалар: Бу шигырдә туган туган җир турында.

Тәрбияче: Әйе бик дөрес. Ничек уйлыйсыз, димәк журналның әлеге бүлегендә нәрсә турында яза башлаганнар? Р..., син ничек уйлыйсың?

Балалар: Мин, әлеге бүлектә туган як, туган җир турында яза башлаганнар дип уйлыйм.

Тәрбияче: Ә нәрсә соң ул туган як? Сезнең туган ягыгыз ничек атала? Туган шәһәрегез?

Балалар: туган як, туган җир кешенең туган үскән ягы,

1 нче бүлек- “Туган җирем”   Журналда текст:   Туган ягым –Арча Минем туган ягым – Арча шәһәре. Риваять буенча Арчага 13 гасырда Батый Хан нигез салган. 20 нче гасыр дәвамында  Арча шәһәр тибындагы посёлок булып йөргән. 2008 нче елдан ул шәһәр статусына ия. Хәзерге вакытта Арчада 52 меңнән артык кеше яши.

- Балалар шушы текстны тулыландыру өчен сезгә уен тәкъдим иткәннәр. Дидактик уен “Арчаның истәлекле урыннарын сайлап ал һәм әйт!” (Слайд) Рәсемнәр: Дан һәйкәле, һәйкәлләр аллеясы, “Тукай музей комплексы”, “Казан арты” музее, Казансу паркы, Җиңү паркы, Тукай паркы, тимер юл вокзалы)

- Ә хәзер үзегез теләгән истәлекле урыннар , биналарның рәсемнәрен беренче бүлеккә урнаштырыгыз. (балалар урнаштыралар)
- Балалар,ни өчен бер рәсем калды? кайсы шәһәрдәге истәлеклеурыннар дип уйлыйсыз?

Балалар: Казан шәһәрендәге Кремль.

- Әйдәгез бер уен уйнап алабыз. «Көлдереш» уены. Мин көлдерүче.

«Көлдереш» уены уйнала (Балалар түгәрәкләнеп утыралар һәм бер көлдерүче сайлыйлар, сорауларны ул бирә)

Указым, указым

Казаннан килгән, приказым:

Алга-артка карамаска,

Елмаймаска, көлмәскә,

Елга, күлгә тимәскә,

Әйе һәм юк димәскә.

1 бала- көлдерүче:  сораулар бирә (Әйе , юк, елга, күл дияргә ярамый)

-Балалар, безнең әлеге тема төгәлләнде. Әйдәгез йомгак ясыйк: туган җиребез Арча турында мәкалә тулы булды микән?Икенче бүлеккә- 2 нче  темага күчәбезме?

2 нче бүлек-  “Әйләнә -тирә табигать”

Тәрбияче: Балалар, экранга игтибар итегез әле. Нәрсәләр күрәсез?

Әлеге бүлектә нинди темалар яктыртыла дип уйлыйсыз? Безгә ярдәмгә экранда пиктограммалар килә. Нәрсәләр күрәсез? (явым-төшем, һава торышы, табигать үзгәрешләре)

- Болар барысы да  безне чолгап алаган тирә -юнь, табигать күренешләре, шулай бит. Димәк әлеге бүлектә нинди темага багышланган мәкалә урнаштырылыачак? (Әйләнә-тирә табигать)

Балалар, табигатьтә ничә ел фасылы бар? (4 ел фасылы бар)

Нindиләр (җәй, көз, кыш, яз)

-Хәзерге вакытта кайсы ел фасылы? (яз)

Мәкальләр:

а) Яз яме чәчкә белән, көз яме көлтә белән.

б) Язның байлыгы – кояш, көзнең байлыгы – уңыш.

в) Язгы көн ел туйдыра.

Балалар, искә төшерегез әле яз айлары ничек атала (март, апрель, май)

-Һәр айның үз үзенчәлеге бар, шулаймы? Март нинди?

Март – тамчыбай, гөрләвеккә бай.

- Нәрсә ул гөрләвек ? (язгы  кар суының агуы)

- Җыелып торган кар сулары ничек дип атала? (Күлләвек)

Апрель нинди?

Апрель – хуҗа, ул канатлы дусларыбызны  каршылый; сулы, ташулы, хезмәт батыры,  матур ай.

Май нинди?

Май – ямьле, матур, чәчәкле ай.

Сүзле уен “Яз турында әдәби китап”

(балалар рәсемнәр буенча язгы табигаь үзгәрешләре, кешеләр хезмәте, хайваннар һәм кошлар тормышы турында җөмләләр төзиләр )

Дидактик уен ”Язга кагылышлы пиктограммаларны сайлап ал” (балалар язга туры килгән пиктограммалаларны табып журналга ябыштыралар)

Балалар, бу бүлектәге мәкаләне тулыландыра алдыкмы икән?Афәрин балалар!

3 нче бүлек-  “Уйныйк әле!”

- Балалар, бу бүлектә нинди теманы яктырткан мәкаләләр яза башлаганнарын тизрәк беләсегез киләме? Сез балалар бакчасынданиләр белән шөгыльләнергә яратасыз?(балалар җавабы: Мин җырларга яратам. Мин биергә яратам. Миңа рәсем ясау ошый, мин уеннар уйнарга яратам.)
- Журналистлар балалар өчен бер уен тәкъдим итәләр. "Тылсымлы гармун" дип атала әлеге уен. Гармун телләренә язылган саннар буенча без белгән татар халык уеннарына тукталырбыз.Үзегезгә ошаган санны әйтү өчен санамыш санап 1 баланы чыгарырга кирәк.(үзләре теләгән санны әйтеп, шул сан астындагы савытны ачып аннан бер вак рәсем алалар, андагы предметның нинди татар халык уенын хәтерләтүен әйтәләр, шул уен барышын сөйлиләр, соңыннан балалар теләге белән бер уенны бергәләп уйныйбыз.)
- Балалар, хәзер үзегез яратып уйнаган уеннарны хәтерләтүче рәсемнәрне журнал битенә урнаштырыйк (балалар өченче биткә ябыштырып куялар)
-Балалар, без бүген сезнең белән бик зур эш башкардык. Нәрсә белән шөгыйлләндек? Без журналның барлык бүлекләрен дә эшләп бетерә алдыкмы? Журнал әзер дип уйлыйсызмы? Сез үзегездән канәгатме?Редакция эше белән танышу да, башкаларга ярдәм итү дә файдалы һәм кызыклы булды! Редакция хезмәткәрләре безгә зур рәхмәт йөзеннән бүләк калдырганнар. Сез бүген чын журналистлар булдыгыз. Афәрин балалар! Булдырдыгыз, рәхмәт!

## "ТАТАРСТАНДА ЯШӘҮЧЕ МИЛЛӘТЛӘР"

(сөйләм теле үстерүдәнзурлар төркеме өчен шөгыль эшкәртмәсе)

***Шәрипова Энҗе Госман кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының*
*"Дөбъяз "Гөлчәчәк" балалар бакчасы,*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:**

Балаларның халык, милләт турында белемнәрен системалаштыру;

Татарстан Республикасының күпмилләтле булуы турындагы белемнәрен киңәйтү;

Балаларда башка милләт вәкилләренә карата хөрмәт, дуслык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:**Татарстан Республикасы картасы, рус, татар, башкорт, урдмурт, мари, чуваш киемендәге курчаклар, белем сандыгы, житоннар, смайликлар, "Идел буе халыкларының милли костюмнары" дидактик уен.

**Шөгыль барышы.**

1. **Оештыру өлеше.**

**Исәнләшү.**

Тәрбияче балалар белән "Әссәләмәгаләйкем" җырының көенә керә һәм җырның 1 куплетын һәм 1 кушымтасын башкара.

Таң ата да кояш чыга

Кояшны сәләмли көн.

Саумы, кояш, сүнмәс учак

Әссәләмәгаләйкем (5 тапкыр).

**Уңай эмоциональ халәт булдыру.**

**Тәрбияче**:-Исәнмесез. Хәерле көн! (Бергә!)

Һәр яңа көнне яхшы кәеф белән башларга кирәк. Кәефебез күңелле һәм яхшы булсын өчен, куллар тотышыйк (түгәрәк ясамыйча, баскан килеш кенә), бер-беребезгә карап елмайыйк, йөрәгебездә булган җылылык һәм мәхәббәт чаткыларын бер-беребезгә бирик. Кулларыгыздагы җылыны тойдыгызма балалар.

2. **Төп өлеш.**

**Тәрбияче:** - Балалар, бүген без үзебез яшәгән туган җиребез һәм анда яшәүче милләт кешеләре турында сөйләшүебезне дәвам итәрбез. Без нинди республикада яшибез?

**Балалар:**-Татарстан Республикасында.

**Тәрбияче:**- Әйе, бик дөрес. Без Татарстан Республикасында яшибез. Нинди телдә сөйләшәбез?

**Балалар:**- Татар телендә.

**Тәрбияче** - Безнең милләтебез – татар. Шуңа күрә без татар телендә сөйләшәбез. Безнең Татарстан Республикасында татарлар гына яшәми, төрле милләт вәкилләре дә яши. Милләт вәкилләре ул – төрле телдә сөйләшүче кешеләр.

Безнең төркемебездә дә төрле милләт балалары бар. Мәсәлән, Саша, Ника, Нозанин.

**Тәрбияче: -** Саша һәм Ника нинди телдә сөйләшәләр сезнең белән?

**Балалар: -**Рус телендә.

**Тәрбияче:**-Димәк аларның милләте – рус. Ләкин алар безнең белән аралашып татар телендә дә сөйләшергә өйрәнәләр.

**Тәрбияче:** -Безнең Республикабызда төрле милләт халыклары яши: татарлар, руслар, удмуртлар, чувашлар, марилар,башкортлар һ.б. Барлык милләт кешеләре дә үзара дус яшиләр, бер-берләренә кунакка йөриләр, бергәләп куңел ачалар, бәйрәм итәләр.

**Тәрбияче:**-Безнең төркемдә генә дә өч төрле милләт кешеләре бар. Ә безнең Татарстан Республикабыз бик зур бит.

**Тәрбияче:-**Әйдәгез, Республикабызның картасын карап үтик. Бу картада тамгалар белән бик күп шәһәрләр, авыллар күрсәтелгән. Менә монда Республикабызның башкаласы. Нинди шәһәр?

**Балалар:** -Казан.

**Тәрбияче:-**Ә менә монда безнең районыбыз. Без нинди районда яшибез?

**Балалар:** -Биектау районында.

**Тәрбияче:** -Нинди авылда яшисез?

**Балалар:** -Дөбъяз авылында.

**Тәрбияче:** -Балалар, ә хәзер сезне, төрле милләт киемнәре кигән курчаклар янына чакырам. Рәхим итегез. Алар төрле милләттән. Бу безгә бик таныш киемнән киенгән курчаклар. Нинди милләттән икән алар?

**Балалар:** - Татар милләтеннән.

**Тәрбияче:** -Татар кызының киеме турында безгә кем сөйләп китәр икән.

**Бала:** -Татаркызының өстендә бала итәкле күлмәк, яшел төсле, озын күлмәк. Күлмәк өстеннән чигүле алъяпкыч кигән, башында чигүле яулык бәйләгән.

**Тәрбияче:** - Рәхмәт. Татар малаеның киеме турында безгә Сөмбел сөйләп китсен әле.

**Сөмбел:** -Татар малаеның өстендә озын җиңле ак күлмәк, күлмәк өстеннән чигүле камзул, билендә билбау, киң балаклы кара чалбар кигән, башында түбәтәй, аягында –күн итек.

**Тәрбияче:** -Бик дөрес, рәхмәт Сөмбел.Ә бу курчаклар нинди милләттән? **Балалар:** -Рус милләтеннән.

**Тәрбияче:** -Әйдәгез аларның киемнәре турында да әйтеп үтик. Рус кызы турында кайсыгыз сөйләп китәр икән.

**Бала:** -Рус кызының өстендә озын җиңле ак күлмәк, күлмәк өстеннән кызыл сарафан кигән. Башында какошник. Рус кызларының яраткан баш киемнәре булып какошник саналган.

**Тәрбияче:** -Бик яхшы. Рус малае турында кайсыгызга сүз бирик.

**Бала:** -Рус малаеның өстендә озын җиңле ак күлмәк, күлмәкнең җиңе һәм итәге чигүле. Билендә кызыл билбау, киң кара чалбар кигән, аягында – күн итек. Башларына картуз кигәннәр.

**Тәрбияче:** Әйе, бик дөрес. Рәхмәт. Ә бу курчаклар – башкорт милләтеннән. Киемнәренә карагыз, киемнәре безнең татар киемнәренә охшаганмы?

**Балалар**: - Юк, ошамаган.

**Тәрбияче: -** Әйдәгез бу милләт курчаклары турында да сөйләп китик.

**Бала**: -Башкорт кызының өстендә киң итәкле кызыл төсле озын күлмәк. Күлмәк өстеннән төрле укалар белән бизәлгән камзул кигән. Күкрәгендә тәңкәләр белән чигелгән күкрәкчә.

Башларында да тәңкәләр тезеп бизәлгән баш кияме. Аякларына башмак яки туфли киеп йөргәннәр.

**Бала**: -Башкорт малае озын җиңле кызыл күлмәк, күлмәк өстеннән чигүле камзул яки кафтан, киң кара чалбар кигән. Башларында Малахай баш кияме, аякларында күн итекләр булган.

**Тәрбияче:** Рәхмәт бик зур. Балалар арыганыгыз күренеп тора, әйдәгез ял итеп алабыз.

**Физминутка. Башкортларның җырлы-биюле уенын уйнап алырбыз.**

Без шат күңелле балалар,

Түгәрәккә җыелдык.

Биеп, уйнап, җырларга

Болыннарга йөгердек. (көйгә башкорт халкының бию хәрәкәтләрен күрсәтеп бию).

**Тәрбияче: -**Бик матур уйнадыгыз, рәхмәт балалар. Курчаклар белән танышуны дәвам итик. Бу милләтләр белән үзем таныштырып китәм.

Бу курчаклар – удмурт милләтеннән. Әйдәгез аларның киемнәренә дә игътибар итик. Удмуртмилли киемнәре гади түгел. Хатын-кызлар озын җиңле, ачык изүле күлмәк, аның өстеннән тәңкәле, укалы күкрәкчә, күкрәксез алъяпкыч, аларга өстәмә кыска җиңле камзул кигәннәр. Башларына косынка бәйләгәннәр, аларны тәңкәләр, укалар белән бизәгәннәр.

Ирләрнең күлмәк бизәкләре хатын-кызларныкыннан аерылмаган. Күлмәк якалары бизәкләр белән чигелгән, билләрендә пута бәйләгәннәр. Киң балаклы чалбар кигәннәр. Башларында эшләпә булган, аякларына чабата, я башмаклар кигәннәр.

(Шул вакыт ишек шакыйлар).

**Тәрбияче:-** Балалар, безгә кемдер килде. Әйе, рәхим итегез. (Урдмурт милли кияме кигән кунак керә. Ул үзе белән таныштырып китә. Балаларга үз милләте турында һәм уен коралы белән таныштыра). Кунак чыгып китә.

**Тәрбияче:** - Балалар, безнең кунагыбыз нинди милләттән булды?

**Балалар:-** Удмурт милләтеннән.

**Тәрбияче:** Бу курчаклар – чуваш милләтеннән. Киемнәренә игътибар итик.

Табигать күренешләрен кием орнаментларында һәм бизәкләрендә кулланганнар. Хатын-кыз костюмы бик катлаулы, ул туника формасындагы ак тукыма күлмәк кигән.

Ир-ат киемнәре бизәкләрнең байлыгы һәм орнаментларның төрлелеге белән аерылып торган. Ир - атлар туника формасындагы ак тукыма күлмәк, билбау белән билләрен бәйләгәнәр.

**Тәрбияче:** Бу курчаклар – мари милләтеннән. Мари кызы озын җиңле ак күлмәк, күлмәк өстеннән үзләренең орнаментлары белән бизәлгән алъяпкыч япканнар. Башларына тәңкәләр белән чигелгән баш кияме, аякларына туфлилар кигәннәр. Мари малае да озын җиңле ак

күлмәк кигән. Күлмәкнең итәге үзләренең орнаментлары белән бизәлгән. Билләрендә билбау бәйләнгән. Киң чалбар һәм аякларында күн итек. Башларында ялкас дигән баш киеме.

**Тәрбияче:** Балалар, без аларның сөйләм телләрен аңламасак та, без үзара тату, дус булып яшибез һәм яшәрбез дә. Сез зур үсеп, мәктәпкә киткәч, күп милләтләр турында тагы да күбрәк белерсез.

3. **Йомгаклау.**

Балалар, мин сезгә "Идел буе халыкларының милли костюмнары" уенын уйнап алырга тәгъдим итәм. (Балалар түгәрәк ясап басалар.) Сез Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларны картада дөрес итеп урнаштырырга тиешсез. Әфәрин булдырдыгыз. Мин сезнең бүген тырышлыгыгыз белән бик канәгать.

**Саубуллашу.**

**Тәрбияче:** -Балалар, мин сезгә бүген белем сандыгы алып килдем. Без белем сандыгына ниләр салып куярбыз икән? Әйдәгез әле искә төшерик. Мин сезгә төрле милләт халыкларының орнаментлары белән бизәлгән житоннар әзерләдем. Һәр алган белемебезне искә төшереп тартмага шушы житоннарны салып барырбыз.

**Балалар**: -Татарстан Республикасында яшәүче милләтләр турында тыңладык.

**Тәрбияче:** -Әйе, димәк Татарстаныбыз күп милләтле булуы турындагы белемебезне салабыз сандыкка.

**Балалар**: -Курчакларның киемнәре турында сөйләштек.

**Тәрбияче:** -Милли киемнәр турында алган белемнәрне салабыз.

**Балалар**: -Җыр-биюле уен уйнадык.

**Тәрбияче:** -Җыр-биюле уеннныбызны салып куйыйк.

**Балалар**: -"Идел буе халыкларының милли костюмнары" дигән дидактик уенны уйнадык.

**Тәрбияче:** -Дидактик уенны белемнәр сандыгына салып куйдык.

**Тәрбияче:** - Балалар, шушы белем сандыгына салган белемебезне алдагы көннәрдә дә кулланырбыз. Ә бүген сезгә бик тырыш булганыгыз өчен яхшы, күтәренке кәеф бүләк итәм. Рәхим итеп кабул итегез. (Балаларга алдан әзерләп куйган смайликларны тәрбияче киертеп чыга). Саубуллашыр вакыт та килеп җиткән. Сау булыгыз балалар.

**Балалар:** - Сау булыгыз. ("Мин яратам сине Татарстан" көенә балалар чыгып китәләр).

# “ӘКИЯТ ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ”

(ТРИЗ методикасының уен алымнарын һәм элементларын кулланып, икенче кечкенәләр төркемендә ачык дәрес конспекты)

***Яруллина Алсу Рафик кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*

*“Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы*

*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат**:Балаларның табигый психологик һәм социаль-коммуникатив үсеше өчен шартлар тудыру,мөстәкыйль эшчәнлек тәҗрибәсен баету,уен алымнары һәм ТРИЗ методикасы элементлары ярдәмендә танып-белү мәсьәләләрен хәл итү.

**Бурычлар**:

1.Балаларны әкият геройларын, таныш әкиятләрне белергә, танырга өйрәтү;логик биремнәр чишә белү; сүзлек запасын активлаштыру,коммуникатив күнекмәләр формалаштыру; 2.Балаларның эмпатиягә сәләтен үстерүне дәвам итү; анализ, синтез, чагыштыру алымнары ярдәмендә фикер йөртә белү.Танып белү активлыгын, игътибар, хәтер, креатив фикерләүне камилләштерү, ТРИЗ методикасы элементлары ярдәмендә иҗади мөмкинлекләрен үстерү.

**Җиһазлау**:туп, “Тылсымлы капчык”,йомры икмәк, “Йомры икмәк” әкиятенә схема, кыргый җәнлекләр,кисмә рәсемнәр, альбом битләре.

Алдан эш: әкиятләр уку, хәрәкәтле уеннар уйнау, схема белән эшләү, проблемалы ситуацияләрне хәл итү.

***I.Кереш өлеш***

Мин бүген бик иртә тордым.

-Без дә.

- Үземне тәртипкә китердем.

-Без дә.

-Бик теләп бакчага килдем.

- Без дә.

-Кәефем шәп- мин шуңа шат.

-Безнең дә. Хәерле көн телибез сезгә. Исәнмәсез!(кунаклар белән исәнләшәләр)

***II.Төп өлеш.***

Хәерле иртә балалар,кәефләрегез ничек? Сез мине таныдыгызма? Әйе, мин, серле әкият иленнән Тылсымчы булам. Бүген шундый матур, кояшлы иртәдә мин сезгә әкият иленә сәяхәт кылырга тәкъдим итәм. Мондый сәяхәткә китәсегез киләме? Сез әкиятләр яратасызма, нинди әкиятләр беләсез? Хәзер тикшереп карыйм!

(тәрбияче балаларга туп ташлый, сораулар бирә, балалар туп тота һәм тәрбияченең сорауларына җавап бирә)

Әкиятләр ничек башлана? (борын-борын заманда.....)

-бабай белән әбидән, нәрсә качкан? (йомры икмәк)

-бабай нәрсә утырткан? (шалкан)

-Урманда бер өй тора,

Анда өч хайван яши,

Өч урындык, өч тәлинкә,

Өч караватъ, өч мендәр

Бу өйдә кемнәр торган? (өч аю)

-шалканны нәрсә тартып чыгарган?

нинди тавык әби-бабайны елаткан да, шатландырган да? (чуар тавык)

-малай кемнең тарагын урлаган? (су анасы)

Булдырдыгыз балалар, сез минем әкиятләр турында сорауларыма дөрес җавап бирдегез.

Әкиятләр дөньясына юл алыйк. Рәхим итегез!

***III.Практик өлеш.***

Балалар килегез әле. Менә монда тылсымлы бик матур бер капчык бар. Бу капчыкта минем балачак хатирәсе саклана. Биредә әкияттән килгән кунак бар.(йомры икмәне ала)

Бу нәрсә? (Йомры икмәк)

Тылсымчы: Балалар әбинең икмәге нинди булган соң? Балалар тотып карагыз әле.

Балалар: Түгәрәк, сары, матур.

Тәрбияче: Дөрес, йомры икмәк үзе түгәрәк, үзе кызарып пешкән. Тик ул бик матур

булсада , тыңлаусызбулган. Әбинең икмәге мичтән генә төшкән, бик кайнар. Икмәгебез тизрәк суынсын өчен әйдәгез аңа өрәбез.

(Балалар сулыш гимнастикасы ясыйлар)

Әкиятче: икмәккә ошаган тагын нәрсәләр беләсез?( *(метод анализ)(шар, туп,коймак...)*

Әкиятче: йомры икмәк белән нәрсә булган? (балаларның җаваплары)

*(Иҗади бирем – сынаулар һәм хаталар методы)*

Әкиятче: сез ничек йомры икмәккә ярдәм итәр идегез?

*Әкиятче серле капчыктан биттә сурәтләнгән схемалар ала.*

*Бирем: схемаларга карарга һәм анда нинди әкият яшеренгәнен әйтергә (“Йомры икмәк”)*

Әкиятче:йомры икмәккә юлында нәрсәләр очрый(капчыктан җәнлекләр ала)

төлке нинди (хәйләкәр, козгылт –сары төстә, йомшак)

куян нинди?(куян бәләкәй, куркак, колагы озын, койрыгы кыска)

Физик ял минуты үткәрелә: “Ак куянкай утырган”

Ак куянкай утырган, колакларын селкетә

Менә шулай, менә шулай, колакларын селкетә *(балалар чүгәләп колакларын куллары белән селкетәләр).*

Куян туңа башлагач аякларын селкетә

Менә шулай, менә шулай, аякларын селкетә *(балалар кулларын шапылдаталар)*

Куян тагы да туңа сикергәләп тә куя

Менә шулай, менә шулай сикергәләп тә куя *(балалар куян булып сикерәләр).*

*Тылсымчы капчыктан бияләй ала*

-Бу нәрсә балалар (бияләй)

-ул нинди( җылы, матур, кызыл)

-ул нәрсәдән эшләнгән?(җеп, тукыма)

-җеп һәм тукымадан тагын нәрсә бәйлиләр, тегәләр (балаларның җаваплары)

-бияләй нәрсә өчен кирәк?(кулларны җылытыр өчен, кайнар предметларны тотарга...)

- бияләйдә нәрсә яшәгән, ни өчен алар анда яшәгән?(балаларның җаваплары)

Ә хәзер үзегезне бияләйдә яшәүче хайваннар дип күз алдына китерегез (*эмпатия методы)*

*Тылсымчы балаларга сораулар бирә, балалар хайван исеменнән җавап бирәләр*

-Син нәрсә? Синең исемең ничек? Син кайда яшисең? Нәрсә белән тукланасың? Нәрсә эшләргә яратасың? Син нәрсәдән куркасың? Кем белән дус буласың?

Тылсымчы: минем серле капчыгымда кисмә рәсемнәр бар, ә экиятне дөрес итеп җыярга һәм кайсы әкият икәнен әйтергә кирәк.

-Булдырдыгыз балалар, афәрин!

*Тәрбияче капчыктан куян ала - ул елый.*

Балалар,сез ничек уйлыйсыз, нәрсә булды икән куянга, кем аны үпкәләткән? (балаларның җаваплары) Ә куянның ничек күңелен күтәрергә?

**IV.Рефлексив өлеш**

Нәни дусларым, безнең сәяхәт ахырына якынлаша. Миңа сезнең белән бик күңелле һәм кызыклы булды. Әйдәгез, искә төшерик, без сезнең белән кайда булдык? Нәрсәләр эшләдек? Сезгә күбрәк нәрсә ошады? Ә нәрсә ошамады?(балаларның җаваплары) Ә миңа сезнең ничек тырышуыгыз, актив булуыгыз ошады.

Ә хәзер мин сезгә куянның кәефен күтәрергә тәкъдим итәм.Карагыз әле, ул нинди моңсу. Моның өчен без кечкенә тылсымчыларга әвереләчәкбез. Ә безгә тылсымлы кисточкалар һәм кәгазь битләре ярдәмгә килер.( алдан шәмнәр белән ясалган битләр).

(Балалар эшкә керешә. Биттә төрле төстәге шарлары сурәте барлыкка килә.. Балалар шарларны куянга бүләк итәләр, куян шатланып әкияткә кайтып китә)

# Гаилә - имин юл күрсәтүче!

**Яруллина Фирдәвес Нәҗип кызы**

*«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Олы Кавал «Чишмэкей» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат.** Әти-әниләр, балалалар,мәктәп укучылары катнашында юл йөрү кагыйдәләре, юл билгеләре, яктырткыч элементлар, саклык каешы турында белемнәрне тикшерү һәм ныгыту;

-Юл йөрү кагыйдәләрен пропагандалау;

-Ярдәмчеллек, иптәшлек хисе тәрбияләү

**Бурычлар**:

**Белем бирү бурычлары**:Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү, кабатлау, ныгыту.

**Үстерү бурычлары:**Игътибарлылык, кабул итү, хәтер сәләтен үстерү.

**Тәрбияви бурычлар**: Үзара дуслык, ярдәмләшү хисләрен , юлда үзеңне дөрес тоту культурасын тәрбияләү. Юл йөрү кагыйдәләренә ихтирам ияту.

**Катнашучылар**. Әти-әниләр, балалар, мәктәп укучылары, тәрбияче, кече тәрбияче.

**Әзерлек эшләре**. Эшчәнлек өчен уен атрибутларын әзерләү, фликерлар алу.

**Эшчәнлек барышы.**

**1 өлеш**.

**Кереш**.Проекторда “Карлсон, который живёт на крыше» мультфильмы күрсәтелә. Мультфильм тәмамлануга ишектән Карлсон килеп керә:

**-**Ай-яй,әйләнде бит башларым. Мин яшәгән өй кайда соң, монысымы, монысымы?Адаштым бугай . (Як-ягына карана) Сез кемнәр, исәнмесез?

**Тәрбияче.**Исәнмесез , сез Карлсонмы әллә?

**Карлсон.** Әйе шул, мин Карлсон. Өй түбәсендә яшим. Менә вареньем бетте. Дус малаем янына тәрәзәдән генә очып кереп, варенье белән сыйланып чыкмакчы идем, тәрәзәләрен бикләп куйганнар. Ишекләреннән керермен дип җиргә очып төшүен төштем, менә хәзер адаштым, өйләрен дә таба алмыйм. Очып еракка да киткәнмен бугай.

**Тәрбияче.** Ул малайның адресын белмисеңме соң, ярдәм итәр идек үзеңә.

**Карлсон** Беләм-беләм. Адресы-Казан шәһәре, Тукай урамы, 5 йорт.

**Тәрбияче.** Ай-яй , син биик ерак очып киткәнсең бит. Ярый, тыңла, без сиңа ул йортны ничек табарга икәнен хәзер өйрәтербез. Аның өчен юл йөрү кагыйдәләрен үтәп йөрергә кирәк булачак.

**Карлсон.** Нинди кагыйдәләр соң ул? Мин яшәгән түбәдә бернинди дә андый кагыйдәләр юк.

**Тәрбияче.** Алай булгач, Карлсон, менә бездән өйрән. Күрәсеңме, менә балалар да, аларның әти-әниләре дә, мәктәптә укучы балалар да юл йөрү кагыйдәләрен, юл билгеләрен өйрәнергә җыелганнар.

**Карлсон.** Рәхмәт инде Сезгә. Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнермен дә дус малаем янына курыкмыйча кайтып китә алырмын.(Карлсон утыра)(Рәс №1)

**Төп өлеш.**

**Тәрбияче.**Исәнмесез балалар, хөрмәтле әти-әниләр, мәктәп укучылары!

(Рәс №1)

Без бергә- бер зур гаилә! Барыбызның да максаты уртак- нәниләребез сау-сәламәт, таза, нык, акыллы булып үссеннәр .

Без көн дә юлда йөрибез, сәфәр кылабыз. Юлларыбыз имин булсын дисәк, юл йөрү кагыйдәсен кечкенәдән үк үзләштерергә, истән чыгармаска тиешбез. Әйдәгез, менә бүген дә шул юл кагыйдәләрен искә төшерик. Балалар, әти-әниләр! Сезне "Гаилә-имин юл күрсәтүче! дигән эшлекле уенда актив катнашырга чакырам. Командалар сез әзерме?(Әйе).

Алай булгач уенны башлыйбыз.

Командалар белән таныш булыгыз :

1.Әти-әниләр - "Кызыл сигнал";

2. Мәктәпнең 6 нчы сыйныф укучылары - "Сары сигнал";

3. "Светофорик "отряды- "Яшел сигнал".

Бүгенге уенны хөкем итү өчен жюри әгъзалары итеп бакча мөдире Гөлүсә Галиахметовнаны тәкъдим итәм. Сез ризамы?(Әйе).Уенны башларга рөхсәт итегез.

***"Светофорик "отряды "Яшел сигнал" сәламләве:***

**Бала1.**

Без бакчага барабыз<br>Иртән ашыга –ашыга.<br>Машиналар ашыга,<br>Килеп чыга каршыга .

**Бала2.**

Ярый әле шул чакта<br>Светофор тора чатта.<br>Җемелдәтеп өч күзен<br>Әйтеп сала өч сүзен.

**Бала3.**

Кызыл әйтә: "Туктап кал!"<br>Сары әйтә: "Игътибар!"

Яшел әйтә: “Юл ачык!”

Карап кына атлап чык”

**Бала4.**

Әмма ләкин бер чатта

Светофор тормый сакта.

Юл аркылы чыгулар

Мең газап ла бу чакта.

Без бергәләп җырлыйбыз

Бүген сезгә бу хакта.

Урамнарда һәр чатта

Светофор торсын  сакта.

**Бала5.**

Җемелдәсен өч күзе,

Әйтеп торсын өч сүзне.

Кызыл әйтсен: “Туктап кал!”

Сары әйтсен: “Игътибар!”

Яшел әйтсен :”Юл ачык!

Әй сез, өлкән абыйлар,

Безнең хәлгә керегез.

Олы юллар чыкканда

Имгәнмәсен беркем дә.

Музыкаль сәламләү. Җыр “Мин-шофёр”

***“Кызыл сигнал” командасы сәламләве:***

**Әти**.Без командаларга  кайнар сәлам юллыйбыз,

Чын күңелдән дөрес җавап бирүләрен телибез.

**Әни**.Сезнең белән без

Ярышачакбыз!

**Әти.**Бирешмәскә

Тырышачакбыз!

**Әти**.Бүген без дә иренмәячәкбез,

Сорауларга җавап бирәчәкбез.

***“Сары сигнал” командасы сәламләве:***

**1 укучы**.Җырлап, күңел ачып,

Каршы командага

Әйтәбез дусларча: “Сәлам”

**2 бала.**Юл хәрәкәтләрен үтәргә

Өйрәтәчәкбез!

**3 бала**Аңлатачакбыз!

Күрсәтәчәкбез!

Сәламнәрне кабул иттек , ә хәзер бәйгеләргә күчәргә тәкъдим итәм .

**1 бәйге.“ Булсаң зирәк, әйт тизрәк”** дип аталган табышмакларга, сорауларга җаваплар табу уены.

**“Кызыл сигнал”** “ командасына сораулар:

1.Юл чатында тора батыр, күзләре төрле – төрле,

Берсен йома, берсен ача- аны белә һәр кеше (светофор)

2.Ике мөгезле, теле юк,

Йөргән юлда эзе юк . Нәрсә ул?

( Троллейбус)

3.Ат түгел ул, кешнәми, йөз аттан ким эшләми.

Үзе тыр да тыр килә,

Йә, нәрсә бу, кем белә? (трактор)

4. Нәрсә ул зебра?(җәяүлеләр юлны чыга торган урын)

***“Сары сигнал****” командасына сораулар:*

1.Нинди гаҗәп өй бу?

Һәр ягы тәрәзәле,

Аягында резина,

Бар ашаганы бензин.

Бу нинди өй?(автобус)

2.Тәрәзәле һәр ягы, җиргә тими аягы

Сыртында бар дугасы,

йә, бу нинди юрга соң? (трамвай)

3.Нәрсә ул светофор? ( юлдагы хәрәкәтне көйләүче җайланма)

4. Җәмәгать транспортын көтү урыны ничек атала?(остановка/тукталыш)

**“Яшел сигнал**” командасына сораулар:

1.Алда да бар, артта да бар,

Борылган да, сырылган.

Озын буып сузылган (юл)

2.Юлны чыкканда башта кайсы якка таба карыйлар?(сулга)

3. Җәяүлеләр йөри торган юлның өлеше ничек дип атала?( тротуар)

4.Светофор сигналлары турында нәрсә беләсең?

Җавапларны бик тиз таптыгыз, ә хәзер кызыклы уен тәкъдим итәм.

**2 бәйге.Уен.“Автомастерская/Автомабильләрне ремонтлау мастерское”**

Уен барышы.Безнең әти-әниләр күбесе автомобиль йөртүчеләр. Автомобильләр ватылган очракта, сез ничек хәл итәсез икән,хәзер шуны тикшерәбез. Һәр команда өстәлендә ремонт таләп ителүче транспорт чаралары ята, шуларны тиз арада “ремонларга” кирәк булачак. Биремне дөрес итеп алдан үтәп бетергән команда җиңүче була.

**3 бәйге.“Ягулык салу станциясе» уены**. Безнең әти-әниләр күбесе автомобиль йөртүчеләр дигән идек инде. Автомобилегезнең багында бензин беткән очракта нишлисез?(Җаваплар тыңлана) .

***Уен барышы.***Чират буенча бер сулы савыттан икенче савытка су(бензин) ташу уены башкарыла.

**3 бәйге Бирем үтәргә. “Юл билгесе өчен урын тап”**

***Уен барышы .***

Командалар бергә уйныйлар.

Өстәлдә “Шәһәр урамы” рәсеме(юл билгеләре, светофор ясалмаган рәсем) һәм төрле юл билгеләре,светофор рәсемнәре ята.(Рәс №2) Чират буенча барып һәр катнашучы рәсемгә дөрес итеп юл билгеләрен урнаштыра, кире килеп урынына баскач, икенче катнашучы барып урнаштыруны дәвам итә. Кайсы команда тиз һәм дөрес башкара шул җиңүче була.

**(Рәс №2)**

Уенга нәтиҗә ясау өчен сүз әтиләргә бирелә. Алар рәсемдә юл билгеләренең, светофорларның, транспорт чарарларының дөрес итеп урнаштырылуларын карап йомгак ясыйлар, балаларны мактыйлар.

***Музыкаль тәнәфес*.**

1.Балалар башкаруында бию “Күңелле светофор”.

2.Әни башкаруында шигырь “Светофор”

**4 бәйге. Түгәрәк уены. “Жезл”**

**Уен барышы**.Барлык катнашучылар түгәрәкләнеп басалар.Уен барышында жезл кулдан кулга бирелә, алып баручы:

“ Бер, ике, өч, жезл кемдә тукталды?” дип әйтеп бетерешкә жезл кем кулында кала, шуңа сорау бирелә (Сораулар юлдагы ситуацияләрне чагылдырган рәсемнәрдәге хаталарны табуга юнәлдерелә)

**5 бәйге** “Юлдагы ситуацияләр” дигән тема буенча **“Өй эше”** бәйгесен

бәяләү**.**Сүз командаларга бирелә. Һәр гаилә үзләре ясап алып килгән рәсемне яклап чыгыш ясый.

**6 бәйге.** Кисеп-ябыштыру. Бердәм эшчәнлек

Тема. Минем яраткан светофорым".

**Максат.** Светофор төсләрен, сигналларының нәрсә аңлатканын истә калдыру, үзара ярдәмләшеп эшләү, бердәм эшчәнлектән канәгатьләнү хисләрен кичерү.

**Йомгак өлеше.**

**Тәрбияче.** Яле, Карлсон, юл йөрү кагыйдәләре, юл билгеләре турында белемнәр туплый алдыңмы?

**Карлсон.** Дусларым, бик зур рәхмәт Сезгә. Юл йөрү кагыйдәләрен дә өйрәндем , юл билгеләренең нәрсә икәнен дә белдем. Юл кагыйдәләрен төгәл үтәргә сүз бирәм!

**Тәрбияче.** Ярар Карлсон, без бик шат. Иң мөһиме син адресыңны беләсең. Сез балалар үзегез яшәгән җирнең адресын беләсезме? Әйтеп карагыз әле?

**Балалар җавабы.** Мин Биектау районы, Олы Кавал авылы, Мәктәп урамы 5 нче йортта яшим һ.б.

**Тәрбияче.** Әфәрин, балалар,булдырдыгыз. Һәр кеше үз адресын әйтә белергә тиеш.

**Карлсон.** Хушыгыз, балалар, миңа китәргә кирәк.

**Бергә** Хуш, Карлсон.(Карлсон "очып" китә)

**Проекторда мультфильм күрсәтү** "Карлсон, который живёт на крыше»

**Тәрбияче.**Менә күрдегезме, дусларым, юл кагыйдәләрен белгәч, Карлсон бик тиз генә дус малае янына кайтып җитә алды.

Ә хәзер йомгаклау өчен сүзне хөрмәтле жюрига бирәбез.

**Жюри члены.** Кадерле балалар, хөрмәтле әти –әниләр, мәктәптә укучылар. Шулай итеп, юл кагыйдәләрен өйрәнүгә, кабатлап ныгытуга багышланган чара тәмам. Юлларыбыз хәвеф – хәтәрсез булсын дисәк, юл кагыйдәләрен беркайчан да истән чыгармыйк. Юлларда үзебезне дөрес тотыйк, шуларга балаларыбызны да өйрәтик. Бүгенеге күтәренке күңел, бердәмлек, көндәлек юлдашыгыз булсын! Рәхмәт.

**Күмәк җыр. "Светофор"**

## “Икмәк иң зур байлык”

*(Мәктәпкә әзерлек төркемендә клуб сәгате)*

**Закирова Чулпан Габделбәр кызы,**

**Хәбибуллина Лилия Юрьий кызы**

*Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

*“Салавыч балалар бакчасы”*

**Максат:** Ипинең килеп чгышын өйрәнү. Ипи пешерүнең борынгы ысулларын аңлату.Игенченең мактаулы һәм авыр хезмәте, икмәкнең нинди юллар аша табынга килүе турындагы белемнәрен ныгыту.Ипи турында туган телдә мәкаль әйтемнәрне өйрәтү. Бергәләп ипи пешереп карау.

**Бурычлар:** Балаларга көзге байлыкның халыкка шатлык, куаныч китерүен төшендерү, бу байлыкларны тудыручы игенчеләр хезмәтенә карата хөрмәт тәрбияләү.Балаларның бәйләнешле сөйләм телен, игътибар, хәтер, белемгә омтылышларын үстерү; төрле һөнәр ияләренә карата кызыксыну тәрбияләү.

**Җиһазлау:** презентация, китаплар, уеннар, картиналар, камыр, калфак һәм алъяпкычлар.

**Тәрбияче:**

**I пункт.**

-Исәнмесез, балалар.

-Исәнмесез.

-Бүген безнең клуб сәгате бик кызык һәм мавыктыргыч булыр. Нәрсә турында беләсегез киләме? Алайса игътибар белән тыңлагыз. ***(****Бүлмәдә ипи турында призентация күрсәтү. Табышмак ярдәмендә ипине чыгару.)*

- Үзе хуш исле, ләкин хушбуй түгел.
  Үзе түгәрәк, ләкин туп түгел.
  Үзе кызарып пешә ләкин пәрәмәч түгел. *( Ипи)*

-Әфәрин! Әйе бик дөрес.Ипи. Ипи өстәлгә каян килә соң? Сез бу турыда беләсезме? Балалар ипи бик кадерле, хөрмәтле һәм иң тәмле ризык ул балалар. Ә ни өчен икәнен клуб сәгате ахырында сез миңа әйтерсез яме. Сезнең ипинең барлыкка килү юлын беләсегез, күрәсегез киләме?

- Алайса юлга кузгалыйк. Ә ничек уйлыйсыз ипинең килеп чыгышын белер өчен нинди пунктларга барасыгыз килә.

- Әйдәгез автопаркка юлга кузгалабыз.

**II пункт.**

**Автопаркта –** механизаторлар Иванов Радик һәм Саттаров Рәфкать белән очрашу.

- Исәнмесез балалар.
- Балалар механизатор ипи турында нәрсә беләләр икән.? Аларның ипинең барлыкка килүендә нинди катнашы бар? Сезнең нинди сорауларыгыз бар?
- Механизатор булып эшләр өчен җир анабызны яратырга, аның турында кайгыртырга кирәк. Басуны әшкәртергә безгә менә шундый техникалар ярдәмкә килә.
- Рәхмәт сезгә. Исән сау эшләгез. Балалар сез ничек уйлыйсыз, комбайн бушаткан ашлык кая бара?
- Бик дөрес! Әйдәгез амбарга юл тотыйк.

**III пункт.**

**Амбарда** – аграном Габделбәр Әлтәфович каршы ала.

-Исәнмесез балалар, хәлләрегез ничек?

- Балалар сез монда нәрсә күрәсез?

- Балалар ашлык турында нәрсә беләсез? Сорауларыгызны бирә аласыз. Ул “Татарстан” колхозының баш аграномы.

- Менә бу АВМга комбаиннан, басудан бодай, солы, арпа кайта. Кайткан ашлыкны монда чистартабыз, киптерәбез һәм он итеп тарттырыр өчен тегермәнгә җибәрәбез. Ә оннан нәрсә пешереп була инде?

- Әйдәгез пекарняга юл тотыйк.

**IV пункт.**

**Пекарьняда –**пешекче Сәмигуллина Фирдия каршы ала.

**Балалар:** Исәнмесез!

**-** Исәнмесез, балалар пешерү цехына рәхим итегез.

**Тәрбияче:** Балалар тегермәннән он шушы пешерү цехына килә икән. Фирдия апага нинди сорауларыгыз бар? Ипине ничек пешергәннәрен беләсегез киләме?

*(Фирдия апа ипи пешерү технологиясен сөйли, күрсәтә. Балалар үзләрен кызыксындырган сорауларын бирәләр.)*

**Фирдияапа**: Бездән шушындый тәмле, хуш исле ипиләр кая баралар, сез беләсезме?

- Бик дөрес. Инде кибеткә юл тотыйк.

**V пункт.**

**Кибеттә -** кибетче Галләмова Галина каршы ала.

**Балалар: Исәнмесез? Галина Семеновна сездә кибеттә ипи бармы?**

**Галина Семеновна:** Бар балалар. Ипи бик кадерле ризык. Шуңа күрә без аны түргә урнаштырабыз. Ул бит ипи киштәсенә бик озын юлларны үтеп килә. Аны пешерер өчен бик күп кешенең хезмәте кергән.

**Балалар:** Апа, ни өчен ипине аерым пакет белән тотасыз. *(балалар үзләренең сорауларын бирәләр)*

**Галина Семеновна:** Сез үзегез дә бик күп беләсез икән. Өйдә әниләрегез ипи пешерәме соң? Ничек итеп пешерәләр?

**Тәрбияче:** Балалар Галина Семеновнага рәхмәтләребезне әйтик тә, үзебезнең остаханәгә кайтып ипи пешереп карыйсыгыз киләме?

**Тәрбияче:** Әйдәгез алайса соңгы пункт, остаханәгә кайтабыз.

**VI пункт.**

**Остаханәдә .**

**Тәрбияче:** Әйдәгез балалар, хәзер инде сез ипи нең каян килгәнен белдегез. Тотып карадыгыз, тәмен тойдыгыз. Инде хәзер үзегезнең хыялый уйларыгызны, фикерләрегезне эшкә җигик тә, үзебез ипи пешереп ашап карыйбызмы?

**Тәрбияче:** Эшне башлаганчы , иң элек нишләргә кирәк? Ничекуйлыйсыз?

**Тәрбияче:** Бик дөрес. Иң элек кулларны сабынлап юып, башка яулык бәйлибез.

Менә безнен "Ипи каян килә?"- дигән клуб сәгатебез тәмам.

-Сез кайда булдыгыз?

-Нәрсә белдегез?

- Балалар ипи ни өчен бик кадерле, хөрмәтле һәм иң тәмле ризык инде? Сез ничек уйлыйсыз?

-Клуб сәгате турында кемгә сөйлисез?

-Синең исендә нәрсә калды?

-Анда тагын барыр идеңме?

**Тәрбияче:** Балалар һәрвакытты да тырыш, кыю, тәртипле, игътибарлы. булыгыз. Ә элекеге әби-бабаларыбыз: "Тырышкан-моратына ирешкән"-дигән.

# “Әбиемнең күңел сандыгы”

*(Зурлар төркемендә клуб сәгате)*

**Сайфетдинова Гөлия Зуфаровна**

**Сайфелганиева Миләүшә Альвертовна**

*Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе“Салавыч балалар бакчасы”*

**Бурычлар:**буыннан-буынга истәлек булып калган эйберләрнең исемнәрен хәтердә калдырып сүзлек запасын баету;

- балаларда халкыбызның тарихына карата кызыксыну уяту, татар халкының үткәне белән таныштыруны дәвам итү;мөстәкыйль иҗат итү сәләтен үстерү;

- татар халкы белән горурлану хисе һәм аңа карата ихтирам тәрбияләү, буыннар арасындагы бәйләнешен ныгыту.

**Җиһазлар:**музей әсбаплары ,китаплар, презентация ”Туган авылым элек һәм хәзер” дигән темага, өй күренеше, фотографияләр,төзү материаллары,карандашлар, альбом битләре,төсле кәгазъләр,күрсәтмә план-схема.

**Сүзлек эше:** мөнәҗәт,такмаза,мәкаль сандык, киндер сөлге...

**Кичә барышы:**

**Тәрбияче:**исәнмесез,балалар.

**Балалар:**исәнмесез.

Тәрбияче: без бүген сезнең белән клуб сәгатендә музейлар турында сөйләшербез.Ә нәрсә соң ул-музей?(элеккеге әйберләр саклана торган бүлмә)Авылыбыз тарихы,аның истәлекле урыннары, данлыклы кешеләрен барларбыз.Балалар, без кайсы авылда яшибез?

-Салавыч авылында.

-Сезгә туган авылыгыз ошыймы, ни өчен ошый?Без нинди телдә сөйләшәбез?(балалар җаваплары тыңланыла)

-Безнең авыл бик матур һәм аның тарихы бар.

**1 бүлмә - зурлар төркемендә Презентация күрсәтелә.**

**Слайдлар:**

1.Элеккеге өйләр.

2. Элеккеге киемле кешеләр.

3.Аларның эш кораллары.

4.Кешеләрнең хезмәте.

5.Хәзерге өйләр.

6.Хәзерге киемнәре.

7.Хәзерге хезмәтләре.

7.Транспорт хәзерге.

-Менә без авылның элеккеге тормышы һәм хәзерге тормышы белән таныштык.Ә менә музейларга элеккеге әйберләрне ничек тапканнарын ,авылның үткәнен ничек белгәннәрен белер өчен без хәзер төрле җирләрдә булырбыз. Сез клуб сәгатендә үзегезне ничек тотарга кирәген беләсез инде.

**2 бүлмә- архив .**

Нурия Каюмовна сөйли-архив хезмәткәре була.

-Балалар,элеккеге документлар шушы бүлмәдә сакланган.Бу архив дип атала.Архивтагы документлар югалмыйлар.Авылның тарихын шуннан эзләп табалар.Документлар монда бик күп еллар сакланалар, чөнки алар бик кирәкле-шулар аша без авылның тарихын беләбез.Буыннан буынга сөйләп калдырабыз.

**3 бүлмә-китапханә .**

Гөлназ Маратовна китапханәче булып сөйли.

-Исәнмесез,балалар.Бу бүлмәдә бик күп китаплар саклана.Менә бу калын китап-энциклопедия дип атала, анда авыллар турында бик күп мәгълүмәт тупланган. Аларны архивтан алып эшләгәннәр, сез анда булдыгыз инде.Китапларны саклап тотарга кирәк –чөнки алар юкка чыкса авылыбыз тарихын белә алмыйбыз бит.

**4 бүлмә- өй күренеше элекеге(кечкенәләр төркемендә )**

Энҗе Рафисовна сөйли – тәрбияче.

Монда берничә баланың әбиләре җыелган.

-Исәнмесез,

балалар.

-Исәнмесез.

**Әбиләр:**балалар, карагыз әле, элекеге авыл өйләрен нинди алар. Элек татар өенең түрендә төп хуҗа булып сандык торган. Сандыкта буыннан-буынга тапшыра торган әйберләр саклана.(карыйлар) Каршыда-пөхтә итеп җыелган карават.Анда татар халык бизәкләре чигелгән мендәрләр өеп куелган.Карават өстенә чигүле япмалар җәелгән.Бер якта-сәке, уртада өстәл.Өстәлдә самавар, чынаяклар. Карават белән утыргыч арасында йон эрли торган каба тора.

Әбиләр авылның тарихы,күренекле кешеләре,истәлекле урыннары турында сөйлиләр.

**Тәрбияче:**Балалар,элекеге әйберләрне күрер өчен мин сезне музейга барырга тәкъдим итәм.

5 **бүлмә- музей бүлмәсе.**

Гөлия Зөфәровна сөйли –экскурсовод булып.

-Исәнмесез ,балалар.Безнең музеебызга рәхим итегез.Музеебызда бик күп элекеге эйберләр тупланган -менә алар.Кайсыгыз таный икән мондагы эйберләрне.(лампалар,читекләр.кер югычлар,үлчәүләр.кукрәкчәләр,һ.б.)Һәрберсе турында сөйләнелә.

**6 бүлмә-остаханә** (чишенү бүлмәсендә)

Илшат Рашитович эшче ролендә сөйли.

-Балалар,исәнмесез.

-Исәнмесез.

-Рәхим итегез остаханәгә.Балалар,туган авылыбызның өйләрен күзалдына китерик ,әле.Остаханәдә сезгә өй ясар,төзер өчен материаллар куелган.

Сез үзегезгә кирәкле материалны алып өйләр төзисез - кемгә нинди өй ошый (легодан,кәгазъдән,пластилиннан,кисеп ябыштырып, рәсемен ясап өй ясыйлар.Ясаган,төзегән өйләребездән күргәзмә оештырыйк әле.

Рәхмәт балалар,кайда гына булсагызда туган авылыгызны,туган өегезне онытмагыз, горурланыгыз. Тарих белән кызыксыныгыз,элеккеге әйберләне саклагыз,борынгы әйберләр булса музеебызга алып килегез.Сау булыгыз.

Балалар төркемнәргә кайталар.Түгәрәк өстәл артында сөйләшәләр.

**Тәрбияче:** Без бүген клуб сәгатендә ниләр белдек ,кайларда булдык, безгә кунакка кемнәр килде? Белгәннәрегезне кемнәргә сөйлисез ?Әти-әниләрегездән сорагыз әле алар нәрсәләр беләләр икән авылыбыз турында. Нәрсә исегездә кады сезнең? Тагын шунда барырга телисезме? Тәртип кагыйдәләрен сакладыгызмы? Рәхмәт сау булыгыз.

## Оста куллы Бабаем

**Мөхәммәдиева Энҗе Рафис кызы**
**Галимуллин Илшат Рәшит улы**

*Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе "Салавыч балалар бакчасы"*

**Максат:** Уртанчылар төркемендә йорүче балаларның буыннан -бунга килә торган кәсепләрен өйрәнү. Төрле халыкларның кәсебе булган агач эше белән якыннанрак таныштыру. Борынгы

агач нәкыш сәнгате һәм хәзерге нәкыш сәгатен бәяләргә өйрәтү. Югала барган сүзлекне кабат яңарту, бала күнеледә калдыру.

**Сүзлек:** Нәкыш,өтерге, чүкеч,ышкы,кайрак,беләү..

**Җиһазлау:** кул эшләреннән эшләнелгән призентация,агачтан эшләнелгән кул эшләре, мастерской, станоклар, кыру өчен кирәкле материаллар.

**Тәрбияче:**

**I пункт**

Алдан ук әзерләнгән күргәзмә почмагына бару.

-Карагыз әле балалар, кул эшләреннән эшләнгән күргәзмә.

- Бу эшләр нинди материаллардан эшләнгән микэн? (тукымадан, пласмастан)

- Балалар җавабы….

- Бу кул эшләрен кем, ничек итеп эшләделәр микән? кайсыгыз белә.

-Альбина елап керә (кулын тотып)

-Альбина Альвертовна, сезгә ни булды ник елыйсыз?

-Хай балалар кулыма чүкеч белән суктым.

- Эй Альбина Альбертовна, сез куркынычсызлык кагыйдәләрен белми идегез мени?

- Ә сез балалар, эш кораллары белән эшләгән вакытта куркынычсызлык кагыйдәләрен беләсезме?

-Әйдәгез әле Альбина Альбертовнаны куркынычсызлык кагыйдәләрен өйрәтә торган пунктка алып барыйк әле.

**II пункт Инструктаж бүлмәсе**

Инструктаж ничек уздырыла, нинди төр инструкажлар бар. (Инструктор аңлата)

Балар кулларына төрле эш кораллары алалар, Альбина Альбертовнага куркынычсызлык кагыйдәләрен аңлаталар.

- Куркынычсызлык кагыйдәләрен белгәч, инструктажлар уздыргач, без сезнең белән кул эшләре эшли торган мастерскойга юл тотыйк.

**III пункт**

Исәнмесез Рәсим абый, безнең баларның сез эшләгән кул эшләре белән таныштырып китә алмассызмы икән?

- Балалар, сезненәрсәкызыксындыра? Рәсимабыегызгасорауларыгызныбирегез?

-Балалар ….

-Рәсим: Сезнеңдәүзкулларыгызбеләнагачтанкулэшләреясыйсыгызкиләме?

-Балалар….

- Рәсим: менәминсезгәкулланыштанкалганагачматериалларыбирәм, сезузегезтеләгәнкулэшләренэшлиаласыз.

РәхмәтРәсимабый, киңәшләрегезөчен,

әхәзербезүзебезнеңкечкенәгенәмастерскоебызгакайтыйк.

**VIПункт**

**Үзебезнеңбалаларбакчасындагыкечкенәмастерскоебызгакайту.**

Балалар, әйдәгезәлеүзебезнеңмастерскоебыздаРәсимабыйкебеккулэшләренясыйк,

һәмүзебезнеңкүргәзмәбезнебулдырыйк.

Күргәзмәдән соң балалрга сораулар

-Сезнең үскәч кем буласыгыз килә?

- Балалар фикере ….

## Лалә чәчәге бизәге

**Минһаҗева Роза Гаптелхай кызы**

*Биектаумуниципаль районы Иске Казан*

*төп белем бирү мәктәбе*

**Максат:** Әвәләү аша лалә чәчәге бизәге белән таныштыру.

**Бурычлар:**

- милли сәнгатькә мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү;
- бәйләнешле сөйләм телен үстерү;
- вак моториканы үстерү;
- табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлау:** курчаклар, ноутбук, проектор, интерактив такта, хат, лалә чәчәге рәсеме, катыргылар, пластилиннар, такталар, чигүле мендәр

**Барышы.**

*Тәфтиләү (татар халык көе) җыры яңгырый. Балалар көй астында, төркем бүлмәсендә уйныйлар.*

**Тәрбияче:** Балалар, карагыз әле, безгә кунаклар килгән икән бит, Гомәр белән Гөлбикә.

*Курчаклар исәнләшә, балалар да исәнләшәләр.*

-Әйдәгез, балалар, кулга-кул тотынышып бер-беребезгә үзебезнең сәламебезне, җылыбызны бүләк итик әле.

Кулларга без тотындык,

Бер-беребезгә елмайдык.

Җылы китте кулларга,

Рәхәт булды дусларга.

**Гомәр:** Балалар, без сезгә үзебезнең дустыбыз Айсылудан хат алып килдек.

**Тәрбияче:** Нәрсә язылган икән? Укып карыйбызмы, балалар? (*Балаларның җаваплары*)

-Ягез, утырышыйк әле. (*Тәрбияче хатны укый*)

“Исәнмесез, кадерле балалар! Сезгә бик зур үтенечем бар иде. Безнең шәһәребездә күргәзмә оештырыла. Аны карарга чит илләрдән дә кунаклар киләчәк. Минем үзебезнең татар халкыбызның милли бизәкләреннән күргәзмә ясап, кунакларга күрсәтәсем, таныштырасым килә. Ләкин мин ул бизәкләрне ясап өлгерә алмыйм. Сез миңа лалә чәчәкләре ясарга ярдәм итә алмассыз микән? Сәлам белән Айсылу”

-Балалар, Айсылу бик зур эш эшләмәкче була икән. Аңа ярдәм итәбезме? (*Балаларның җаваплары*)

**Гөлбикә:**Балалар, сез лалә чәчәген беләсезме, күргәнегез бармы? (*Балаларның җаваплары*)

**Тәрбияче:** Менә ул лалә чәчәге. (*Тәрбияче рәсемен күрсәтә*) Бик матур чәчәк, шулай бит, балалар? Ул бакчада үсә. Яз җитеп, карлар эрегәч, тишелеп чыга да матур итеп чәчәк ата.

**Гөлбикә:** Балалар, мин сезгә лалә чәчәге турында бик матур бер шигырь сөйләп күрсәтим әле.

Кызыл лалә чәчәкләрен

Әбием бик ярата,

Сулар сибеп карап тора,

Туфракларын йомшарта.

**Тәрбияче:** Балалар, әби чәчәкләрне ничек итеп карый? (*Балаларның җаваплары*)

Әби лалә чәчәкләренең нинди төсләрен ярата. ( *Балаларның җаваплары*)

-Балалар, сезнең лалә чәчәгенең нинди төсләрен күргәнегез бар? Сезнең бакчада ниндиләре үсә? (*Балаларның җаваплары*) Тактага карагыз әле, бу бакчада нинди төсләләре бар икән? ( **1 нче слайд** ) (*Балаларның җаваплары*)

-Балалар, лалә чәчәге бизәге төрле формаларда, төрле төсләрдә була (**2 слайд**).

Аны киемнәргә дә, сөлгеләргә, түбәтәйләргә, читекләргә дә чиккәннәр. (**3 слайд**)

**Гөлбикә:** Менә минем алъяпкычымда да бар ул.

**Тәрбияче:** Балалар, карагыз әле, ничек матур итеп чигелгән. Балалар, сез лалә чәчәгенең нинди икәнлеген белдегез, ә хәзер Айсылуга ярдәм итәбезме? (*Балаларның җаваплары*) Алайсам, өстәл артына утырыйк та, эшкә керешик. Айсылу безгә үрнәген биреп җибәргән, карагыз әле. (*Тәрбияче үрнәкне күрсәтә*) Менә катыргыга ясалган чәчәкләребез дә әзер. Безгә аларны матур төсләргә генә кертергә кирәк. Ә төсләрне сез үзегез сайлагыз. (*һәр баладан нинди төс сайлауларын сорый*)

**Тәрбияче:** Балалар, беренче эш итеп без шарчыклар ясарбыз. Аның өчен нишләргә кирәк әле? (*Балалар тәрбиячегә карап эшлиләр*)

-Балалар, әйдәгез, эшебезне дәвам иткәнче әзрәк ял итеп алыйк. «Зәңгәр чәчәк» уенын уйнап алабызмы?

**“Зәңгәр чәчәк” уены**

*Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкясыйлар. Бер бала, чигүле кечкенә мендәртотып, уртага чыгып баса. Балалартүгәрәк буенча җырлап әйләнәләр:*

Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар
Зәңгәр чәчәк ярата.

*Кырыйдагы балалар туктап биеп-җырлап торалар, ә уртадагыбала, мендәр тотып, түгәрәк буенча биепйөри:*

Якын дуслар арасыннан
Берсен сайлап ал әле.
Тезләреңә ипле булыр -
Мендәреңне сал әле.

*Мендәр тоткан бала мендәрен бер балаалдына куя һәм, тезләнеп, аңа кулын бирә.Ул бала аның тирәли әйләнә, башкалар кулчабып торалар.*

**Тәрбияче:** Ә хәзер эшебезне дәвам итик. Шарчыкларыбызны чәчәгебезнең уртасына ябыштырыйк. (*Тәрбияче, Гомәр һәм Гөлбикә балаларны мактыйлар*)

**Тәрбияче:** Балалар, бик матур булды. Әйдәгез, эшләребезне үзебезнең күргәзмәгә куеп карыйк. Матур килеп чыкты микән?

- Балалар, сезгә ошыймы?

- Без бүген сезнең белән нинди бизәк ясадык?

**Гөлбикә:** Балалар бигрәк матур килеп чыкты. Булдырдыгыз! Айсылуга бик тә ошар инде. Рәхмәт, сезгә. Безгә китәргә кирәк. Сау булыгыз, балалар! (*Балалар саубуллашалар*)

## Нәрсә ул акча?

(Мәктәпкә әзерлек төркеме)

**Әхмәтханова Гөлсинә Камил кызы**

*"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының "Кече Рәс "Дуслык" балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе"*

Максаты: балаларны акчалар һәм аларның тарихы белән таныштыру.

Бурычлар:

***Белем бирү бурычы:***

- акча белән таныштыру.

***Үстерү бурычы:***

- икътисад элементлары турында күзаллауны киңәйтү;
- тикшеренү эшчәнлегендә белем формалаштыру;
- пространство мөнәсәбәтләрен модельләштерү сәләтен үстерү;
- предметларның авырлыгы турында күзаллауларны формалаштыру.

***Тәрбияви:***

-балаларда кызыксынучанлык, күзәтүчәнлек тәрбияләү;

- күмәк эштә дустанә мөнәсәбәтләрне тәрбияләү, гомуми фикерләргә туры китереп вазыйфаларны бүлә белү.;
- хезмәткә хөрмәт тәрбияләү;
- акчаларга карата сакчыл караш тәрбияләү.

Эшчәнлек барышы:

Тәрбияче: Исәнмесез, балалар! Хәерле иртә.

-Исәнмесез!

-Хәлләрегез ничек!

-Әйбәт, яхшы

Балалар, карагыз эле, минем кулымда нәрсә?

-Тартма.

Тартмадагы тавышларны тыңлагыз һәм монда нәрсә икәнлеген белергә тырышыгыз. (Балалар белән тартманы селкетеп карау.)

Балалар җавабы (акчалар)

Тәрбияче: тикшереп карыйк, ачам.Әйе, дөрес, акчалар.

-Балалар, нинди акчалар монда?

-монета( тәңкә, тимер акча) .

-купюра( кәгазь акча)

-Карагыз әле, монда ракушкалар да бар бит.

Сез ничек уйлыйсыз:ни өчен ракушкалар акчалар арасында?

-Түгәрәк булганы өченме?

-(балалар җавабы)

-Минем үземә дә бик кызык балалар.Әйдәгез ,балалар , без хәзер исследовательләр( эзләнү-тикшеренүчеләр) булабыз.Акча турында күбрәк белербез. Ракушканың ни өчен акчалар арасында булуын ачыкларбыз.

Балалар, сезнең барыгызның да акча күргәнегез , аны кулланганыгыз бар, шулай бит? Ә сез ничек уйлыйсыз,элек, бик борынгы заманнарда акчалар булды микән? Уңайлы итеп мендәрчекләргә утырабыз. Бик азга гына борынгы заманга кайтып киләбез.

Тәрбияче: димәк,борынгы кешеләрнең дә акчалары булган.  Алар нинди булган? (Сөякләр, кабырчыклар). Ни өчен тартмада ракушка булып чыкты? (Бу борынгы акча)

4 слайд (хәзерге тимеракчалар)

5  слайд ( хәзерге кәгазь акчалар)

Тәрбияче: Балалар,  башта  нинди акчалар  барлыкка килгән икән соң? Металл(тимер)  яки кәгазь?

(Балалар җавабы-металл (тимер) акчалар)

Тимер акчаларны икенче төрле тәңкәләр дип тә атыйлар.

***Димәк , башта тимер акчалар , аннары кәгазь акчалар барлыкка килгән***

Тәрбияче: балалар, ә хәзер мин сезне “Вакыт елгасы” кырыена чакырам. Әйдәгез, «Вакыт елгасы " на килик һәм анда акча рәсеме төшерелгән рәсемнәрне урнаштырыйк.

*(балалар вакыт елгасына акчаларны ябыштыра)*

Тәрбияче: Афәрин! Балалар, ә сез ничек уйлыйсыз, тимер акчаларны  кулланырга  җайлымы әллә кәгазь акчаларнымы?

(Балаларның җаваплары).

Тәрбияче: тәңкәләр яки купюраларның уңайлы булуын ничек аңларга соң? Ә бәлки без моны тикшерербез? Сезнең өчен лаборатория ачылды, без исә Сезнең белән тикшерүчеләр. Барыгыз да  уңайлы итеп  урнашыгыз. Без  тимер һәм кәгазь акчаларның  кайсысы уңайлы булуын белү өчен килдек. Чын тикшеренүчеләр буларак, без тәҗрибә нәтиҗәләрен тактада язачакбыз.

1 эксперимент:

Кәгазь акчаны алып, аны бөкләп  карыйк.  Ертып карагыз әле. Ә хәзер шулай ук   тәңкә белән эшләгез. Нинди нәтиҗә ясарга була?

Нәтиҗә: тәңкә яхшырак, ул бөгелми һәм ертылмый да.

(Нәтиҗә ясый балалар).

Тәрбияче: киресенчә, тәңкәгә плюс куябыз, бу экспериментта тәңкә иң яхшы сыйфатларны күрсәтте.

2 эксперимент:

Хәзер кәгазь акчаны суга тыгабыз.Кәгазь акча нишләде?

(Юешләнде)

Ә хәзер тәңкәне тикшерәбез. Нәрсә булачак? Нинди нәтиҗә ясыйбыз? Кем ота бу экспериментта? ...тактада билге ясa.

Нәтиҗә:кәгазь акча юешләнә, ә тәңкә юк.

3 эксперимент:

Әйдәгез, хәзер бу акчаларның авырлыгын үлчик. Кулыгызга тәңкә һәм купюраны алыгыз,нәрсә авыррак?

Нәтиҗә: Кәгазь акча җиңелрәк.

4 эксперимент:

Мин сезнең өчен кошелеклар  әзерләдем. Башта купюраны кошелекка, ә аннары тәңкәләрне салыгыз. Өстен аска әйләндерегез, селкетегез.  Нинди акчаны  кошелекта  саклау уңайлырак?

Нәтиҗә: купюраны саклау җайлы.

Тәрбияче: карагыз әле кем ота? (Ничья) Әйе, дөрес. Димәк, безгә кәгазь  акчалар да һәм тимер акчалар да  кирәк. Балалар, берәр нәрсә сатып алган вакытта акчадан башка тагын нәрсә белән түләп була?

(Банк картасы).

Т: Аны каян алалар?

(Банктан)   Әйе, безнең Биектау районында менә шундый ике зур банк бар: Сбербанк һәм Ак Барс банкы

Сез ничек уйлыйсыз, уңайлы микән банк картасы белән файдаланырга? Нигә?

(Балаларның җаваплары).

Физкультминут:әйдәгез  “Кибеттә” дигән уен уйныйбыз.

Сатыла торган әйбер булса, кул чабабыз, сатылмаса-тыпырдыйбыз.

Ипи, дуслык, китап, иптәш, ручка.

Тәрбияче: иҗат үзәгенә барыгыз. Сезнең алда ак кәгазьләр,тәңкәләр ята. Сезнең һәрберегез төсле карандашлар, фломастерлар ярдәмендә үзенең кабатланмас бизәген безнең төркем акчаларына төшерә.

Тәрбияче: балалар, сез зур афәрин! Ә хәзер әйтегез әле, сез бүген нинди яңалык белдегез? Сезгә нәрсә ошады? Нәрсә авыр булды?

Хезмәтегез өчен рәхмәт сезгә!

## «МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРГА УЕННАР АША, ЯҢА ИННАВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНЫП МИЛЛИ ТӘРБИЯ БИРҮ»

## («Татар милли киемнәре»)

***Хисамова Алия Рефатжан кызы***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының*

*"Катнаш төрдәгеБалтач 5 нче балалар бакчасы"*

*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе*

**Максат:**

-Татар милли киемнәре турында белемнәрен ныгыту.

Максатыбызны чынга ашыру өчен түбәндәге бурычлар куелды:

-Татарча сөйләм телен үстерү;

- Балаларның логик фикерләү сәләтен үстерү.

- Милли киемнәргә кызыксыну уяту, үзләренә генә хас булган үзенчәлекләрен ачыклау.

**Сүзлек:** лалә, өчьяфрак, канәфер чәчәге, милли, күлмәк, чалбар, читек, калфак, түбәтәй, билбау.

**Җиһазлар:** смарт такта, ноутбук.

**Уен барышы**

**Тәрбияче:** Хәерле көн,балалар. (исәнләшү)

**Тәрбияче:**Һәр яңа көнне яхшы кәеф белән башларга кирәк. Кәефебез күңелле һәм яхшы булсын өчен, куллар тотышыйк (түгәрәк ясамыйча, баскан килеш кенә), бер-беребезгә карап елмайыйк, йөрәгебездә булган җылылык һәм мәхәббәт чаткыларын бер – беребезгә бүләк итик.


**Тәрбияче:** Балалар, сез нинди милләтләр барлыгын беләсез? (удмурт, татар, рус, мари, башкорт).

**Тәрбияче:** Рәхмәт. Әйе, милләтләр күптөрле була. Сез бик күп беләсез икән. Ә без бүген сезнең белән татар халкының милли киемнәрен искә төшереп бер уен уйнап алырбыз. Уенны алып бару өчен миңа бер ярдәмче кирәк була.(смарт такта янына бер бала чакырыла.)

**Тәрбияче:** Әнисә белән Салих сездән ярдәм сорыйлар.

**Тәрбияче:** Балалар, сез экранда кемнәрне күрдегез? (Әнисә исемле кыз һәм Салих исемле малайны)

(Аннан соң башта күлмәк, аннан аяк һәм баш киемнәрен кияргә ярдәм итәләр).











**Тәрбияче:**Балалар,Әнисәгә нәрсәләр киендердегез? (Күлмәк, камзул, читек, калфак).

Ә Салих нинди киемнәр киде? (Күлмәк, чалбар, камзул, читек, билбау, түбәтәй).

**Тәрбияче:**Әлеге киемнәр милли киемнәр дип атала. Чөнки алар татар халкының милли бизәкләре белән бизәлгән.

**Тәрбияче:**Шигырь уку: Л.Лерон. «Татар баласы».

Калфак кигән кыз баланың
Багып алчы йөзенә,
Нинди гүзәл татар кызы,
Күз тимәсен үзенә.
Килешеп тора түбәтәй
Аның күркәм йөзенә.
Нинди матур татар улы,
Күз тимәсен үзенә.

**Тәрбияче:**Малай белән кызның киеме нәрсә белән аерыла? (малайларның башында түбәтәй, кызларның – калфак. Малайлар күлмәк, чалбар, билбау кия, кызлар күлмәк кия).

**Тәрбияче:** Нинди киемне кызлар да, малайлар да кия? (читек)

**Тәрбияче:** Булдырдыгыз, балалар. Әнисә белән Салих сезгә бер матур җыр да әзерләгәннәр.( **"Кәләпүшем, калфагым"** җыры яңгырый.)

**Тәрбияче:** Балалар, карагыз әле, милли киемнәрдә миллилек өсти торган нинди үзенчәлек бар? (орнамент – бизәк).

**Тәрбияче:** Орнаментта гадәттә чәчәкләр ясала. Сез орнаментта нинди чәчәкләр күргәнегез бар? ( ләлә чәчәге (тюльпан), канәфер чәчәге (гвоздика))

**Тәрбияче:** Татар милли бизәкләре арасында тагын нинди бизәкләр очратырга мөмкин?(ай рәсеме, йөрәк рәсеме, өчъяфрак, гөлҗимеш).

**Тәрбияче:** Бик дөрес. Балалар, без бүген сезнең белән белемнәр сандыгынаниләр салып куярбыз икән? Әйдәгез әле искә төшерик. (малай белән кызны милли киемнәргә киендердек, җыр тыңладык, бизәкләр турында сөйләштек)

**Тәрбияче:** Бу сандыкны кирәк чакта без ача алырбыз, шулаймы? (Әйе) Балалар, саубуллашыр вакыт та килеп җиткән. Сау булыгыз. (Гармун көенә чыгып китү)

## “МУЗЫКА ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ ТАТАР ХАЛЫК КӨЙЛӘРЕН КУЛЛАНЫП, “ЭВРИТМИЯ” ТЕХНОЛОГИЯСЕ АША, БАЛАЛАРНЫҢ МУЗЫКАЛЬ СӘЛӘТЛӘРЕН ҮСТЕРҮ” (МАСТЕР КЛАСС)

***Васильева Илһамия Таһир кызы***

*Балтач районының “Катнаш төрдәге*

*Карадуган балалар бакчасы”*

*музыка җитәкчесе*

**Максаты:** эвритмик гимнастика аша мәктәпкәчә яшьтәгебалаларның музыкаль сәләтләрен үстерү.

**Белем бирү бурычы:**татар халык көйләрен танып белү күнекмәләрен ныгыту.

**Үстерү бурычы:** ритмик уеннарны башкару осталыкларын үстерү.

**Тәрбия бурычы:**кулдан ясалган уен коралларына кызыксыну ояту.

**Барышы:**

Хәерле көн, хөрмәтле хезмәттәшләр. Мин Васильева Илһамия Таһир кызы, Балтач районы “Катнаш төрдәге Карадуган балалар бакчасы” ннан музыка җитәкчесе булам. Безнең бүгенге очрашуыбыз бик кызыклы булган музыкаль уеннар һәм күнегүләр турында булыр. Һәм мастер-классның темасы да: Музыка эшчәнлегендә татар халык көйләрен кулланып, “эвритмия” технологиясе аша, балаларның музыкаль сәләтләрен үстерү” дип атала.

***I өлеш–теоретик.* (сөйләгәндә кызыл һәм зәңгәр таякчыклар өләшенә)**

Нәрсә соң ул Эвритмия? Грек теленнән тәрҗемә иткәндә Эвритмия – ул “гүзәл ритм”, “гүзәл хәрәкәт” дигәнне аңлата. Сөйләм, музыка һәм хәрәкәт бергә булганда эвритмик гимнастиканы барлыкка китерә дә инде.

Эвритмик гимнастика үз эченә ритмик уеннар, социаль уеннар, импровизацияле-хәрәкәт композицияләре, махсус уен-күнегүләр һәм уенлы-биюләрне ала. Бүген без сезнең белән ритмик уеннар өлешенә тукталырбыз. Чөнки беренче чиратта балаларны ритм тояргa өйрәтергә кирәк. Моның өчен мин иң гади хәрәкәтләр комбинациясен (ритмны аяк белән сугу, кул чабу, тыпырдау, сикерү һ.б.) һәм музыка уен коралларын кулланам. Ә инде музыка уен кораллары гадәти булмаган алымнар белән ясалган булса, уеннар тагын да кызыклырак һәм мавыктыргыч була. Сүзле күнегүләрдә уен коралларын куллану ритм тою хисен арттыра, артикуляцияне камилләштерә. Музыка уен кораллары балаларны музыка шөгыленә җәлеп итүче һәм кызыксындыручы бер чара булып тора.Бу уеннар вакытында балалар үзләре дә сизмәстән шигырьне җиңел ятлыйлар.

***II өлеш–практик.***

Сезнең белән шундый уеннарның берсен уйнап алыйк.

**“Кояш, чык” (балалар фольклорыннан)**

*Таякчыклар ярдәмендә ритм сугып җырлау.*

Кояш чык, чык, чык!

Майлы ботка бирермен!

Майлы ботка казанда!

Тәти кашык базарда!

*Таякчыклар тоткан катнашучыларны өстәл янына чакыру. (6 кеше)*

Мин Сезгә оркестр булдырырга тәкъдим итәм. Ә оркестр өчен тавышлы уен коралларын үзебез ясарбыз. Өстәлләрдә уен коралларын ясау буенча күрсәтмәлекләр һәм ясау өчен кирәкле материаллар куелган. Үзегезгә ошаган уен коралын ясап карагыз әле. Рәхим итегез. *(пластик кашыклардан маракаслар, чикләвек кабыгыннан шакылдавыклар, кер кыстыргычларыннан трещоткалар ясау)*

Музыкантларыбыз үз эшләрен башкарган арада, залда утыручылар, Сезгә мөрәҗәгать итәсем килә. Игътибарыгызны экранга юнәлтегез әле. ***(экранда күк йөзе сурәтләнгән слайд)*** Экранда нәрсәләр күрәсез? *(күбәләкләр, болытлар, чәчәкләр)* Күк йөзендә нәрсәдер юк. *(кояш)****(экранда кояш сүрәтләнгән слайд)*** Кояшның ничә нуры бар? *(7)* Ничек уйлыйсыз, 7 саны һәм музыка, нинди бәйләнеш бар? *(музыкада 7 нота бар)* ***(экранда ноталар сүрәтләнгән слайд)***Ноталарны искә төшереп җырлыйк әле, шул ук вакытта куллар белән аска һәм өскә хәрәкәтләр ясарга кирәк булыр.

***Җырлау "Ноталар"***

Ноталар бик матур көй барлыкка китерделәр. Үзләренең билгеле бер ритмнары да бар. Ә хәзер мин сезне тылсымлы табигать тавышларында булган ритмнарны тыңларга чакырам.

1. Җылы яңгыр яуганда яфраклар пышылдашалар. ***(экранда яңгыр һәм яфраклар сүрәтләнгән слайд - пергамент кәгазь ярдәмендә тавыш чыгару)***
2. Яңгырдан соң калган тамчылар яфраклардан җиргә тәгәриләр. ***(экранда яфраклар сүрәтләнгән слайд - пластик стакан ярдәмендә тавыш чыгару)***
3. Ерак түгел алан буенда чишмә үзенең җырын суза. ***(экранда чишмә агуы сүрәтләнгән слайд - стаканнан су агызу ярдәмендә тавыш чыгару)***

Чишмә суы үзенең бик матур җырын башкарыр. Тынлап карагыз әле, нинди көй ишетерсез икән?

***Сулы бокалларда көй уйнау. ("Әпипә" татар халык җыры)***

Нинди көй ишеттегез? Әйе, татар халык җыры "Әпипә".

Ритмнарны һәм төрле көйләрне гадәти булмаган алым белән ясалган тавышлы уен коралларында башкару балалар белән аларны тыңлауны тагын да мавыктыргыч һәм кызыклы итә.

Минем сезгә уен тәкъдим итәсем килә.Нәрсә соң ул "Яңгырашлы хәрәкәтләр"? *(кул чабу, тыпырдау, тезгә чәбәкләү, бармаклар ярдәмендә тавыш чыгару)*. Алар кешелектә иң беренче инструментлар, алар һәрвакыт безнең белән. Без"Әпипә" җырына яңгырашлы хәрәкәтләр ясарбыз.

***"Әпипә" җырын "Яңгырашлы хәрәкәтләр" ярдәмендә башкару.***

Бас, кызым, Әпипә, *(бармаклар ярдәмендә тавыш чыгару)*

Син басмасаң мин басам. *(кул чабу)*

Синең баскан эзләреңә *(тезгә чәбәкләү)*

Мин дә китереп басам *(тыпырдау)*

Музыкантларыбыз үз эшләрен тәмамлаганнар, аларны үз яныма чакырам. Каршы алыгыз, сезнең өчен "Нур" оркестры башкаруында татар халык көе.

***Оркестр "Татар халык көйләренә тезмә"***

Рәхмәт Сезгә. Сезнен көчле алкышларыгыз белән музыкантларыбызны урыннарына озатабыз.

Кайда гына тыңламадым икән
Моң саркыган татар көен мин –
Сайрар кошлар, тал-тирәкләр белә
Һәр бормасын «Әллүки»емнең.

***Җыр "Әллүки" (акапелла башкарыла) (Г.Тукай сузләре, татар халык көе)***

Безнең барыбызның да уртак максатыбыз - туган илен, туган җирен, туган телен яратучы татар җанлы шәхес тәрбияләү. Татар халык көйләреннән башка берничек тә мөмкин түгел.

Балачак, чыннан да, бәхетле, кайгысыз булсын дисәк, балаларга рәхәтләнеп җырлап яшәргә шартлар булсын. Әйдәгез, үзебезнең балалар белән ешрак җырлап уйныйк. Киләсе очрашуларга кадәр!Рәхмәт сезгә.

## "ХАЛКЫБЫЗНЫҢ МИЛЛИ БИЗӘКЛӘРЕ-КУЛЪЯУЛЫК ЭШЛӘҮ"

***Галиуллина Алсу Мөнир кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының*

*"Чыршы"Салават купере" балалар бакчасы,*

*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** -милли традицияләребез нигезендә ятучы кыйммәтле, милли, әхлаклы сыйфатларны саклау.

**Бурычлар:** -татар халкының милли бизәкләре турында мәгълүмат бирү, кызыксынуларын арттыру;

- милли чәчәк, үсемлек орнаментлары турында төшенчә бирү;

-татар халык бизәкләрен кулланып, "салкын батик" ысулы белән кулъяулык ясау;

-эш барышында куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.

**Кирәкле материаллар:** өлге (шаблон), кайчы, атлас тукымадан кисеп тегелгән шакмак рәвешендәге тукыма, тукымага төшерә торган буяулар, пумала, энә, төрле төстәге җепләр, гади карандаш, буяуны тукымага таратмый торган махсус сыеклык , киерге.

**Мастер-класс барышы:**




1. Тема белән таныштыру.

-Исәнмесез, хөрмәтле әниләр, дәү әниләр!Без бүген Сезнең белән халкыбызның милли бизәкләре турында сөйләшербез. Милли бизәк төшенчәсен ничек аңлыйсыз?

Бизәк (орнамент) латин теленнән килеп чыккан.

Инде халкыбызда болай диләр: “Сөйлә миңа- мин онытырмын, күрсәт- истә калдырырмын, кызыксындыр-өйрәнермен. Минем дә Сезне кайбер бизәкләр белән кызыксындырып китәсем килә.Бизәкләргә игътибар итик. Бизәкләрдә без кыңгырау, лалә чәчәкләрен күрәбез, шул ук вакытта ярым түгәрәкле рәсемнәр дә бар. Ә төсләренә килгәндә ачык төсләр: кызыл,сары, яшел, зәңгәр.

Татар халкы элек-электән бик тырыш чиста, пөхтә халык буларак билгеле.Хәзер дә татарлар яшәгән авылларны карасак, ялт итеп торалар, йортлар төзек, бай, кешеләр мул тормышта яшиләр, тәрәзә төпләрендә ясалма чәчәкләр түгел, ә чын табигый гөлләр үстерәләр. Болар барысы да кешенең тырышлыгы белән генә булдырыла. Сез моны үзегезнең әти-әниләрегездән күреп һәм сез дә үзегезнең балаларыгызга тапшырырга тырышасыздыр дип уйлыйм.

Бүген без татар орнаментларын кулланып, менә мондый кулъяулыклар эшләрбез.

2. Эш барышы:

-өлге өстенә шакмак рәвешендәге атлас тукыманы куеп бизәкләрне төшерү;

- киергегә киертеп махсус сыеклык белән бизәкләрне йөртеп чыгу (ул кипкән арада татар халык җыры “Эх алмагачлары”җырлана);

- бизәкләрне буяу ( бизәкләр кипкән арада “Татар халык бию”нә бию);

- кулъяулыкның кырыйларын төсле җепләр белән чигеп чыгу.

3. Йомгаклау:бик матур булган рәхмәт сезгә! Кул җылысы, бигрәк тә күңел җылысын биреп башкарылган эш һәрчак уңышлы була. Хөрмәтле әниләр, әбиләр, мастер- класста актив катнашуыгыз өчен бик зур рәхмәт!

# МИЛЛИ БИЗӘКЛЕ ЧӘЧ КЫСТЫРГЫЧ

**(Мастер-класс)**

***Мөхәммәтшина Диләрә Фоат кызы***

*“Татарстан Республикасы Саба районы муниципаль районы Олы Кибәче “Күбәләк” балалар бакчасы”- муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

“Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге булмас”, ди татар халык мәкале. Татар халкын милләт буларак саклап калу, үстерү, үткәннәре турында түкми-чәчми балаларыбызга тапшыру- ул тәрбиячеләребезнен вазыйфасы дип уйлыйм мин.

Татар милли бизәнү әйберләрен хәзер газета-журнал битләрендә, телевидение аша яки милли бәйрәм чараларында гына күрергә мөмкин. Борынгы заманнарда чулпылар, беләзекләрне көндә тагып йөрү гадәти күренеш булган. Татар хатын-кызлары элек-электән бик матур һәм зәвыклы киенеп, бизәнеп йөргән.

Балалар бакчасында без дә үз милләтебезнең гореф-гадәтләрен, милли уен, йолаларын искә төшереп, төрле бәйрәмнәр, чаралар уздырып торабыз.

Менә бүген мин сезгә татар халкының милли бизәкләрен кулланып, бик матур чәч кыстыргычлары ясау турында сөйләп үтәм.



Кыстаргычларны ясар өчен безгә фаомиран, гади кыстыргычлар, милли бизәкләр төшерелгән әзер эш үрнәкләре, кайчы, карандаш, ике яклы ябыштыргыч һәм матур сәйләннәр кирәк була.

Иң башта без әзер эш үрнәкләрен фаомиранга куеп төшереп алабыз. Аннары кисеп милли бизәкләрне әзерлибез. Әзер өлешләрне кыстыргычка ике яклы ябыштыргыч белән беркетәбез. Шушы әзер кыстыргычларны матур ташлар, сәйләннәр белән бизибез. Менә безнең чәч кыстыргычларыбыз әзер. Кызларыбыз чәчләренә бу милли кыстыргычларны куеп, бәйрәмнәрдә үз милләтләре белән горурланып йөрерләр.

Сабый чакта ук күңелгә, йөрәккә салынган изге орлыклар яхшы шытымнар бирә. Үз телендә матур итеп сөйләшеп, үз милләтенең гореф-гадәтләрен, милли киемнәрен, милли бизәкләрен белеп, күреп үскән бала киләчәктә дә милләтенә тугрылыклы булып калачак. Мин моңа ышанам.

**Сумкага татар халкының милли бизәген төшерү**

**Миннебаева Зөлфия Әсхәт кызы**

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*
*«Биектау «Шаян» катнаш төрдәге балалар бакчасы»*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** Төсле буяулар кулланып сумкага татар халкының милли бизәген төшерү; орнамент турында төшенчә бирү.
**Бурычлар:**
Белем бирүче: трафарет ярдәмендә төсле буяулар кулланып , сумкага татар халкының милли бизәген төшерү.
Үстерешле: уйлау сәләтен ,логик фикерләүне ,сөйләм телен үстерү.
Тәрбияви: мөстәкыйльлек ,тырышлык,иҗади сәнгатькә кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү.
**Эш формасы:** индивидуаль .
**Методлар һәм алымнар:** сөйләү, демонстрация, күрсәтү, аңлату.
**Алдан эшләнгән эш:** татар халкының милли бизәкләре ясалган китаплар карау.
**Сүзлек өстендә эш**: орнамент, трикотаж тукыма.
**Жиһазлар һәм жайланмалар:** әзер эш үрнәкләре, трафаретлар, төсле буяулар ,сумка-шопер, губкадан ясалган кисточкалар.
Мастер-класс уртанчылар төркеме балаларына исәпләнгән .

**Эшчәнлек барышы:**

**I. Кереш өлеш.**



Балалар алдан әзерләнгән өстәл кырыена басалар.
Тәрбияче: Балалар,безнең әби-бабайларыбыз,әти-әниләребез аш-суга,җыр- биюгә бик сәләтле булу белән бергә, кул эшләренә дә оста булганнар! Бүгенге көндә хатын-кызларның күбесе төрле-төрле бизәкләр , рәсемнәр төшерелгән сумкалар белән йөриләр.Кибет -базарда нинди генә сумка сатылмый ... Әмма үз кулларың белән бизәлгән сумкага ни җитә?! Театр-концертка барганда да , иңбашыңа андый сумка элсәң “уңган һәм күркәм туташ” образың тулы булыр.
Бүгенге шөгыльдә без трикотаж сумкага төрле төсле буяулар кулланып трафарет ярдәмендә татар халкының милли бизәген төшерәбез.

**II. Төп өлеш.**

Тәрбияче:Балалар,вакытны озакка сузмас өчен трафаретлар,төрле төстәге буяуларны алдан әзерләп куйдым. Пумалаларны таякчыклар һәм губка ярдәмендә ясадым. Эшкә керешик. Сумка өстенә трафарет куела, пумалага тиешле буяуны алып сумканы бизибез.

**III. Нәтиҗә ясау.**

Тәрбияче:Менә шундый татар халкының милли бизәге төшкән сумка барлыкка килде.



Бүген сез шөгыльдә алган күнекмәләр белән бу эшне үзегез дәвам итә аласыз һәм бүтән балаларны да олыларны да өйрәтә аласыз.

Башкарган эшегез һәм сәләтегез өчен рәхмәт.Шуның белән мастер-класс тәмам.

# ДИДАКТИК

# УЕННАР



# МИЛЛИ БАРАБАН

***Гайфуллина Ләйлә Фәнил кызы***
*“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*Олы Кибәче “Күбәләк” балалар бакчасы”муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:** балаларга уеннар аша милли тәрбия бирү.

**Бурычлар:**

- татар халкының милли ашларын,киемнәрен,музыка уен коралларын орнаментын өйрәнү .
- балаларның логик фикерләвен, хәтерен үстерү,кул чукларын,ориентлашуны ныгыту.
- милли һәм эстетик тәрбия бирү,үз халкына хөрмәт,ярату хисләре уяту.
- балаларның үзара аралашуына,дустанә мөнәсәбәттә булуына,ярдәмләшеп эшләвенә ирешү.

Әлеге уен 5-7 яшьлек балалар өчен әзерләнде. Уен алдыннан татар халкының милли ашлары, музыка уен кораллары, киемнәре турында әңгәмәләр алып барылды, татар орнаментлары өйрәнелде.

**“Милли барабан”** дидактик уены 6 уеннан тора. Барабанны әйләндерүче санамыш ярдәмендә билгеләнелә. Барабан угы кайсы уенга туктый, шул уен уйнатыла. Уен шул рәвешле дәвам итә.

| | |
|---|---|
|  | **“Милли ризыклар”** уены<br>**Максат:** ике милләтнең ризыкларын искә төшерү. Фикерләү сәләтен үстерү.<br>**Уен барышы**: балаларга рус һәм татар халкының милли ризыклары төшерелгән рәсемнәр бирелә.Алар ризыкларны дөрес итеп, карточкаларда урнаштыра. |

| | |
|---|---|
| <br> | **“Парын тап”** уены<br>**Максат:** логик фикерләү сәләтен үстерү, игьтибарлылык тәрбияләү.<br>**Уен барышы**:  үрнәк буенча рәсемнең өлешләрен табу. |
| <br> | **“Моңлы көй”** уены<br>**Максат:** җыр сәнгатенә мәхәббәт уяту.<br>**Уен барышы**: балалар алдына төрле уен кораллары төшерелгән рәсемнәр куела. Мультимедиядән төрле көйләр яңгырый. Балалар дөрес уен коралы рәсемен сайлап алырга һәм исемен әйтергә тиеш була. |
| <br> | **“Милли киемнәр”** уены<br>**Максат:** татар халкының милли киемнәре турында белемнәрен ныгыту; сүз байлыгын арттыру.<br>**Уен барышы**:  рәсемнәрне бирелгән карточкаларга  дөрес итеп ябыштырыла  һәм исемнәрен атала. |
| <br> | **“Милли келәм”** уены<br>**Максат:** хәрәкәтне, кул чукларын, ориентлашуны ныгыту;дустанә уйнау.<br>**Уен барышы**:  балалар алдына милли бизәкләр төшерелгән келәм җәелә.Санамыш ярдәмендә беренче уенчы билгеләнелә. Шакмак тәгәрәтелә.Шакмакта нинди бизәк туры килә,бала шул бизәкләргә генә басып  йөреп килә. |

| | |
|---|---|
|  | **“Милли бизәк”** уены<br>**Максат:** балаларның милли киемнәр турында белемнәрен ныгыту, кул чукларының вак моторикасын үстерү.<br>**Уен барышы**: бирелгән кием үрнәкләренә татар орнаментларын сайлап ябыштыру. |

## "Белем чемоданы”
## (Дидактик кулланмага методик киңәшләр)

**Фатыйхова Гөлнара Нурзадовна,**
**Кәлимуллина Гөлназ Маратовна**

*Татарстан Республикасы Балтач районы муниципаль бюджетмәктәпкәчә белем бирү учреждениесы “Салавыч балалар бакчасы”*




Дидактик кулланма белем чемоданын - 2-7 яшьлек балалар өчен индивидуаль, төркемдә фронталь эшләрдә, шулай ук мөстәкыйль балалар эшчәнлеге өчен кулланылырга мөмкин. Бу ярдәмлекнең гамәли әһәмияте һәм яңалыгы аның вариативлыгында, бер генә ярдәмлек кулланып, күп кенә мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлегендә. Бу методик кулланмага киңәшләрдә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләмен, эстетик күзаллавын үстерүенә, фикерләү сәләтен камиләштерүгә юнәлдерелгән. Белем чемоданны җыйнаклыгы, гадилеге һәм мобильлеге белән төркемдә дә, өй шартларында да уйнап үсәргә мөмкинлек бирә. Әлеге кулланма мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре тәрбиячеләре, укытучы-логопедлар, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларның ата-аналары өчен тәкъдим ителгән.

**Кулланманың максаты**: балаларның сөйләмен үстерү өчен шартлар тудыру, белем чемоданы дидактик кулланма аша баланы төрле якттан җәмгыяткә яраклашкан шәһес итеп формулашуына ярдәм итү.

**Белем чемоданы дидактик кулланмасын куллану процессында тормышка ашырыла торган бурычлар.**

**Белем бирү бурычы:** ФГОС таләпләренә туры китереп биш белем бирү өлкәсендә баланың фикерләү сәләтен, сөйләмен, эстетик күзаллавын физик үсешен камилләштерү**.**

**Тәрбия бурычы:** Халык аваз иҗаты жанрына карата, гайлә традицияләренә , дәүләтенә карата мәхәббәт хисләре тәрбияләү**.**

**Үстерү бурычы:** логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйль һәм бергәләп эшләү күнекмәләрен үстерү.

**Төп белем бирү өлкәсе: сөйләм үсеше**

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сәнгати-эстетик үсеш , физик үсеш, иҗтимагый-комуникатив үсеш, танып - белү үсеше.

**Методик алымнар һәм чаралар:** уен, күрсәтмә материал, сүзлек өстендә эш, сөенеч мизгеле, сораулар, әдәби сүз, үсендерү-мактау, искә төшерү, ныгыту, үзеңә бәя бирү,әңгәмә , интерактив уен.

Бу ярдәмлекнең күп функциялелеге аны теләсә нинди эшчәнлектә кулланудан гыйбарәт. Ярдәмлек төркем, төркемчә һәм шәхси дәресләр үткәрү өчен үзгәртелә ала, педагоглар, ата-аналар тарафыннан балалар белән эшләүдә кулланыла ала. Ярдәмлекнең эчтәлеген тулыландырырга һәм катлауландырырга мөмкин. Чемоданда сөйләм үсеше, танып белү үсеше, сәнгати-эстетик үсеш, физик үсеш, соөиалҗ комуникатив үсеш буенча уеннар һәм таратма материалы тәкъдим ителгән.

**Тасвирлама (дидактик кулланманы куллану буенча инструкция)**

Дидактик кулланма белем чемоданы – интерактив кулга тотып йөртә торган чемодан рәвешендә эшләнгән, анда мәгълүмат ачыла өч торган бүлекчә рәвешендә бирелә, андатөрле китапчыклар һәм алына торган карточкалар, лэпбуклар бар, аларны бала үз теләге буенча ала, күчереп куя, җыя ала. Чемодан белән эшләү баланы барлык яктан камил итеп үстерүгә юнәлдерелгән дидактик уеннар һәм күнегүләр сайлап алынган һәм системалаштырылган(тавыш әйтелеше, сөйләмнең всехик-грамматик ягын, телнең фонетик-фонематик системасын һәм тавыш анализы һәм синтезы күнекмәләрен формалаштыру, сөйләмнең просодик ягын үстерү, грамота, бәйләнешле сөйләм һәм сөйләм аралашу

элементларын өйрәтү.) Төсле, танып белү чемоданы балаларда уен мотивациясен булдырырга, биремнәрне үтәгәндә аларның кызыксынуын сакларга ярдәм итә, ә уен ситуациясенә чуму һәм биремнәрне үтәү тәрбиячегә баланың сөйләмен мөмкин кадәр баетырга һәм активлаштырырга мөмкинлек бирә.

**“Белем чемоданы” кулланмасының технологик картасы.**

Белем чемоданы өч тартмадан тора, анда һәр тартмада төрле уеннар бар.

1.Бармак уеннары

2.Табышмаклар

3. Балалар өчен хәрәкәтле уеннар

4. Физмик күнегеләр.

5. Сулыш алырга йөртечү уеннар

6. Маршерутлы уен карталары.

7. Мавыктыргыч keләмнәр.

8. Мавыктыргыч алъяпкыч

9. Китапчык “Кечкенә музыкант”

10. Экологик уеннар.

11.”Мавыкттыргыч математик дөнья”

12.”Кыргый һәм йорт хайваннары”.

## ЭЧТӘЛЕК

1. Гыйлметдинова Г.Р. “Бусага ялы”йоласы ........................................7
2. Әхмәтшина Ф.С. Кич утыру........................................12
3. Гилемханова Р.Н. Кабык салып, мунчала алу күренеше........................................15
4. Әхмәтшина Н.Р. Он тарту ........................................19
5. Гарипова А.Н. Авылым чишмәләре, әбием йолалары........................................23
6. Гобәйдуллина Ф.И. Аулак өй........................................28
7. Рәхимова Г.Р. Әбиемнең серле сандыгы........................................34
8. Гәлләмова Р.Р., Шәвәлиева Н.М. Исем- күңел көзгесе........................................39
9. Зәйнәкова Г.И. Туган нигезгә җыелу йоласы........................................42
10. Гыйләҗиева Э.Р. Без – Тукай оныклары ........................................45
11. Тимергалиева Ә.З. Дуслык иле ........................................49
12. Васильева Л.Т. Милли уеннар ярминкәсе........................................53
13. Фәйзетдинова Л.Х.Кичке аш вакыты күренеше........................................59
14. Шәйхуллина А.И. Минем нәсел – минем шәҗәрәм........................................61
15. Шәвәлиева Г.М. Без – яшь журналистлар........................................65
16. Шәрипова Э.Г. татарстанда яшәүче милләтләр........................................69
17. Яруллина А.Р. Әкият иленә сәяхәт........................................74
18. Яруллина Ф.Н. Гаилә – имин юл күрсәтүче........................................77
19. Закирова Ч.Г., Хәбибуллина Л.Ю. Икмәк иң зур байлык........................................83
20. Сәйфетдинова Г.З., Сәйфелганиева М.А. Әбиемнең күңел сандыгы........................................86
21. Мөхәмәдиева Э.Р., Галимуллин И.Р. Оста куллы бабам ........................................88
22. Минһаҗева Р.Г. Лалә чәчәге бизәге ........................................90
23. Әхмәтханова Г.К. Нәрсә ул акча? ........................................93
24. Хисамова А.Р. Татар милли киемнәре........................................96
25. Васильева И.Т. Музыка эшчәнлегендә татар халык көйләрен кулланып,”Эвритмия” технологиясе аша, балаларның музыкаль сәләтләрен үстерү........................................98
26. Галиуллина А.М. халкыбызның милли бизәкләре ........................................101
27. Мөхәмметшина Д.Ф. Милли бизәкле чәч кыстыргыч........................................103
28. Миннебаева З.Ә. Сумкага татар халкының милли бизәген төшерү........................................104
29. Гайфуллина Л.Ф. Милли барабан........................................107
30. Фатыхова Г.Н., Кәлимуллина Г.М. Белем чемоданы........................................109

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 03.05.2024.
Форматы 60×84 $^{1}/_{16}$. Шартлы басма табагы 7.
Тиражы 100 д. Заказ

«Ихлас» нәшрияты. 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
Тел.: 89172836545
E-mail: ilfaz@mail.ru